**Министерство образования и науки Республики Татарстан**
**Отдел образования Управления образования ИКМО г. Казани по Авиастроительному и Ново-Савиновскому районам**
**Средняя общеобразовательная татарско-русская школа №71 с углубленным изучением отдельных предметов Ново-Савиновского района г.Казани**

# *ВЕНЕЦ ТВОРЕНИЯ…*

**Республиканские педагогические чтения, посвященные выдающимся татарским просветителям, педагогам и общественным деятелям**

**Казань – 2023**

УДК 372.882.512.145
ББК 74.268.3(2Рос=Тат)
Л

***Редакторы:***

**Т.Р.Шакирова**, Заслуженный учитель Татарстана, директор высшей квалификационной категории муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Средняя общеобразовательная татарско-русская школа №71 с углубленным изучением отдельных предметов» Ново-Савиновского района г.Казани;

**Р.Р.Кашапова**, заместитель директора высшей квалификационной категории по вопросам национального образования муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Средняя общеобразовательная татарско-русская школа №71 с углубленным изучением отдельных предметов» Ново-Савиновского района г.Казани

**Венец творения…:** Республиканские педагогические чтения, посвященные выдающимся татарским просветителям, педагогам и общественным деятелям. – Казань, редакционно-издательский центр «Школа», 2023. – 324 с.

В сборник включены тезисы научно-исследовательских работ учителей школ г.Казани и республики, представленных на Республиканских педагогических чтениях, посвященных выдающимся татарским просветителям, педагогам и общественным деятелям. Сборник адресован преподавателям общеобразовательных организаций.

*Материалы печатаются в авторской редакции*

© Коллектив авторов, 2023
© Оформление РИЦ «Школа», 2023

# ВЕНЕЦ ТВОРЕНИЯ ...



*Никогда не прекращайте вашей самообразовательной работы, сколько бы вы не учились, знанию и образованию нет ни границ, ни пределов*

*Н.А.Рубакин*

Одной из актуальных проблем образования татарского народа конца 19 века было образование женщин. Школы для обучения женщин в разных городах были открыты меценатами, купцами, промышленниками и их женами. Махруй ханум Барудия – одна из таких женщин.

Махруй (Бибимагруй) ханум родилась в 1862 году в деревне Мечкяра Малмыжского уезда. Ее отец Исхак Мусыевич Утямешев был богатейшим человеком своей эпохи – владельцем прядильных и ткацких фабрик.

Махруй ханум с раннего детства стала ходить на уроки Гайши абыстай, внучки дяди Курсави Габдулхалика ишана, изучала тюркский, арабский и персидский языки. Ишан Габдулхалик, получивший образование в Каире, учил ее правильно читать Коран и красиво писать. Свои религиозные и светские знания девочка черпала также из тюркских книг богатой домашней библиотеки и многочисленных писем отца.

В возрасте одиннадцати лет Махруй ханум осталась без отца, воспитывалась матерью и родными.

В 1882 году девушка была выдана замуж за Галимзяна-хазрета Баруди. Брат Галимзяна Баруди Салихзян Галиев женился на второй дочери Исхака Утямешева.

После замужества образованием Махруй ханым занимался Г.Баруди сам и привлекал преподавателей медресе «Мухаммадия». Впоследствии она понимала уже смысл Корана и хадисов при чтении на арабском языке.

Однажды произошел такой курьёзный случай. При чтении сборника хадисов Галимзян хазрат с преподавателями медресе не смогли понять смыл хадиса из-за того, что не знали перевод одного слова «салк». Мах-

руй ханым, находящаяся в это время за ширмой, со смехом ответила, что это слово на тюркском языке означает «свекла» и добавила: «Один из вас – великий мударрис Казани, два других – медресе «Мухаммадия», но не можете перевести это простое слово». В медресе долго вспоминали этот забавный случай.

Муфтий Галимзян аль-Баруди о своей жене Махруй ханум написал: «Если говорить о моей жене Махруй ханум, она – **венец творения.** При нашем знакомстве она зачитывалась книгой «Укрепление слабых», глубоко вникая в смысл произведения, при этом часто повторяла, что эта книга – ее шейх, она радует ее душу и передает весь дух религии. Махруй ханым много молилась и читала Коран по ночам, до последних дней своей жизни не переставала учиться. Ни одна статья, которая попадала ей в руки, не оставалась не прочитанной и не разобранной до последнего слова. Махруй ханым писала без ошибок, всегда обращала внимание на правописание слов и стиль письма. У нее было сильно развито критическое мышление. Если у меня не было времени прочитать новые книги, я просил ее прочитать их, и с ее слов знакомился с содержанием этих произведений. Около двадцати лет своей жизни моя жена посвятила себя просветительской работе. Именно она одной из первых в Казанской губернии обратила внимание на внедрение новых методов преподавания в женском образовании, учила девушек основам правильного чтения Корана и объясняла всем о необходимости получения образования».

Махруй ханым в наследство от отца получила огромную сумму денег. В отличие от большинства богатых женщин, которые тратили свое состояние на красивую одежду и украшения, она, радеющая за будущее татарского народа, особенно женщин, вкладывала свои знания, силы и средства в просвещение и религиозное образование женщин. Её старания и неоценимый вклад до сих пор живы в памяти татарского народа.

Махруй ханым первая открыла школу для девушек, образцом для которой была первая Казанская новометодная мужская школа, созданная ее мужем Галимзяном Баруди.

Выпускницы её школы, овладевшие новыми методами обучения, в дальнейшем преподавали в других школах и медресе. Одна из выпускниц Лябиба ханым продолжила дело своей наставницы, после ее смерти руководила школой Махруй ханым, позднее открыла и свою школу для девочек.

29 января 1891 года в газете «Волжский вестник» была опубликована статья о применении нового звукового метода обучения в мусульманских школах города Казани. В этой статье сообщалось о том, что Галимзян Ба-

руди ввел данный метод для облегчения усвоения начального образования в своей школе. Также было написано, что этот великий имам открыл ещё одну школу для девочек-сирот. Было подчеркнуто, что в мужской и женской школах обучение велось достаточно успешно благодаря созданной им грамматики родного языка и написанным книгам для детского чтения. Эта опубликованная статья в газете свидетельствует именно о школе Махруй ханым.

Выпускница Гылмутдинова Тоффак с благодарностью воспоминает годы обучения в школе Махруй ханым: «Школа Махруй ханум находилась на 1 этаже дома, где проживала ее семья. А сам дом находился на пересечении улиц Г.Тукая и Парижской коммуны. Нижний этаж дома полностью был отдан школе. В одной большой комнате находилась школа, а в другой – интернат и общежитие для девочек.

Я, ребенок из бедной семьи, приехала в Казань из деревни. В 1902-1903 годах обучалась и проживала в интернате Махруй ханым. Пять девочек, таких же, как и я, жили в школе-интернате, нас кормили и одевали за счет Махруй ханым. Мы обучались не только чтению и письму на татарском языке, но и изучали арабский и персидский языки, арифметику».

Примечательно то, что, когда на повестке дня встал вопрос расширения медресе «Мухаммадия», Махруй ханым вместе со своими родственниками также внесла свою лепту, пожертвовав две тысячи рублей, а ее брат Габдулла Утямяшев – 4 тысячи рублей. На средства меценатов было построено двухэтажное деревянное здание на выкупленном земельном участке по соседству с медресе.

Махруй ханум все свое богатое наследство вкладывала в развитие и нужды медресе.

После ее смерти Шехер Шараф – выпускник медресе, помощник и друг Г.Баруди, отметил, что в ее расходных тетрадях содержались отчеты о размерах пожертвований и помощи. Эти записи показывают сколько средств были направлены на приобретение учебников для шакирдов и обучение одаренных воспитанников медресе «Мухаммадия», снабжение учебными пособиями и оборудованием окрестных новометодных школ, построенных в нескольких деревнях на средства меценатов.

Данный факт говорит об аккуратности, дисциплинированности и большом уме этой женщины.

Махруй ханым заботилась и о повышении квалификации преподавателей медресе «Мухаммадия». На ее средства учитель медресе Джихангир эфенди и помощник мударриса Рахим Ханафи – руководители начальных классов, прошли обучение в Стамбуле, мударрис старших

классов Ахмеджан Мустафа посетил Стамбул, Каир и Бейрут. Шехер Шараф и имам города Буинска Абдулла хазрат в 1904 году посетили Стамбул и ознакомились с порядками средних и подготовительных школ также на эти средства.

Перед смертью она завещала отправить вместо себя в хадж человека, способного перенять полезные знания за границей. На эти средства известный ученый Тагир Ильяси учился четыре года в Стамбуле, Каире и Хиджазе. После возвращения он работал учителем, директором медресе Хусаиния, стал профессором Казанской Восточной академии, имамом мечети «Марджани» в Казани, честно служил татарскому народу.

Эта удивительная женщина своей эпохи умерла 4 мая 1904 года в возрасте 44 лет.

**Т.Р.Шакирова,**
*директор МБОУ «Школа №71» г.Казани*

# ПРОГРАММА
# РЕСПУБЛИКАНСКИХ ПЕДАГОГИЧЕСКИХ ЧТЕНИЙ, ПОСВЯЩЕННЫХ ВЫДАЮЩИМСЯ ТАТАРСКИМ ПРОСВЕТИТЕЛЯМ, ПЕДАГОГАМ И ОБЩЕСТВЕННЫМ ДЕЯТЕЛЯМ «ВЕНЕЦ ТВОРЕНИЯ…»

| | | |
|---|---|---|
| **8.00 – 8.55** | **Регистрация**<br>**Экскурсии**<br>• Музей истории и культуры народов Республики Татарстан<br>• Музей Артема Айдинова | **Халикова Г.Г., Сагдиева Р.Ф.** Руководители музеев МБОУ «Школа №71» г.Казани |
| **9.00** | **Открытие педагогических чтений**<br><br>***«Венец творения…»*** | **Шакирова Т.Р.,** директор МБОУ «Школа №71» г.Казани<br>**Литинский С.И.,** директор МБУДО «Детская школа искусств №3» Ново-Савиновского района г. Казани |
| **10.30-12.00** | **Работа секций** | |
| **Секция**<br>**Кабинет 2.6**<br><br>**Ведущая идея** | **Современный взгляд на педагогические идеи татарских просветителей**<br><br>«Әдип вә галимнәре булмаган кавем бәхетсез, мәшһүр кемсәләрен оныткан халык көчсез, әдәбияты булмаган милләт рухсыз.»<br>*Ризаэддин Фәхреддин* | **Председатель**<br>**Биктимирова А.Р.,** руководитель отдела социального развития Духовного управления мусульман Республики Татарстан, к.ф.н.<br>**Сопредседатель**<br>**Фахрутдинова А.Р.,** заместитель директора по учебной работе по вопросам МАОУ «Гимназия №37» г.Казани, к.ф.н. |
| **Секция**<br>**Кабинет 2.5**<br><br>**Ведущая идея** | **Функциональная грамотность – современный вызов для образования**<br><br>«Педагоги не могут успешно кого-то учить, если в это же время усердно не учатся сами.»<br>*Али Апшерони* | **Председатель**<br>**Николаевская И.А.,** методист информационно-методического отдела Управления образования ИКМО г. Казани<br>**Сопредседатель**<br>**Фатхутдинова Г.А.,** директор МБОУ «Школа №43» Ново-Савиновского района г. Казани |

| | | |
|---|---|---|
| **Секция Кабинет 2.7**<br><br>**Ведущая идея** | **Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә функциональ грамоталык формалаштыру**<br><br>«Кешегә бетмәс – төкәнмәс иҗат чыганагы салынган. Менә шул чыганакны ачарга, ireккә чыгарырга, кешегә иҗтимагый тормышта урынын табарга булышырга, аңа үсү өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк.»<br>*Л.Н.Толстой* | **Председатель**<br>**Зиннатуллин Р.К.,** методист по национальному образованию Управления образования ИКМО г.Казани<br>**Сопредседатель**<br>**Ильясова И.М.,** методист УМС ИМО Управления образования г.Казани по Авиастроительному и Ново-Савиновскому районам |
| **Секция Кабинет 2.10**<br><br>**Ведущая идея** | **Современные педагогические технологии в системе образования**<br><br>«Мои ученики будут узнавать новое не только от меня; они будут открывать это новое сами, моя главная задача – помочь им раскрыться, развить собственные идеи.»<br>*И.Г.Песталоцци* | **Председатель**<br>**Бронникова Э.К.,** заведующая УМС ИМО Управления образования ИКМО г.Казани по Авиастроительному и Ново-Савиновскому районам<br>**Сопредседатель**<br>**Григорьева Ю.П.,** заместитель директора МБОУ «Школа №71» г.Казани |
| **Секция Кабинет 2.2**<br><br>**Ведущая идея** | **Организация инклюзивного образования обучающихся с ОВЗ**<br><br>«Вероятно, человечество победит раньше или позже и слепоту, и глухоту, и слабоумие. Но гораздо раньше оно победит их социально и педагогически, чем медицински и биологически.»<br>*Л.С. Выготский* | **Председатель**<br>**Юлтыева Н.Е.,** старший методист по ЦСО ИМО Управления образования г.Казани<br>**Сопредседатель**<br>**Егорова Ю.М.,** директор МБОУ «Школа №25» Ново-Савиновского района г. Казани |

| | | |
|---|---|---|
| **Секция Кабинет 2.3**<br><br>**Ведущая идея** | **Внеурочная деятельность и дополнительное образование как неотъемлемая часть образовательного процесса**<br><br>«И воспитание, и образование нераздельны. Нельзя воспитывать, не передавая знания, всякое же знание действует воспитательно.»<br>*Л.Н. Толстой* | **Председатель**<br>**Лазарева А.А.,** главный специалист Отдела образования УО ИКМО г.Казани по Ново-Савиновскому и Авиастроительному районам<br>**Сопредседатель**<br>**Вахитова И.А.,** директор МБОУ «Гимназия №4 с татарским языком обучения» Кировского района г.Казани |
| **Секция Кабинет 2.11**<br><br>**Ведущая идея** | **Дәрестән тыш эшчәнлек һәм өстәмә белем бирү**<br><br>«Яшь талантларның беренче авазларын сез мәктәп залларыннан ишетерсез. Дөньяга сирәк килә торган Тукайларның яшьлеге сезнең кулда.»<br>*Сибгат Хәким* | **Председатель**<br>**Юнусова Э.Н.,** директор МБОУ «Школа №113» Ново - Савиновского района г.Казани<br>**Сопредседатель**<br>**Мухаметзянов И.М.,** член союза писателей России, лауреат республиканской премии им.Каюма Насыри, к.ф.н. |
| **Секция Кабинет 4.5**<br><br>**Ведущая идея** | **Ценности современной начальной школы**<br><br>«Личность не воспитывается по частям, она создается синтетически всей суммой влияний, которым она подвергается.»<br>*А.С.Макаренко* | **Председатель**<br>**Ахсанова Р.В.,** методист УМС ИМО Управления образования ИКМО г. Казани по Ново-Савиновскому и Авиастроительному районам<br>**Сопредседатель**<br>**Ахмадуллина А.И.,** методист УМС ИМО Управления образования ИКМО г. Казани по Ново-Савиновскому и Авиастроительному районам |

| | | |
|---|---|---|
| **Секция**<br>**Кабинет 4.4**<br><br>**Ведущая идея** | **Дошкольное образовательное учреждение и школа: преемственность и развитие**<br><br>«Когда думаешь о детском мозге, представляешь нежный цветок розы, на котором дрожит капелька росы. Какая осторожность и нежность нужны, чтобы, сорвав цветок, не уронить каплю»<br>*В.А.Сухомлинский* | **Председатель**<br>**Сагадеева О.А.**, заведующая МАДОУ «Детский сад №306 комбинированного вида» Ново-Савиновского района г. Казани<br>**Сопредседатель**<br>**Шарибзянова Н.Т.,** Почетный работ-ник общего образования Российской Федерации |
| **12.30**<br>**Персона**<br> | **Фёдорова Тамара Трофимовна** – почётный работник общего образования Российской Федерации, заслуженный учитель Республики Татарстан, к.п.н., директор УПО «Колледж «ТИСБИ» | **Якупова С.А.,** педагог дополнительного образования МБУДО «Центр детского творчества» Ново-Савиновского района г. Казани |
| **14.00**<br>**Подведение итогов** | **Подведение итогов работы секций** | **Председатели секций** |

# Современный взгляд на педагогические идеи татарских просветителей

## УКЫТУ – ТӘРБИЯ ПРОЦЕССЫНДА РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН ХЕЗМӘТЛӘРЕН КУЛЛАНУ

**Акперова Сирена Минделевна**
*Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «7нче гимназия» Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Эзләнү эшенең бурычлары:**

1. Күренекле фикер иясе, мәгърифәтче галим, язучы, журналист, дин әһеле Ризаэддин Фәхреддиннең иҗаты белән танышу, аның әсәрләрендәге рухи-әхлакый тәрбия алымнары белән таныштыру.
2. Хезмәтләрендә рухи-әхлакый сыйфатларны күрә белергә өйрәтү.
3. Мөгаллимнең тәрбия-әхлак кануннарын өйрәнү, укучыларга әхлак тәрбиясе бирүгә юнәлтү.

Хәзер җәмгыятьтә әхлак мәсьәләсе җитди тора. «Алай эшләмә», «тегеләй итмә» кебек кисәтүләр бала колагында даими яңгырап тора. Ә ни өчен алай ярамаганны аңлата алабызмы? Халкыбызның акыл иясе Риза Фәхреддиннең зирәк фикеренә колак салыйк: «Бала чакта алган тәрбияне соңрак бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас», – дип кисәтә ул. Ризаэтдин Фәхреддинның барлык китаплары, бигрәк тә тәрбия-тәгълим юнәлешләрендәгеләре, халык арасында бик танылган һәм киң таралган. Бу китаплар нәшриятта кабат-кабат басылып чыккан. Тәрбия китапларында пакълек, төрле авырулар, ашау-эчу кагыйдәләре, өс һәм аяк киемнәрен карау һәм башкалар хакында мәгълүмат һәм киңәшләр китерелә. Бу китапларда тәрбия фәненең нигезләре кертелгән, аларның бар кыйммәте – аңлаешлы итеп язу һәм кеше тәрбияләүнең җаваплы бер эш икәне исбат ителә. Бала мәктәпкә кадәр үз тирә-ягындагы мохит тәэсирендә формалаша. Моны табигать мизгелләре белән чагыштырырга мөмкин: билгеле бер вакытта гына кояш чыга, көн туа, яз килә һ.б. Кеше аңының, әхлагының формалашуы да эзлекле рәвештә бер вакытка туры килә. Шул моментны үткәрдекме – соңга калуыбыз да бик мөмкин. Һәр кеше әйләнә-тирәдәгеләрнең шатлыкларына һәм хәсрәтләренә игътибарлы булырга,

ямьсезлектән йөз чөерергә өйрәнергә тиеш. Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән әхлак мәсьәләләре – намус, гаделлек, җирдә дөрес итеп яшәү, əти-əни һәм Ватан алдындагы изге бурычны үтәү кебек төшенчәләр мәңгелек, һәркем өчен уртак. Аларны үзебездә булдыру өчен Кеше булу кирәк. Мине дә бу хәл бик борчый. Байлык, акча артыннын куу чорында без үз кыйблабызны, буыннын – буынга килгән тәрбия кагыйдәләрен онытмыйбызмы? Тәрбия эшендә иң мөһиме – балага карата һәр эштә төгәл булу, аңа якын килә белү. Яшь буынны югары әхлак сыйфатларына ия булган мәдәниятле кешеләр итеп тәрбияләп, аны олы тормыш юлына әзерләүне Р.Фәхреддин дә җәмгыятебезнең иң мөһим эше дип санады.

Шуңа күрә эзләнү эшемдә Риза Фәхреддиннең китапларындагы әхлак темасының бирелешен өйрәнүне алдым.

## ПЕДАГОГИЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ ВЕЛИКОГО ТАТАРСКОГО ПРОСВЕТИТЕЛЯ КАЮМА НАСЫРИ В КОНТЕКСТЕ СОВРЕМЕННОСТИ

**Галимова Гюзель Хакимовна**
*МБОУ «Лицей №177»*
*Ново-Савиновского района г.Казани*
*Учитель русского языка и литературы*

Цель: определить, какое значение имеет педагогическое наследие татарского просветителя Каюма Насыри.

Задачи:

– изучение материалов, отражающих основные этапы педагогической деятельности К.Насыри; научной деятельности и личной жизни великого просветителя.

– обзор вопросов, касающихся проблемы сформированности эмоционально-ценностного отношения к миру, труду, другим людям и самому себе у учащихся, подготовленных к успешной жизни;

– диагностика контингента учащихся (родителей, семей), проведение их дифференциации по материальному положению, по структуре и типу семьи, по характеру проблем, выявление общего состояния и уровней эмоционально-ценностного отношения старшеклассников к семье;

– выявление факторов, оказывающих влияние на формирование личных качеств и способностей, составляющих основу жизнеспособной и гармоничной личности.

В качестве показателей сформированности эмоционально-ценностного отношения выступали широта ценности, эмоциональное принятие ценностей (потребности, мотивы и интересы); когнитивный (знание о ценностях); поведенческий (поступки).

В соответствии с целями и задачами был выделен ряд базисных блоков, объединяющих сходные ситуации в проблемах воспитания: это сложные отношения с родителями, конфликтные отношения со сверстниками, снижение престижа учебы, разброс во мнениях о ценностях (духовных и материальных). Каждый человек заинтересован в том, чтобы занять достойное место в жизни, чувствовать себя уверенно и защищенно в постоянно меняющемся обществе. А это возможно благодаря знаниям, личным качествам, способностям, составляющим основу жизнеспособной личности.

**Актуальность исследуемой проблемы** определяется значительными переменами в жизни, в общественном устройстве страны. Эти перемены сегодня оказывают существенное влияние на формирование ценностных, гуманистических ориентаций на личность. Поиск пути заставляет обращаться к традиции, представителем которой был Каюм Насыри.

Современное обращение к творческому наследию «татарского Леонардо да Винчи», ученого энциклопедического дарования – Каюма Насыри (1825–1902) – неслучайно. Дело в том, что многие, поднятые им проблемы, оказались созвучными сегодняшним реалиям. Он оставил большой пласт творческого наследия, связанный с этнологией, историей, литературой, повседневностью и бытом татарского народа, системой воспитания и образования. Среди нравственных качеств, ценимых татарским просветителем, можно выделить скромность, искренность, трудолюбие, ум, послушание, бодрость духа, располагающие к себе человека, тем самым оставляя памятный след о нем.

Мыслитель считал, что предпочтительнее всего учиться у людей мудрых и умных. «Послушать мудреца – удовольствие для души, словно бы постоять возле лавки торговца благовониями: хотя и не перепадет тебе ничего, зато вволю ароматом надышишься», но не стоит тратить время на беседу с незнающим и злым человеком.

«Истинным мужеством» исследователь называет «умение простить», что оказывается возможным благодаря способности адекватно ориентироваться в ситуации.

Каюм Насыри считает, что человек разумный должен уметь прогнозировать ситуацию, предвидя ее позитивные и негативные последствия, и рассчитывать свои силы в доведении любого начатого дела до конца,

что также является нравственным арсеналом личности. Он пишет, «кто думает о последствиях, избавит себя от многих бед и огорчений», поэтому «прежде чем войти, подумай, как выйти», а «открывая дверь, подумай.

Еще одной характеристикой идеального человека была способность трудиться: «человек никогда не должен оставаться без заботы и труда.

Пропагандируя знания различных наук, К. Насыри имел своей целью воспитать и образовать человека, соответствующего уровню развития своей эпохи. Неслучайно он особо пишет о личности воспитателя (вариант конфуцианского цзюнь-цзы), считая, что он закладывает жизненную программу в своих воспитанников. «Если ты педагог и воспитатель, так воспитывай своих подопечных, чтобы твое воспитание сказывалось на них до конца их жизни» Ученый закладывает и методику обучения, основанную на мнемонике: «каждое услышанное слово нужно запоминать и постепенно, слово за словом, положить их в казну памяти».

По мнению татарского просветителя, каждый человек должен обладать знаниями, чтобы применять их в своей практике. Он справедливо замечает: «Человек, выполняющий работу без науки – это все одно, что человек, путешествующий без дорог», потому что «невежество – качество, сближающее с животным. Невежественному человеку нигде нет почета» и научной деятельностью, нравственной позицией и творчеством, стали причинами долголетия этих людей. Оба деятеля (немецкий и татарский) восприняли эстафету ценностей от мыслителей прошлых эпох, в основе которых заложена триада Истины, Добра и Красоты, пронесли ее через свою жизнь, распространяя среди современников, и передали будущим поколениям в виде творческого наследия

Подводя итоги, подчеркнем следующие моменты. Своей личностью и на страницах своих трудов Каюм Насыри воссоздал на татарской почве образ идеального человека, тем самым (неосознанно/осознанно) осуществив реконструкцию взглядов древневосточного мудреца Конфуция о «благородном муже». Татарский просветитель своей жизнью явил нравственный подвиг человека, мужественно отстаивавшего свои идеи и не отказавшегося от них, тем самым сохранив чистоту своих помы слов и принципиальность жизненной позиции.

# ТАТАР МӘГАРИФЕНЕҢ ГҮЗӘЛ ЭНҖЕЛӘРЕ

**Гыймадиева Гузәл Илдус кызы**
*МАОУ «Гимназия-интернат №4»*
*Киров районы Казан шәһәре*
*Педагог-китапханәче*

**Онытырга хакыбыз юк**

Безнең бай рухи мирасыбыз, мәгърур матбугатыбыз һәм бер үк вакытта хатын-кызларыбыз хәрәкәтендә мәңге җуелмас эз калдырган шәхесләребез бар. Тик халкыбызның гаять бай тарихлы булуын, ни кызганыч, бары соңгы елларда гына аңлый башладык шул. Тарихыбызның, андагы шәхесләрнең, шул исәптән зыялы кызларыбызның да тормыш юлларын гаять дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуы нинди аяныч нәтиҗәләргә китерде...

Фатыйха Аитова, Ләбибә Хөсәения, Мөхлисә Буби... **(1нче кушымта).** Изге күңелле мәгърифәтче хатын-кызларыбыз татар кызларына беренче җәдид мәктәпләрен ачканнар. Мәктәпләр бары тик байлар һәм мәхәллә халкы хисабына гына яши алганнар. Халыкның аң-белемгә омтылышын күреп, татар байлары яңа мәктәп-мәдрәсә ачу өчен акча кызганмаганнар. Мәктәпләрдә дин белеменнән тыш дөньяви фәннәрне дә (математика, физика, химия, география, тарих, чит телләр) укытканнар. Татар рухи мәдәниятен үстерү юлында берничә буыннар дәвамында хезмәт күрсәткән аерым шәхесләр, бөек шагыйрьләребез, язучыларыбыз, галимнәребез, тарихчылар, хәтта аерым нәселләр бар. Халыкны аң-белемле итүдә күренекле шәхесләребез Гаяз Исхакый, Шиһабетдин Мәрҗәни, Фәхреддиновлар нәселе, Йосыф Акчура, Исмагыйль Гаспралы, Апанаевлар, Яушевлар, Юнусовлар, фабрикант Акчуриннар, кебек зур сәнәгатьчеләр булганнар (**2нче кушымта).** Алар мәчетләр төзүгә, мәктәпләр, мәдрәсәләр ачуга йөзәрләгән мең акчаларын химая иткәннәр, уннарча уку йортларын үз акчаларына яшәткәннәр, аеруча сәләтле шәкертләрне чит ил уку йортларына югары белем, тәҗрибә туплау өчен җибәргәннәр. Ләкин татарларның укымышлы кызларын да, аларның туган халкына күрсәткән хезмәтләрен дә һич онытырга ярамый.

**Татар мәгарифенең гүзәл энҗеләре**

XX гасыр башы... Гаҗәеп заман, искиткеч кешеләр... XX гасыр башы – халкыбыз тарихының иң матур, шөһрәтле чоры дияр идем. Бу чор- мәгърифәтчелек чәчәк аткан, милли матбугатыбыз тормышыбызда әһәмиятле урын токан, хөр фикерле иҗат интеллигенциясенең яшь бер

буыны катлам булып барлыкка килгән һәм иң мөһиме – халкыбызның милли рухы көчле вакыт.

Казан шәһәре Киров районында урнашкан 4нче гимназия-интернатның тәрбия эшчәнлегендә 12 ел дәверендә «Мәгърифәт йолдызлыгы» проекты эшләп килә. Бу проектның авторы һәм җитәкчесе буларак әйтә алам – аның барлыкка килүе очраклы түгел, гимназиябездә кызлар гына белем ала. Безгә татар мәгарифе, аеруча хатын-кызлар мәгарифе тарихы бик тә кызыклы һәм әз өйрәнелгән булып тоелды.

Аның максатлары: халкыбызның тарихын өйрәнү, саклау, үстерү, укучыларда милләткә һәм туган илгә карата ихтирам тәрбияләү, милли үзаң формалаштыру. Татар мәгърифәтчесе, галим Ризаэддин Фәхреддин болай дигән: «Яхшы тәрбияле, киң белемле кызлар гына чын «милләт аналары» булып җитешәчәк һәм киләчәктә милләтне алга алып барырлык шәхесләр тәрбияләчәк». Безнең проектыбызның эшчәнлеге бу фикерне дәлилләп, укучы кызларыбызны белемле, әхлакле, гүзәл холыклы булып тәрбияләргә ярдәм итә. Укучы кызлар белән архивларда, музейларда булып, китаплар һәм журналларда аларга багышланган чыганаклар эзләп, күп кенә материаллар туплыйбыз.

Фатыйха Аитова мәктәбе укыту программасыннан алып, шул вакыттагы уку әсбапларына таянып, тарихи торгызылган дәресләр әзерлибез. Әхлак, тыйб (медицина), кул эшләре, хисаб һ.б., Каюм Насыйриның «Әнмүнәҗ» дәреслеге буенча татар теле грамматикасы дәресләре күрсәттек.

Проектыбыз кысаларында без 10 ел фәнни-гамәли конференцияләр уздырабыз. Бүгенге көндә алар халык-ара дәрәҗәсендә үткәрелә. Чараларыбызны Бөтендөнья Татар конгрессы, Казан Федераль Университеты филология факультеты белән берлектә әзерлибез. Гасыр башында кызлар өчен мәктәпләр ачыла башлаганга 100 елдан артык вакыт узу сәбәпле, без татар мәгърифәтчеләренең мирасларын барлап, параллельләр уздырып, киләчәгебез турында уйланабыз. Конференция кысаларында укучы кызлар өчен «Асылташ» конкурсы уздырабыз.

Гимназиябездә татар мәгарифе тарихына багышланган музеебыз эшләп килә. Кызларыбыз белән фәнни эзләнүләр алып барабыз, архивларда, китапханәләрдә бу темага кагылышлы документлар, мәкаләләр белән танышабыз. Татар мәгарифе тарихына багышланган фәнни эшләребезне төрле дәрәҗәдәге укучылар һәм укытучылар конференцияләренә җибәреп, уңышлы гына яклыйбыз. Укучы кызларыбыз Мәскәүдәге «Вышгород», «Маркеловские чтения» исемле гуманитар конференциядә фәнни хезмәтләре белән беренче урыннарны алалар. Әле узган елның

апрелендә укучыбыз Сайдә Мөхәмматҗанова «Мәгърифәт йолдызлыгы» проекты буенча фәнни эш белән Мәскәүдә Вернадский исемендәге Бетөнроссия укуларында I дәрәҗәле дипломга, ә Бөтенроссия «Вышгород» конференциясендә III дәрәҗәле дипломга лаек булды. Комиссия әгъзалары – Мәскәү университетының укытучылары бу тема белән бик кызыксынып, Сайдәгә өстәмә сораулар биреп, безгә бу шәхесләрегез турында мәгълүматлар бик кызыклы диеп, әнгәмә корганнар. Димәк, татар мәгърифәте тарихы белән мәскәүлеләр дә тагын бер тапкыр хәбәрдар булдылар.

Мәгърифәт учагы буларак, Казанның 4нче гимназия-интернаты хөрмәтле беренче президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең уй-нияте белән булдырылды. Төрле елларда бу уку йортын тәмамлап, кызларыбыз югару уку йортларында белем алып, туган йортларына әйләнеп кайткан кебек, гимназиягә балаларны укытырга кайталар. Аларның төп бурычлары, гомүмән монда эшләүче һәрберебезнең дә, мәгърифәтле, мәдәниятле, әхлакле, үз милләтенең мәнфәгатьләрен кайгыртучы кыз-балалар тәрбияләү.

**Игелекле татар байлары**

Хәйриячелек – кешелек уйлап тапкан, диннәр хуплаган, хәтта кушкан изге гамәлләрнең берсе. Бәлки, бу дөрестер дә. Хәйриячелек һич тә афишалап башкарыла торган эш түгел. Татар мәкале дә «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык күрмәсә, балык күрер» ди. Урамга чыгып кычкыргач, гамәлнең изгелегеннән бернәрсә дә калмый ич…

19 гасырда бик күп кенә реформалар үткәрелә. Мөселманнарга мәчетләр салырга рөхсәт ителә, татар сәүдәгәрләре эшчәнлекләрен җәелдереп хәтсез генә акча туплый, милли капитал барлыкка килә.

1998 елда татарларга махсус «Мөселман хәйрия җәмгыятьләре» төзергә мөмкинлек ачыла. Җәмгыятьнең попечительләре булып отставкадагы генерал-майор Мөхәммәтшәфыйк Шамил, Әхмәт Гани улы Хөсәенов һәм башкалар булалар (**3нче кушымта**). Җәмгыятьләрнен төзелүе патша хөкүмәтеннән бер тиен ярдәм ала алмаган татар халык мәгарифе үсеше өчен дә шифалы яңгыр кебек була.

Игелекле татар байлары ярдәмендә кызлар өчен мәдрәсәләр, дин гыйлеме белән бергә дөньяви фәннәр дә укытылган мәктәпләр ачыла.

Дөньяви белем бирү яклылар арасында Әхмәт һәм Гани Хөсәеновлар, Юнусовлар, Шакир һәм Закир Рәмиевләр, фабрикант Акчуриннар, Үтәмешевләр, Азимовлар кебек зур хәйриячеләр, сәнәгатьчеләр булганнар. Алар мәчетләр төзүгә, мәктәпләр, мәдрәсәләр ачуга йөзәрләгән мең акчаларын химая иткәннәр, уннарча уку йортларын үз акчаларына

яшәткәннәр, аеруча сәләтле шәкертләрне чит ил уку йортларына югары белем, тәҗрибә туплау өчен җибәргәннәр һ. б.

Оренбург хәйрия җәмгыятен оештыручы атаклы Хөсәеновларга татар мәгарифенә ярдәм оештыру эшендә дөньяда тиңнәр булыр микән? Оренбург губернасында 200ләп мәктәп-мәдрәсәне уку-укыту әсбаплары белән тәэмин итү, 40ләп мөгаллимгә эш хакы түләү, Петербург, Мәскәү, Томск, Каһирә, Бейрут, Истамбул югары уку йортларына ел саен 20ләп татар яшьләрен җибәреп, уку өчен матди шартлар тудыру – алар эшләгән изге эшләрнең бик азы гына әле. Алар мәчетләр төзүгә, мәктәпләр, мәдрәсәләр ачуга йөзәрләгән мең акчаларын химая иткәннәр, уннарча уку йортларын үз акчаларына яшәткәннәр, аеруча сәләтле шәкертләрне чит ил уку йортларына югары белем, тәҗрибә туплау өчен җибәргәннәр һ. б. Бик олы мөлкәтләргә ия булмасалар да, милли мәгърифәтне үстерүгә, мохтаҗларга ярдәм итүгә һ. б. сизелерлек өлеш кертүче башка химаячеләрнең исемнәрен дә тарих саклап калган. «Ак байлар» – Акчуриннар, Апанаевлар, Хөсәенов, Мөхәммәтсадыйк Борнаев – хәйриячелекләре аркасында татар тарихына мәңгегә кергән игелекле җаннар. Алар барысы да бик диндар кешеләр булган.

Габдулла Габделкәрим улы Апанаев Г.Барудига ияреп, Печән базары мәдрәсәсенә яңа ысуллы укыту системасы кертә. Мөхәммәтвәли Муса улы Апанаев кына да 4000 сум табышны мәдрәсәләргә бүләк иткән.

Совет власте урнашкач, Апанаевларны бер-бер артлы үлемгә – атылуга дучар ителәләр. 1918 елда Габдулла Апанаев, 1937 елда Габделхәмит Исхак улы Апанаев, Гарун Апанаев, 1938 елда Исмәгыйль Апанаев, Якуб Апанаев атып үтерелә. Үз көчләре белән тапкан, төзегән, булдырган, байлыкларын ярлы халык белән бүлешкән чын шәхесләр булган бит алар. Ватаныбызның берәр почмагын, урамына Апанаевлар исемен бирү дә артык булмас. Моңа алар, һичшиксез, лаек.

Бик олы мөлкәтләргә ия булмасалар да, милли мәгърифәтне үстерүгә, мохтаҗларга ярдәм итүгә һ. б. сизелерлек өлеш кертүче башка химаячеләрнең исемнәрен дә тарих саклап калган. Мәсәлән, Җ.Сәгъдиев дигән сәүдәгәр Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсенә – 10 мең сум, мәчетләр һәм мәдрәсәләр төзелеше өчен шулай ук 10 мең сум, Казан хәйрия җәмгыятенә 2 мең сум, бу җәмгыятьнең бала тудыру шифаханәсе бүлегенә 3 мең сум иганә иткән.

Фабрикант һәм сәүдәгәр Ибраһим һәм Исхак Юнусовлар мөселман балалары йорты чыгымнары өчен Печән базарында урнашкан һәм елына 14 мең сум табыш бирә торган кибетләрен биргәннәр. Приют каршында мәктәп ачылган, анда балаларга замана өчен кирәкле дини һәм дөньяви

белем бирелгән. Үз акчасына балалар йорты тоткан Ибраһим Юнусовны III дәрәҗә Изге Анна ордены, абыйсы Исхакны III дәрәҗә Изге Станислав ордены һәм алтын медаль белән бүләкләгәннәр.

Безнең гимназиябездә тәрбияләнүче кызларыбыз үз нәсел тамырларын барлап, горурлык белән хәтерләрендә саклыйлар.

Троицк сәүдәгәрләре Яушевлар гаиләсендә туып үскән Фатыйха Аитованы онытып буламы...(**4нче кушымта).** Ул Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитовка кияүгә чыканда, үзенә гаиләдән бирелгән малны кызлар мәктәбе ачуга сарыф итү белән генә калмыйча, Казанда 1916 елда шул мәктәпне кызлар гимназия дәрәҗәсенә кадәр үстерә.

Бүген дә татар халкының мәгариф өлкәсендә ихтыяҗлары зур, ярдәм кылу артык булмас иде, аның өчен шәфкатле, миһербанлы гына булу кирәк.

Безнең гимназиябездә укыту һәм тәрбия эшендә 10 ел дәверендә кулланыла торган проектларыбызның берсе – «**Мәгърифәтчелек йолдызлыгы**». **(5нче кушымта).** Проектның максатлары: халкыбызның рухи һәм мәдәни кыйммәтләрен саклау, үстерү, татар мәгарифе (аеруча хатын-кызлар мәгърифәте) тарихын өйрәнү, милли мәгърифәтне үстерүдә зур өлеш керткән татар хәйриячеләрнең исемнәрен яңартып, укучыларда милләткә һәм туган илгә карата ихтирам тәрбияләү, милли үзаң формалаштыру.

Бу проектның гимназиябездә барлыкка килүенең сәбәпләре күп. Уку йортыбызда кызлар гына белем ала, татар хатын-кызлары мәгърифәтчелеге тарихы безгә аеруча якын һәм кызыклы. Гасыр башында кызлар өчен мәктәпләр ачыла башлаганга 100 елдан артык вакыт узуы сәбәпле, без аларның мирасларын барлап, параллельләр уздырып, киләчәгебез турында уйланабыз.

Укучы кызлар белән архивларда, музейларда булып, китаплар һәм журналларда аларга багышланган чыганаклар эзләп, күп кенә материаллар туплыйбыз.

Бу темага багышлап һәр ел саен республика, халык-ара күләмендә укытучыларыбызны, мәърифәтчеләребезне чакырып, фәнни-гамәли семинарлар, конференцияләр уздырабыз. Фатыйха Аитова мәктәбе укыту программасыннан алып, шул вакыттагы уку әсбапларына таянып, тарихи торгызылган дәресләр әзерлибез: **Әхлак, тыйб (медицина), кул эшләре, хисаб һ.б., Каюм Насыйриның «Әнмүҗәҗ» дәреслеге буенча татар теле грамматикасы дәресләре.**

Чараларыбызны Бөтендонья Татар конгрессы, Казан Федераль Университеты филология факультеты белән берлектә әзерлибез. Конференция кысаларында укучы кызлар «Асылташ» конкурсы уздырабыз.

«Мәгърифәт йолдызлыгы» проектында катнашучы кызларыбызны V бөтендөнья татар хатын-кызлары корылтаенда сәхнәгә чакырып алкышладылар **(6нчы кушымта).**

Олы рәхмәтебезне галимә, язучы Биктимирова Тәэминә Әхмәт кызына әйтәсе килә. Тәэминә апаның бөтен мәкаләләре, ачы һәм катлаулы татар тарихын, мәгърифәт тарихын барлап язган барлык китаплары безнең эш өстәлендә һәрвакыт түрдә тора. «Ил язмышын салып иңнәренә» исемле китабында Тәэминә апа игелекле татар хәйриячеләрнең татар мәгърифәте үсешенә керткән зур өлешләрен искә төшереп яза. Мәгърифәт эшенә барлык көчен сарыф иткән татар хатын-кызларының сокландыргыч эшчәнлеге, аларның язмышлары турында ул йөрәгеннән үткәреп, горурланып яза.

**Кызлар язмышы – милләт язмышы**

Мәгърифәт учагы булган безнең уку йортыбыз (Казан шәһәре 4 нче гимназия-интернаты) да иң беренче буларак хөрмәтле беренче президен-тыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең уй-нияте белән булдырылды. Аның изге ниятен тормышка ашыруда фидакяр хәйриячеләрнең шәхси матди-мәгънәви ярдәмнәренең өлешләре зур булды. Гимназиябездә конкурслар үтеп, төрле төбәкләрдән килгән, сәләтле кызлар гына белем ала. Төрле елларда бу уку йортын тәмамлап, кызларыбыз югару уку йортларында белем алып, туган йортларына әйләнеп кайткан кебек, гимназиягә балаларны укытырга кайталар. Аларның төп бурычлары, гомүмән монда эшләүче һәрберебезнең дә, мәгърифәтле, мәдәниятле, әхлаклы, үз милләтенең мәнфәгатьләрен кайгыртучы кыз-балалар тәрбияләү.

Татар кызы дигәч тә, аның тарихтагы урыны искә төшә. Бик борынгыдан затлы нәсел кызлары татарның милли байлыгы булган татар кызына өйләнү башка халыклар арасында да зур мәртәбә саналган. Дөньякүләм билгеле шәхесләрнең я әбиләре, я әниләре юкка гына татар түгел. Димәк бар халыклар да таныган бик мөхим сыйфатларыбыз бар, һәм без аларны югалтмыйча сакларга тиешбез.

**Йомгаклау өлеше**

Бүгенге көндә мәгариф өлкәсенә игътибар итсәк, мәктәпләрдә, балалар бакчасында тулаем диярлек хатын-кызлар хезмәт итә. Бу закончалыклы күренеш. Габдулла Бубый әйткәнчә «Хатын-кыз – бала тәрбияләүдә беренче һәм төп роль уйнаучы шәхес; нәкъ менә ул баланың холык – фигылен формалаштыра, аның акылын һәм эчке дөньясын тәрбияли, аңа беренче һәм төп роль уйнаучы шәхес; нәкъ менә ул баланың холык фигылен формалаштыра, аның акылын һәм эчке дөньясын тәрбияли, аңа беренче әхлакый төшенчәләрне сеңдерә». Киләчәк буынны, акыллы, тәртипле

итеп үстерү бүген дә хатын кызлар кулында. Ләкин бу вазифаны дөрес үтәү өчен, Габдулла Буби әйткәнчә, хатын-кызга иң элек тиешле дәрәҗәдә белемле һәм тәрбияле булырга кирәк. Мәгърифәтче 100 ел элек әйткән бу фикер бүген дә девиз булып яңгырый.

Татар кызы кием-салымы белән дә, йөз-кыяфәте белән дә, күңел хәләте белән дә башкалардан аерылган. Безнең туташларга үз милләте белән горурланып, шул матурлыкны саклап, балаларга мирас итеп буыннан-буынга тапшыру кирәк.

Татар кызлары – милләтебезнең киләчәге, киләчәгебез мәгърифәтле, мәдәниятле булсын иде. Рәзил абый Вәлиев язган шигырь юллары белән тәмамлыйсы килә: «Таңнар атты, ай да батты, уян син халкым, уян! Халкыма тел, хөррият бир, бир ходай безгә иман».

**Файдаланылган әдәбият**

1. Биктимирова Т. А. Ступени образования до Сорбонны. – Казань, 2003. – С.98

2. Биктимирова Т.А . Ил язмышын салып иңнәренә.- Казан, 2006. – С.95-62.

3. Биктимирова Т.А. Хәтерләрне яңартыйк... – Казан, 2012. – С.29-31, 44-46

4. Махмутова А.Х. Милләт аналары. – Казан, 2012. – С.142,147, 156-166, 558

5. Махмутова А.Х. Вакыт инде: без дә торыйк.... – Казан, 2012. – с.138, 140-142,

6. Дәүләтшин Г.М., Хуҗин Ф.Ш., Измайлов И.Л., Татарстан тарихыннан хикәяләр. – Казан: «Мәгариф», 1993.

## РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН ИҖАТЫН УКЫТУ ПРОЦЕССЫНДА КУЛЛАНУ

**Гыйниятуллина Раилә Хәбибулла кызы**
*Казан шәһәре Яңа Савин районы*
*«43 нче урта гомуми белем мәктәбе»*
*гомуми белем муниципаль бюджет*
*учреждениесе*
*Югары квалификацион категорияле*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Кеше – бөек исем!
Шуны аңла, шуны саклый бел.
Тормыш корган сынаулар алдында
Кеше исемен горур йөртә бел.

Кеше ... Бу исем горур яңгырый. Ләкин һәркем аның мәгънәсен аңлап бетерә алалмы икән соң? Юктыр, мөгаен. Әгәр һәркем аның асы-

лына төшеп аңлый алса, безнең арабызда исерек сәрхүшләр дә, тәмәке төтене белән үзенең организмын зарарлаучылар да, авыр сүз әйтеп кеше күңелен яралаучылар да, бигрәк тә, башкаларга гел начарлык кына теләп йөрүчеләр дә булмас иде.

Кеше туа... Тәүге адымнарын атлый. Бер мизгелен дә бушка уздырмыйча тормыш белән танышуын дәвам итә. Үзе дә сизмәстән, киләчәге турында да уйлана башлый. Әти-әнисен таң калдырып, үзенең үсеп җиткәч кем булачагын хәбәр итә. Кем генә булмый ул сабыйлар. Табиб та, очучы да, җырчы да, хәтта президент та. Ләкин тормыш юлына кереп киткәч, алар арасында үзләренең сабый чак хыялларына хыянәт итүчеләр дә еш очрый.

Моны булдырмас өчен укытучылардан һәм әти-әниләрдән бик күп сабырлык, тирән акыл сорала. Бары тик мәктәп белән гаилә берлектә генә баланы әхлаклы, милли хәзинәләребезне ихтирам итүче, тормышка яраклы шәхес итеп тәрбияли ала.

Халкыбыз үзенең яхшы күңелле, зыялы кешеләре белән горурлана. Татар халкында бай иҗади һәм фәнни мирас калдырган шәхесләребез аз түгел. Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезхан, Габденнасыйр Курсави, Ризаэддин Фәхреддиннәрне әйтеп китәргә була.

Шулар арасыннан Ризаэддин Фәхреддингә тирәнрәк тукталып китәргә кирәктер, чөнки аның әсәрләре бүгенге көндә дә үзләренең актуальлекләрен югалтмыйлар. Бу эшемнең максаты итеп, татар халкының иң мәшһүр улларының берсе булган Ризаэддин Фәхреддиннең туган (татар) әдәбият дәресләрен укытканда, хезмәтләрендә чагылыш тапкан мәсьәләләргә, галимнең тәрбия өлкәсенә караган фикерләренә күзәтү ясау, аның эшчәнлеге белән кызыксыну хисләре уяту, гомумкешелек сыйфатлары тәрбияләүне алдым.

Гәрчә бөек шәхесләрне кемнәр беләндер чагыштырып карау дөрес эш булмаса да, аның әдәбиятыбыз өчен куйган хезмәтләренең, мирасының зурлыгын русларның Лев Толстое белән, күп фәннәр буенча эшчәнлеген итальяннарның Леонардо да Винчи белән куеп булыр иде.

Укучыларга әхлак тәрбиясе бирүдә әдәбият дәресләренең роле әйтеп бетергесез. Чөнки әдәбият – бөтен барлыгы белән тәрбия фәне. Р. Фәхреддин бу хакта: «Әхлак белән әдәбият бергә булырлар. Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлагы да шул рәвештә булыр», – дип язды. [1:23].

Әдәбият дәресләрендә әхлак тәрбиясенә караган мәсьәләләрне хәл иткәндә Р. Фәхреддиннең «Балаларга үгет-нәсыйхәт» һәм «Нәсыйхәт»еннән файдаланырга була.

Гаяз Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәрен өйрәнгәндә, Р. Фәхреддиннең «Өйләнү әдәпләре», «Никах вә өйләнү» бүлекләреннән файдалану дәреснең нәтиҗәлелеген тагын да арттырып җибәрә. Бу әсәрләрдән алынган фикерләр укучыларга тормыш итү өчен үз парын сайлаганда дөрес юлны табарга ярдәм итәләр һәм югалып калмаска өйрәтәләр.

Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрен өйрәнгәндә, «Кыз балалар өчен генә», «Тәрбияле хатын», «Тәрбияле бала», «Шәкертлек әдәпләре» бүлекләреннән файдаланырга була. «Ата вә аналарыгыз хозурында бик әдәпле булыгыз, аларның сүзләрен яхшы тыңлагыз, ишарәләрен аңлагыз, алар белән артык кычкырмыйча, әдәпле итеп, ачык сөйләшегез. Алар аягүрә торганда, сез басып тормагыз!..», «Ата-аналарын риза кылучы балалардан Аллаһы Тәгалә дә риза булыр», «И, газиз балалар! Көчегездән килгәнчә аларга чын күңелдән хезмәт итегез һәм хөрмәт күрсәтегез!» [1:157]. Р.Фәхреддиннән алынган бу тирән фикерләр белән танышу инде үзләрен олыларча тотарга омтылган яшүсмерләр өчен киләчәккә зур сабак була, аларны уйланырга мәҗбүр итә һәм өлкән буынга хөрмәт тәрбияли.

«Ана сөте белән кермәгәнне – тана сөте белән кермәс», – ди халык мәкале. Димәк, бөтен бәхет, тәрбия, тәүфыйкълылыкның башы хатын-кызда – анада. Ризаэддин Фәхреддин үзенең «Тәрбияле ана» хезмәтендә: «Аналарның хезмәтләре – язып, тел белән сөйләп бәян кылырлык түгелдер. Яхшы балалар үстергән аналарны һәркем мактыйдыр», – дип яза. Нинди дөрес сүзләр. Галим аналарны ике төргә бүлә: тәрбияле анага һәм тәрбиясез анага. «Тәрбияле аналар балаларын үзләре тәрбияләрләр, мөмкин кадәр башкаларга тапшырмаслар», – ди, чөнки баланы үз анасы кебек беркем дә тәрбияли алмый.

Бүгенге көндә балалары барында башкаларны гаепләп сөйләшүче ата-аналарны еш очратырга була. Мондый гаиләдә тәрбияләнгән балалар киләчәктә үзләрен һәрвакыт хак санап, башкалардан гел гаеп кенә эзләүчән булып үсәләр. Тора-бара ата-аналарына карата да шундый ук начар мөнәсәбәт уяна. Каршылыкка килеп бәрелгән ата-ана кайда гаеп җибәрдем икән, дип уйламый, ә киресенчә, бер гаебе булмаган кешеләргә үзенең ачу, нәфрәт укларын ата башлый: авыр сүзләр белән башкаларны рәнҗетә. Баланы бу исә канатландырып кына җибәрә: ул тагын да катырак итеп көчсезләрне кыерсыта башлый. Киләчәген якты итеп күрергә теләгән ата-ана моңа юл куймаска: башкаларны гаепләп сөйләмәскә тиеш.

Аның «Балаларга үгет-нәсыйхәт» китабында да ата-ана вазыйфасы турында түбәндәге юлларны очратырга була: «Ата-ананың вазыйфасы

бала тудыру белән генә чикләнми. Туган баланы сәламәт итеп үстерү, яхшы тәрбияләү, дине, милләте өчен файдалы итү – ата-ананың иң зур вазыйфаларыннан исәпләнә» [1:42] – ди ул. Бу фикерләр барысы да Ш. Камалның «Буранда» әсәрен өйрәнгәндә дә укытучыга бик зур ярдәмгә киләләр. Ата-ананың бер-берсен аңлый алмавы аркасында таркалган гаиләдә барлык авырлык бала өстенә төшә.

Р. Фәхреддиннең Пайгамбәребезнең Изге Хәдисләренә аңлатма бирү рәвешендә язган зур күләмле «Җавамигуль кәлим шәрхе» исемле китабында адәм баласын дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле итү чарасы булган «гүзәл холык» турында бик төгәл билгеләмә бирелә: «...Гүзәл холыкның кисәкләре бик күп төрле булып, бу заманнарда аерым рәвештә әһәмиятле булганнары шушылардыр:

- Тугрылык... Тугры булган кеше – ышанычлы булыр...
- Үз хатаңны үзең тану...
- Үз фазыйфаңны – үзең белү. Бу сыйфат һәркемнең үзендә булырга, кемдер тарафыннан кисәтеп әйтүне көтеп тормаска тиеш...
- Хакыйкатьне күзәтү. Бу сыйфат – эшләрнең тышкы ягын түгел, ә эчке мәгънәсен күзәтүдә чагыла...
- Үз-үзеңә ышану. Бу сыйфат беркемнән дә ярдәм көтмичә, фәкать үз-үзенә нык ышанган килеш бөтен авырлыкларны җиңеп алга баручы кешедә ачык чагыла...
- Намус. Кешеләрнең бөтен кыйммәтлеге – намуслы булуларында. Адәм балаларын фәрештәләр дәрәҗәсенә күтәрә торган нәрсә – намус булып, хайваннардан да түбән дәрәҗәгә торган нәрсә – намуссызлыктыр...

Шулай итеп, укытучыларның төп бурычы, Р. Фәхреддин сүзләренчә әйтсәк: «...фәкать гыйлем өйрәтү белән генә чикләнмичә, бәлки балаларның күңелләренә сөю, гүзәл гадәтләр, тырышу, эшлеклелек, туганлык, гайрәт, инсафлылык, гүзәл холык, гаделлек, батырлык, җанлылык кебек яхшылык орлыкларын тәмам игътибар белән чәчү вә тәрбияләп үстерү булачактыр.

**Библиографик исемлек**

1. Балаларга үгет-нәсыйхәт. – Казан: «Дом печати» нәшрияты. – 2001. 192 бит.

2. Мәшһүр мәгърифәтче-галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин мирасын укыту-тәрбия процессында куллану. – Казан, 2006, 200 бит

3. Нәсыйхәт. Әхлак гыйлеменнән/ Ризаэддин Фәхреддин. – Казан: Мәгариф, 2005 – 184 бит

4. «Тәрбияле ана», «Тәрбияле хатын». Р. Фәхреддин. – Казан, 2006. – 187 бит

# МУРАД РАМЗИ – ЖИЗНЬ И НАСЛЕДИЕ ТАТАРСКОГО ИСТОРИКА В ЭПОХУ ДЖАДИДИЗМА

**Калимуллин Айрат Азатович**
*МБОУ «Старочечкабская ООШ*
*Кайбицкого муниципального района*
*Республики Татарстан»*
*Директор школы*

Становление Мурада Рамзи, как историка происходило в конце XIX – вначале XX в. В то время, когда шел подъем к знаниям по истории своих предков у татар. Мурад Рамзи – выходец из простой крестьянской семьи. Он получил классическо-татарское образование у себя в деревне. Далее он совершенствовал свои знания в различных исламских мусульманских учебных заведениях. Однако многое зависело и от самого ученого. Хочется отметить, что началом исторических исследований Мурада Рамзи, послужило влияние другого татарского историка и богослова Шигабуддина Марджани. Он, неоднократно, приводил в доказательство своих слов цитаты из его книг. Конечно же, есть мнения, касающиеся тех вопросов о компилятивности работы Мурада Рамзи. Но в более подробном изучении его исторического труда приводит к мнению, что концепции Ш.Марджани и М.Рамзи о возникновении становлении и развитии татарского народа отличаются. Что и доказывает пользу, приносимую от его исторических исследований.

**Актуальность темы:** Изучение творчество Мурада Рамзи и особенно его исторического труда представляет огромный интерес, тем, которым интересуются с творчеством Шигабутдина Марджани или Хусаина Фаизханова

**Целью работы:** является выявление и оценка вклада Мурада Рамзи в дело изучения истории татарского народа

Из поставленной задачи вытекают следующие исследовательские **задачи:**

1. Дать научную оценку деятельности историка Мурада Рамзи
2. Показать для широкой общественности Мурада Рамзи как личность внесший весомый вклад в просветительскую мысль татарского народа.

**Территориальные рамки исследования:** охватывают Волго-Уральский регион, с которым связана жизнь и деятельность Мурада Рамзи, а также которому посвящена исследуемая нами работа историка.

**Научная новизна исследования:** Мурад Рамзи один из ярких представителей татаро-философской мысли рубежа XIX – XX вв. Интерес к его работе начал проявляться в исследовательской среде сравнительно недавно, но, несомненно, его работы можно ставить в один ряд таких известных личностей как Шигабутдин Марджани, Ризаэтдин Фахретдин, Хусаин Фаизханов.

Особенно актуальная, в наше время, стоит задача по изучению рукописных сочинений татарских мыслителей XIX – начало XX века. До настоящего времени многие произведения татарских просветителей, в том числе и М.Рамзи, не переведены на современный татарский и русский языки.

Это не дает полной картины развития татарской исторической мысли вообще и просветительской в частности. Значение исторического наследия М.Рамзи для татарской культуры велико и неоценимо. Его творческая деятельность свидетельствует о честном служении своему народу. Он пытался приобщить современным достижением цивилизации и мусульманскими ценностями прошлого, русской и восточной культур и его книга останется крупным вкладом в историю, не только татарской, но и всей исторической мыслей в России.

## ДӨНЬЯ БУЙЛАП МӘГЪРИФӘТ НУРЫ ЧӘЧҮЧЕ

**Кашапова Рамилә Равил кызы**
*Казан шәһәре Яңа Савин районының*
*«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган*
*71 нче татар-рус урта гомуми белем мәктәбе»*
*гомуми белем бюджет муниципаль учреждениясе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Безнең төрки бабаларыбыз IV гасырда ук укый-яза белгәннәр. Идел буе Болгар дәүләте чорында мәгърифәт эше аеруча алга киткән. Чөнки Исламда гыйлем һәрвакыт игътибар үзәгендә булган, уку йортлары тоту изге эш дип саналган. Мөселманнарның һәр мәчете каршында мәдрәсә булган. Әлбәттә инде, бу мәдрәсәләрнең төп юнәлеше – дини белем бирү, мәдрәсә программасына Коръәнне үзләштерү һәм ятлау, аның тәфсирен, хәдисләрне, шәригатьне һәм гарәп телен өйрәнү кертелгән, аларда белем бирү югары булмый. Әмма халкыбызның мәгърифәтенә нигез салу шулардан башланган. Казан ханлыгында иң зур уку йортларының берсе сәед Кол Шәриф мәдрәсәсе булган. Биредә үзенең диненә һәм ватанына чын

күңелдән бирелгән шәкертләр тәрбияләнгән. Аларның барысы да 1552 елда Казанны урыс гаскәрләреннән саклаганда һәлак булганнар. Патша хөкүмәте, Казанны сугышып алганнан соң, татар мәчетләре белән бергә алар янындагы мәдрәсәләрне юкка чыгарырга тырышкан.18 нче йөзнең 70 нче елларыннан башлап, мәдрәсәләрнең хәле шактый җиңеләйгән. (Пугачев восстаниясенә бәйле, татар һәм башка милләтләрнең зур көч булып күтәрелүе хөкүмәтне уйланырга мәҗбүр итә.) Ул чорда Казанда ике уку йорты – Ахун һәм Апанай мәдрәсәләре, 1780 елда Әмирхания мәдрәсәсе ачыла. XVIII гасыр ахырында атаклы авыл мәдрәсәләре оеша башлый. Ләкин руслаштыру сәясәтенең көче кимими. Шундый шартларда мәйданга мәгърифәтчеләр килә. Алар татарны милләт буларак саклап калуда һәм үстерүдә мәгарифкә зур өметләр баглыйлар. 20 нче гасыр башында мәгарифнең дөньявилыгын үстерү юнәлешендә эш башлана. Шул нигездә хәреф- иҗек ысулына корылган кадими мәдрәсәләргә аваз-хәреф ысулына нгезләнгән җәдиди мәдрәсәләр өстәлә. Шәкертләргә күбрәк дөньяви белемнәр бирүне максат итеп куйган яңа тип мәдрәсәләрдән «Мөхәммәдия», «Касыймия», «Галия», «Хөсәения», «Рәсүлия» һәм «Буби» ны әйтеп үтәргә кирәк. Татарның үткәндәге күпчелек күренекле шәхесләре дә нәкъ менә шушы мәдрәсәләрдән чыккан. Кыскасы, бездә гасырлар дәвамында төрле кысуларга һәм югалтуларга карамастан, аң-белемгә игътибар зур булган, татарлар революциягә кадәр үк гыйлемле халыкларның берсе саналган.

Фәнни эшемнең темасын: «Дөнья буйлап мәгърифәт нуры чәчүче» дип атадым. Эзләнү эшем барышында үземә шундый максатлар куйдым:

1. Мәгърифәт тарихы турында белемнәрне тирәнәйтү;
2. Иж-Бубый мәдрәсәсенең шактый зур һәм бай тарихын өйрәнү;
3. Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем алган, белем биргән мөгаллим-шәкертләрдән Нәҗип Думавиның тормыш юлы, иҗаты белән танышу, аның турындагы язмаларны эзләү.

Халкыбызның мәдәнияте тарихында мәдрәсәләр зур урын билиләр. XX гасыр башында халыкны аң-белемгә тартып, милләтебезнең зыялыларын үстереп, укыту-тәрбиянең куелышы һәм эчке тәртип ягыннан алдынгы саналган, бөтен Русиядә дан-шөһрәт казанган татар мәдрәсәләре берничә генә. Алар – Казанда «Мөхәммәдия», Оренбургта «Хөсәения», Уфада «Галия», Әгерҗе төбәгендә Иж-Бубый мәдрәсәләре.

Иж-Бубый мәдрәсәсенең тарихы шактый зур һәм бай. Ул элекке Вятка губернасы Сарапул өязе Әгерҗе волостеның Иж-Бубый авылында 1781 елда оештырыла. Башка татар мәдрәсәләре белән беррәттән, ул да XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында зур үзгәрешләр кичерә. 1907 ел-

дан башлап, мәдрәсәдә аерым фәннәр буларак гарәп, фарсы, төрек, рус, француз телләре, тарих, политэкономия, арифметика, геометрия, физика, астрономия, география, ботаника, медицина, психология, педагогика алдынгы рус һәм Европа уку йортлары дәрәҗәсендә укытыла. Фәлсәфә, логика, әхлак, Коръән, хәдис, ислам тарихы өйрәтелә. Укыту расписание буенча алып барыла, дәресләр үткәрү өчен бүлмәләр җиһазландырыла; уку елы ахырында имтиханнар уздырыла.

Русиянең төрле почмакларыннан мәдрәсәгә укырга яшьләр килә. 1908-1911 елларда биредә һәр елны 500 шәкерт белем ала.

Мәдрәсәдә һәр атнада әдәби, фәнни кичәләр уздырыла. Мәдрәсәнең бай китапханәсе, махсус җиһазландырылган спорт мәйданчыгы була. Мәдрәсәне тәмамлап чыгучылар тирән фикерле, белемле, киң мәгълүматлы шәхесләр булып формалаша. Иж-Бубый мәдрәсәсенең уңышларга ирешеп чәчәк ату елларында аның белән бертуган Габдулла һәм Гобәйдулла Бубыйлар җитәкчелек итә. Буби мәдрәсәсендә Н.Думави, З.Байчурина, Д.Гобәйди, С.Җәләл, Җ.Вәлиди һ.б. укый һәм укыта.

Бу авылда Русиядәге мөселман хатын-кызлар өчен иң беренче уку йортларыннан кызлар мәдрәсәсе дә эшли. Ул Мөхлисә Бубый карамагында була.

Мәдрәсәнең дөньяви юл белән алга атлавы патша хөкүмәтен борчуга сала. Танылган татар уку йортларыннан булган Иж-Бубый мәдрәсәсе 1911 елның гыйнварында Русия хөкүмәтенә каршы фикер таратуда һәм панисламизмда гаепләнеп, яптырыла. Җитәкчеләре, мөгаллимнәре кулга алына. Мәдрәсә ябыла, 1912 елда хатын-кызлар мәдрәсәсе дә ябыла.

Күренекле тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең «Үткәнгә күзе җиткән, киләчәккә үзе җитә», – дигән бик гыйбрәтле сүзләре бар. Еллар, гасырлар уза тора. Кайбер данлыклы шәхесләр онытыла-лар. Ә менә Иж-Бубый мәдрәсәсендә дини һәм дөньяви белем алган, шунда ук тирән белемнәрен шәкертләренә җиткерү теләге белән янган Нәҗип Думави халык хәтерендә һаман саклана, иҗади мирасы өйрәнелә. Н.Думави иҗатының халыкны үзенә тартып тору көче нидән гыйбарәт соң? Минемчә, аның яшәеше, көнкүреше, кайгысы, шатлыгы сөйгән хал-кы белән бер җепкә бәйләнгән. Бу тылсымлы бергәлек.

Әйе, Нәҗип Думави – бай мирас калдырган язучы. Ул – шагыйрь дә, прозаик, публицист, әдәбиятчы-тәнкыйтьче, тәрҗемәче, уку-укыту эшенә, педагогикага кагылышлы хезмәтләр, дәреслекләр авторы да. Шагыйрь буларак ул 1905 елгы инкыйлаби вакыйгалар тәэсирендә мәйданга чыга һәм башта мәгърифәтчелек, соңга таба романтика катыш тәнкыйди реа-лизм рухында язылган социаль эчтәлекле шигырьләре белән үз чорының популяр шагыйрьләреннән берсе булып таныла. Ул күпсанлы шигырьләр,

поэмалар иҗат итә. Болардан тыш, повестьлар, хикәяләр, публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләрен дә яза.

Нәҗип Думави (Нәҗип Сибгатулла улы Тахтамышев) Чистай өязе (Татарстанның Аксубай районы) Яңа Дума авылында 1883 елда туган. Дүрт ел башлангыч белемне үз авылларындагы әтисе мәктәбендә алып, аннары бер кышны Кизләү мәдрәсәсендә уздыргач, Казанга килгән һәм 19 яшенә надәр Апанаевлар мәдрәсәсендә укыган. Татар балалары өчен ачылган рус мәктәбенә йөргән, бик кыска вакыт эчендә русча укырга-язарга өйрәнгән.

Казанда яшәгән елларында Думави үзлегеннән күп укый, белемен күтәрә. Философия белән кызыксына. Үзенең фикри үсешенә мәгърифәтче Шәмсетдин Күлтәси әсәрләренең тәэсире зур булганлыгын әйтә. Күлтәси Думавида иске мәдрәсә схоластикасына карата тәнкыйть карашы тәрбияли. Булачак әдип төрек телендәге матбугат белән якыннан таныша. Галиәсгар Камалның яңа ачылган китап кибетеннән алдырылган китаплар аңа зур чыганак була. Аеруча тырышлык белән Думави рус әдәбиятын өйрәнә. «Тәрҗемәи хәл» ендә ул, «рус классикларын «барын да укып чыктым», ди.

1902 елда мәдрәсәне тәмамлагач, Думави Учительская школага кереп уку турында хыяллана. Ләкин материаль хәле начар булу сәбәпле, бу уен тормышка ашыра алмый. Бераз акча эшләп кайту максаты белән Әстерхан һәм Гурьевкадагы балык промыселларына китә, аннан казакъ далаларына юнәлә һәм ике ел буе шунда балалар укыта.

Думави гомеренең байтак өлешен (30 елга якын) педагогик хезмәткә багышлый: туган авылында, Буби мәдрәсәсендә, Уралдагы күмер шахталарында (Кизелда), Рязань губернасындагы Вәрәки авылында, Үзбәкстанда укытучы булып эшли.

Демократия тарафдары буларак, Думави патша самодержавиесе тарафыннан эзәрлекләнә. Буби мәдрәсәсе вакыйгалары уңае белән 9 ай ярым (1911) төрмәдә утырып чыга. Рус-япон сугышы һәм беренче империалистик сугыш кебек афәтләрнең җәфаларын да үз җилкәсендә татый. Шактый катлаулы һәм каршылыклы иҗат юлы үтеп, социалистик революциягә хезмәт итү бәхетенә ирешә.

Совет хакимияте елларында барлык мәдрәсәләр ябыла һөм дини мәгариф системасы юкка чыгарыла. Ләкин тарих тәгәрмәч кебек әйләнә дә кайта. Халык та үз асылына кайтып, яңадан мәчет-мәдрәсәләрне торгыза башлый. Татарстанда беренче мәдрәсә 1990 елда Чистай шәһәрендә Габделхак хәзрәт Саматов тарафыннан ачыла. 1993 елда «Мөхәммәдия» һәм Исламны кабул итүгә 1000 ел исемендәге югары мәдрәсәләр ачыла.

Татар милләте яшәеш өчен төп терәк, уңышка ирешү чыганагы гыйлем булуын бик борынгы чордан ук аңлап яшәгән, без дә бу гадәтне дәвам итик: тырышып белем алыйк.

Алдан куелган максатларыма ирешкәч, шундый нәтиҗәләргә килдем: милләтебез тарихында тирән эз калдырган мәдрәсәләр – мәгърифәт учакларыбыз, бөек шәхесләребез турында онытырга безнең хакыбыз юк. Аларның тарихын белү зарур һәм безнең бурычыбыз.

**Кулланылган чыганаклар:**


1. Ганиева Р. Нәҗип Думави // Татар әдәбияты тарихы. – 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 214–233 б.
2. Гайнанов Р. Ярлылар зарын җырлаучы // Соц. Татарстан. – 1963. – 30 май.
3. Мәһдиев М. «Таң атар, башланыр ак тормыш…»: Нәҗип Думавиның тууына 100 ел // Соц. Татарстан. – 1983. – 19 май.
4. Татарстан. Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре -2011. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе


## НАСЛЕДИЕ ХАДИ АТЛАСИ НА УРОКАХ ИСТОРИИ


**Каюмова Айзиля Фаизовна**
*МБОУ «Татарская гимназия №14*
*им. Хади Атласи»*
*Учитель истории и обществознания*


В 2012 году гимназии присвоено имя выдающегося государственного и общественного деятеля, просветителя, историка Хади Атласи. Это большая честь и ответственность одновременно, которая возлагается на руководителя и учителей гимназии. Это систематическая работа учителей, результатом которой является умение обучающихся ответить на самый главный вопрос: Кто он Хади Атласи? Почему гимназия носит его имя? В чем его вклад в развитие образования нашего города/региона? Проблема, с которой сталкиваются учителя, в содержательном элементе Федеральных государственных образовательных стандартов по истории, отсутствует темы, посвященные Хади Атласи. Учителя используют в этой работе часы, отведенные региональному компоненту, который составляет 10% от содержания. Актуальность данной работы заключается в том, что многие татарские гимназии носят имена татарских просветителей, наш опыт работы с именем может помочь и другим школам нашей республики.

Цель работы: распространить опыт работы с наследием известного татарского просветителя Хади Атласи на уроках истории.

Ежегодно обучающиеся 5-8, 11 классов пишут Всероссийские проверочные работы по истории. До недавнего времени постоянным заданием в работах был отведен региональному компоненту, в котором ученикам предлагалось написать имя исторического деятеля, его вклад в развитие региона или любое важное событие, связанное с его именем. Традиционно, учителя истории гимназии готовили детей писать о Хади Атласи. Благодаря этому заданию, дети учились осознанно писать о вкладе Хади Атласи в развитие города/региона. Но, к сожалению, в прошлом году это задание изменили.

Хади Атласи – автор многих публикаций, статей, трех исторических монографий. Эти работы удачно использовать на уроках истории:

7 класс, тема: «Государства после распада Золотой Орды: Казанское ханство, Сибирское ханство».

О каком историческом деятеле идет речь в отрывках из монографий Х.Атласи?

«__________ның башында **<u>Сибирияне</u>** Русия кул астына кертмәк уе булмаган кеби, аңарга соңыннан ул җирләрдә башкарырга туры килгән олы эшләрне башкару уе да юк иде. <...> ...__________ үзенә кирәкле нәрсәләрнең һәрберсен хәзерләдектән соңра, тагы да адашып юкка вакыт әрәм булмасын өчен **<u>Строгановлардан</u>** юл белүче ничәләп кеше алды».

Другая монография Хади Атласи «Казанское ханство» актуально использовать для развития читательской грамотности:

Какие причины поражения в Казанской войне называет Хади Атласи:

| | |
|---|---|
| «Казанның ни бар гаскәре 60 мең белән 80 мең арасында булып, урысныкы аларныкына караганда ничә кат артык иде. Ышанычлы рузнамәләрдә урыс гаскәренең саны хакында ачык сүз булмаса да, кайсыберләрендә аның саны 150 мең, кайсыларында исә 520 меңнән дә артыграк булганлыгы күрсәтеләдер». | ⟹ численное превосходство армии Ивана Грозного |
| «Кайсыбер рузнамәләрнең сүзләренә караганда, берьюлы 3 мең татар Казаннан качып урыслар янына килгәннәр иде. Камай мирзаның Иван янына килүе урыслар өчен чиктән тыш файдалы булган кеби, Казан тормышын төпчеләп Иванга сөйләве бигрәк файдалы булды. Шуңа күрә Иван аның үзен һәм иптәшләрен төрлечә бүләкләр белән бүләкләде». | ⟹ татарские мурзы поклялись в верности русскому царю |

| | |
|---|---|
| «Казанлылар, урыслар килгәнчегә чаклы Нугай йортына илчеләр җибәреп, шулар аркылы андагы мирзаларга кыйммәтле бүләкләр биргәннәр, ни чаклы акчага булса да, нугай явын казанлыларга ярдәмгә җибәрүләрен үтенгәннәр иде. Мирзалар, казанлыларның бүләкләрен алды исә дә, гаскәр җибәрмәделәр. Шулай итеп, Казанны иң кирәк чагында ярдәмсез калдырдылар» | $\Longrightarrow$ отсутствие единства среди татар |

Правильно после этого задания задать ученикам вопрос: А как вы думаете, какую причину Хади Атласи считает главной причиной?

В 9 классе ученики начинают изучать историю развития парламентаризма, Государственные Думы I – IV созывов. Какова роль мусульманской фракции в этих Госдумах? Как проходили выборы в Государственные Думы? и на многие другие вопросы, нам помогает ответить биография Атласи. Его жизнь и судьбу также нельзя не вспомнить в 10 классе, когда изучаем печальные вехи истории: репрессии. Наравне с судебными разбирательствами «делом врачей», «ленинградским делом» на уроках изучаем «атласовщину» – сфабрикованное дело против Х.Атласи и его соратников.

Большую роль в формировании предметных знаний о Х.Атласи имеет внеурочная деятельность, которая проводится в течении года: экскурсии по музею Хади Атласи, вовлечение учеников в мероприятия, связанные с Х.Атласи («Хәтер көне», «Межрегиональные юношеские чтения Хади Атласи»). Ежегодно 15 февраля проводятся пятиминутки, посвященные памяти Х.Атласи: ученики ходят по классам и рассказывают о судьбе татарского просветителя. Интересным решением для старшеклассников стала игра по мотивам популярной игры «Мафия». Эту игру мы назвали «Казанское ханство», а имена героев взяты из монографии «Казанское ханство»: Сююмбике, Шаехгали, Ядегәр хан, Кол Шариф, Камай мирза, Явыз Иван и другие.

В заключении, Хади Атласи – символ нашей гимназии, наш национальный герой. Наша задача – поддерживать этот символ и делать это лицо узнаваемым, а систематические использования его трудов на уроке и вне урока делают нашу работу успешной. Подобный план работы с именем своей школы, должны проводить все школы.

# XX ЙӨЗ БАШЫ ГАЛИМНӘРЕНЕҢ ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУГА БАГЫШЛАНГАН ХЕЗМӘТЛӘРЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ, ӘҺӘМИЯТЕ

**Мансуров Алмаз Илдар улы**
*Казан шәһәре МАББУ «7 нче интернат лицей»*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Тарихи чыганаклардан мәгълүм булганча, урыс дәүләте белән икътисадый багланышларыбызның башы борынгы гасырларга ук барып тоташа. Бу, үз чиратында, милләтләр арасында бәйләнеш урнаштыру теләге, аларның телен, мәдәниятен үстерү ихтыяҗын китереп чыгара. Татар теле гарәп графикасына нигезләнгән булуга да карамастан, урыс халкы бу тел белән һәрвакыт кызыксынган, ә соңрак патша хөкүмәтенә урыс дәүләтенең мәнфәгатьләрен яклый алырлык, татарча белүче урыс түрәләре әзерләргә кирәк була. Алар төрки дәүләтләр белән төрле бәйләнешләр урнаштыруда, шулай ук хөкүмәтнең басып алу сәләтенә мөһим роль уйныйлар. Ф.Ф.Харисов фикеренчә, татарлар арасында миссионерлык эшен алып бару өчен дә тел беренче шарт булып тора.

Шулай да үз телеңнең кагыйдәләрен белми торып, чит телне өйрәнеп булмый. Үзенең 1884 елда чыккан «Фәвакиһел җөләса фил әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлес җимешләре»)исемле китабында К.Насыйри да туган телне яхшы белүнең чит телне өйрәнгәндә зур файда китерәчәген искәртә: «Кеше үзенең туган телен кагыйдәсез дә белер һәм һич тә ялгыш әйтмәс һәм хата сөйләмәс. Ләкин башка телне өйрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кагыйдәләрен белү бик кирәк. Чөнки кеше үз телен яхшы белмәсә, башка телгә төшенә алмас, тик бик озак вакытлардан соң гына аңа күнегә алыр». (Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 2 томда. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. – 1т. – Б. 30).

Билгеле булганча, татар телен башка милләт вәкилләренә өйрәтүнең шактый зур тарихы бар. Ул төрле милләтләр арасындагы үзара бәйләнеш урнаштыру ихтыяҗларыннан барлыкка килгән. Руслар арасында бу эшне галим В.Н.Татищев башлап җибәрә.

Эшебезнең **төп максаты** – татар булмаганнар өчен язылган дәреслек, кулланма, программаларга ретроспектив, диахроник күзәтү ясау һәм аларны кыскача анализлау, бүгенге көндәге актуальлеген билгеләү.

Максаттан чыгып түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

1. XX гасырда татар булмаганнар өчен язылган дәреслек һәм кулланмаларга тулы күзәтү ясау;

2. татар булмаганнарга татар теле укытуда туган проблемаларны күрсәтү, бүгенге көн белән чагыштыру;

3. татар телен башка милләтләргә укыту өлкәсендә зур эшчәнлек башкарган һәм кулланма, дәреслек, программалар тезү эшендә үзләреннән зур өлеш керткән галимнәребезнең иҗатына күзәтү ясау.

Эшебезнең **актуальлеге**: татар теле бик борынгы заманнарда ук укытыла башлый. Ул чордагы галимнәрнең чыгарган дәреслек, кулланма, программалары татар телен өйрәтүгә бик нык ярдәм итәләр, һәм аларның күбесе бүгенге көн методикасы яссылыгыннан караганда хәзер дә актуаль.

Рус балаларына татар теле укыту бик тә катлаулы процесс. Аның тарихы борынгы заманнарга барып тоташа, чөнки безнең татарлар белән руслар бер-берсе белән аралашып яшәгәннәр, сәүдә иткәннәр. Татар телен укыту эше XVIII йөзнең I яртысыннан башлана. Алда билгеләп үткәнчә, ул Татищев исеме белән бәйле, чөнки ул беренчеләрдән булып, мәктәпләр, гимназияләр ачтыра, сүзлекләр төзетә. Укыту өчен дәреслекләр булмый. Бераз вакыт үткәннән соң берсе артыннан берсе дәреслекләр, кулланмалар һәм программалар дөнья күрә. Галимнәр, укытучылар зур тырышлык күрсәтәләр. Русларга татар теле укыту өлкәсендә зур өлеш керткән шәхесләребезнең кайберләрен генә санап китәм: Хәлфиннәр династиясе, К.Насыйри, М.Корбангалиев, Р.Газизов. Аларның күп кенә хезмәтләре бүгенге көнгәчә сакланган һәм фәнни-методик мирасыбыз булып торалар. Әлеге дәреслекләр белән танышу безгә рус теле белән татар телен чагыштырма планда карап тикшерергә, үзенчәлекләрен күрергә ярдәм итә. Бүгенге көн галимнәре элеккеге дәреслекләрне нигез итеп алып яңаларын төзиләр. Моңарчы төзелгән дәреслекләрдән аермалы буларак, XX гасыр кулланмаларында укучыларның интелектуаль үсешен үстерү дә күздә тотылып грамматик уеннар, ребуслар, рәсемнәр нигезендә җөмләләр, хикәяләр төзү, инша язу кебек биремнәр кертелгән. Бигрәк тә Ф.С.Сафиуллина, А.Ш.Асадуллин, Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова дәреслек, кулланмаларында тәрбияви максатка зур урын бирелә. Монда ягымлы сүзләр куллану, үзара аралашу, әдәплелек сыйфатлары буенча күнегүләр уңышлы кертелгән. Укытучы сөйләмен тыңлап, аңлап уку, укыганны хәтердә калдыру, укытучы артыннан сүзләрне дөрес әйтә белү, укучылары үзләре үк сораулар төзи алу кебек белем һәм осталыкларны камилләштерү алымнары еш кулланыла.

Әйтергә кирәк: татарлардан башкаларга татар телен өйрәтү эше җиңел генә бармый. Илдә команда-административ система урнаша барган саен (XX гасыр ахырында үзен аеруча сиздерә башлый),милли по-

литика тупас бозуларга, деформацияләргә дучар ителә, милли телләрне үстерү сәләте алга куела.

30нчы елларда башланган һәм 50нче еллар башына кадәр дәвам иткән руслаштыруның бер формасы булган милләтләрне бетерү сәясәте Татарстан Республикасын да читләтеп үтмәде. Бик күп зыялылар нахакка милләтчелектә гаепләнеп җәзаландылар, туган җирдән аерып сөргенгә җибәрелделәр, мәдәният учаклары, газета-журналларның күбесе ябылды. Мондый шартларда телне саклап калу да куркыныч астына куелды, – дип яза Ф.Ф.Харисов үзенең хезмәтендә. Фикерен дәвам итеп, 7 миллионлы татар халкының башкаласы Казан шәһәрендә 80нче еллар уртасында 10нчы интернат мәктәптән башка бер генә дә саф татар мәктәбе калмады, – ди. Милләтебезнең тәмам юкка чыгу куркынычыннан бары тик үзгәртеп кору, хәбәрдарлык сәясәте генә коткарды, милләтара мөнәсәбәтләргә яңа сулыш өрелде. Ниһаять, милләтләрнең һәрьяклы, гармонияле үсеше өчен кирәкле шартлар тудырыла башлады. (34, Б. 29-30).

Мөстәкыйльлек турында Декларация игълан ителгәч, икетеллелек гамәлгә керде. 1922 елда «Татарстан халыкларының телләре турында Закон» кабул ителде. Татар һәм рус телләре дәүләт телләре дип игълан ителде һәм ике телгә бертигез хокуклар бирелде. Бу исә телебез, мәдәниятебез үсеше өчен зур мөмкинлекләр ачты. Шул уңайдан татар телен дәүләт теле буларак өйрәтү мәсьәләсе дә үзәккә килеп басты. Татар теленә кызыксыну рус милләте һәм башка милләтләр тарафыннан артканнан-арта барды. (34, Б. 21).

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк:

Баштарак татар милләтеннән булмаган кешеләргә татар телен укыту өлкәсендә кыенлыклар һәм проблемалар туган булса, бүгенге көндә алар тулысынча туктатылды дияргә була. Чөнки 80нче елларның икенче яртысыннан урыслаштыру башбаштаклыгына чик куела башлады. ТРның мөстәкыйльлек яулавы, «Татарстан халыкларының телләре турында Закон»ның кабул ителүе һәм рус теле белән татар теленең дәүләт телләре итеп беркетелүе татар телен укыту өлкәсендә алга китәргә этәрде. Алда әйтеп үткәнчә, башка милләт вәкилләренә татар телен укыту бик катлаулы процесс. Моны җиңәргә булышкан һәм татар булмаганнар өчен язылган кулланма һәм дәреслекләрне төзүдә мәгърифәтче Хәлфиннәр династиясенең, шулай ук татар халкының күренекле мәгърифәтчесе, энциклопедист галим, язучы һәм педагог К.Насыйриның, профессор М.Корбангалиев һәм Р.Газизовларның, А.Троянский, М.Иванов, М.Махмудов, Н.Остроумовларның һәм башка бик күп күренекле галим һәм шәхесләребезнең эшләре аерым ихтирамга, хөрмәткә лаек. Алар төзегән кулланма, дәреслек, программа, сүзлекләр бүгенге көндә дә уку-

ту методикасының нигезен тәшкил итәләр, бүгенге көн дәреслекләрен төзү өчен төп таяныч булып торалар.

Чыганаклар белән танышканнан соң, татар теленең бик борынгы заманнардан ук укытыла башлаганын, ул чорда нинди галимнәр эшләгәнен һәм алар чыгарган дәреслек, кулланмаларның ни дәрәҗәдә татар телен өйрәтүгә ярдәм итүен аңлыйсың, һәм күбесенең, бүгенге көн методикасы яссылыгыннан караганда, хәзер дә актуальлегенә инанасың.

## МӘШҺҮР ПЕДАГОГ

**Мифтахова Гөлсинә Гомәр кызы**
*Нурлат шәһәре 4нче урта гомуми белем мәктәбе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

XX йөзнең беренче яртысында татар теленең сафлыгы өчен көрәшүче, аның әдәби һәм фән теле була алуын исбат итүче, татар телен гамәли һәм гыйльми эшкәртү юлында кыю, зур эшчәнлек күрсәтүче, шулай ук татарларга рус телен балаларның ана телләре белән чагыштырып укытуны яклаучы, аны гамәлгә кертеп җибәрүче педагогларыбыз арасында Мөхетдин Хафизетдин улы Корбангалиев аерым урын били.

М. Корбангалиев татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын, аның башка телләрдән артта булуын фәкать тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгәнлектән генә икәнлеген исбат итә. Ул татар телен эшкәртү һәм бөтен халыкка аңлаешлы тел итү юлында татар телен бозучыларга каршы көрәштә күп көч куя. Балаларга ана телен һәм рус телен укытуны яклап чыга һәм шуны үзе эшләгән мәктәпләрдә гамәлгә кертеп җибәрә. Ул бу эшләрне, практик укыту процессында сынап, бер телне икенче тел белән чагыштыру методын куллану аркылы алып бара.

Мәшһүр педагог уку-укыту өлкәсендә яңа методларны алга сөрә, грамматикага һәм аны укытуга зур урын бирә. Ул укучыларның сүзлек запасын арттыруга аерым игътибарын юнәлтә һәм бу юнәлештә эшләү юлларын да күрсәтә; татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр төзү эшенең әһәмияте зур, һәм алар бүгенге көндә дә үзләренең **актуальлекләрен** саклыйлар диярге мөмкин. Шуңа күрә фәнни-тикшеренү эшемне бөек педагог эшчәнлеген өйрәнүгә багышладым.

Хезмәтемнең **темасы:** «Мәшһүр педагог».

**Максаты:** М.Корбангалиевның тел белеме һәм методика өлкәсендәге эшчәнлеген тикшерү.

**Бурычлар:**

М.Корбангалиевнең педагогик эшчәнлеген тикшерү.

М.Корбангалиевнең методик системасына анализ ясау.

Тикшеренү **обекты** М.Корбангалиевның эшчәнлеге.

Тикшеренү **предметы** М.Корбангалиевның тел белеме һәм методика өлкәсендәге хезмәтләре.

Эш барышында кулланылган **методлар:** эзләнү, күзәтү.

Эшнең **структурасы**: фәнни эшем кереш, бүлек, йомгаклау, әдәбият исемлегеннән тора.

Татар методистлары арасында аерым урын алып торган профессор М.Корбангалиевның күп еллык педагогик һәм методик хезмәтләре тикшерелмичә, өйрәнелмичә, аларга бәя бирелмичә, архивта гына ятуы зур кимчелек иде. Шушы кимчелекне бетерү максатыннан Казан дәүләт педагогия институтының татар теле белеме кафедрасы доценты Ф.С.Валеева үз алдына М.Корбанагалиевның методика өлкәсендәге эшчәнлеген өйрәнү максаты куя. Шушы юнәлештә кандидатлык диссертациясе яклый һәм, ниһаять, 2004 нче елда «Халкына багышланган гомер» дип аталган хезмәтен бастырып чыгара. Бу хезмәттәге кайбер фикерләрне үз эшемдә мин дә файдаландым.

М.Корбангалиев үзенең хезмәтен башлангыч мәктәпләрдә ана теле һәм рус теле укыту белән башлап җибәрә. Соңга таба бу эшне урта һәм югары мәктәпләрдә дә дәвам иттерә. Шулай ук укый-яза белмәүчелекне бетерү өлкәсендә дә, ягъни зурларны укыту өлкәсендә дә, күп көнә көч куя. Шулар белән бергә, татар булмаганнарга татар теле укыту буенча да күп эш алып бара.

Укырга-язарга өйрәтү буенча М.Корбангалиев үз гомерендә өч төрле метод белән эш иткән: аваз методы, бөтен сүзләр методы һәм аналитик-синтетик аваз методы.

М.Корбангалиев, башлангыч мәктәпләр дә укырга-язарга өйрәтү методикасы өстендә эшләү белән бергә, шул ук мәктәпләрдә грамматика укытуны ничек алып бару юлларын да күрсәткән.Ул грамматика дәресләрендә грамматик тикшеренүләр ясарга кирәклекне алга сөрә. Грамматик тикшеренүләрне ул телдән дә һәм язма рәвештә дә алып барырга тәкъдим итә; дәресләрдә ул сызма тикшеренүләрнең төрле үрнәкләрен һәм төрле схемаларын да бирә.

М.Корбангалиевның дөрес язарга өйрәтү турындагы карашларына да игътибар итәргә кирәк. Бу өлкәдә дә үз вакыты өчен яхшы ук төрле фикерләр әйтә. Рус методистларыннан К.Д.Ушинский һәм Н. Кульманнар

алганча, М.Корбангалиев та диктантны, күчереп язуны һәм ятлаганны күчереп язуны дөрес язарга өйрәтү чаралары итеп ала.

Педагог уку дәресләрендә аңлап укуга игътибар итәргә кирәклекне аеруча басым астына алып күрсәтә; моның өчен укыла торган материалны элек ана телендә аңлатырга, яңа сүзләргә аңлатма бирергә; ул сүзләрне укучылар дөрес әйтә алуга ирешкәч кенә аерым-аерым укытырга куша һәм укучыларның үзләренә эчтән укырга мөмкинлек бирергә кирәклекне әйтә.

Башлангыч, урта һәм югары мәктәпләрдә укуны татар булмаганнарга татар телен укыту, укырга-язарга өйрәтү, аларның татарча сөйләм телен үстерү һәм аларга грамматик белем бирү эшләрен ул югарыда күрсәтелгән алымнар белән алып барган һәм шулай алып барырга кирәклекне яклаган.

Мәшһүр педагогның эшчәнлеген тикшереп, аның метод һәм алымнар хәзер дә файдалы, кулланырга һәм үрнәк алырга яраклы булып торуына инандым. «Укытучы укучыларның тел өстендә күзәтүләрен, тәҗрибәләрен билгеле бер нәтиҗә ясый алуларына юнәлдерелергә тиеш. Шуннан инде укучы тиешле кагыйдә чыгара алуга кадәр барып җитәргә, аны кабатларга һәм үзләштерергә тиеш. Укытучы әзер кагыйдәне генә укучыларга тәкъдим итеп, ятлатудан ерак торырга тиеш». М.Корбангалиевның шушы кагыйдәләре хәзерге проблемалы укытуның нигезе булып тора бит. Ана телен башка фәннәр белән бергә бәйләп алып барырга кирәклеген ассызыклап, предмет ара бәйләнеш барлыкка китерә.

Чыннан да, М.Корбангалиев – гомерен татар халкы өчен багышлаган мәшһүр педагог. Ул халык өчен туган телнең зур әһәмияткә ия булуын һәм мәктәптә аның укыту теле булырга тиешлеген алга куя. Туган телдә укыту балаларга белем бирүдә һәм аларны тәрбияләүдә яхшы чыганак дип саный.

**Кулланылган әдәбият**


1. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы.- Казан, «Раннур», 2000. – 455 бит.

2. Вәлиева Ф.С. «Халкына багышланган гомер». – Казан. «Мәгариф». –2004. – 144 бит.

3. Вәлиева Ф.С. М.Х.Корбангалиевның татарларга һәм татар булмаганнарга татар телен укыту буенча методик системасы.- Казан, 1951.-286 бит.

# ХӘЗЕРГЕ ҖӘМГЫЯТЬТӘ ХАТЫН – КЫЗ ТӘРБИЯЛӘҮНЕҢ АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАСЫ

**Нуретдинова Альфия Рафаиль кызы**
*Казан шәһәре Яңа Савин районының*
*315нче балалар бакчасы*
*Тәрбияче*

Хатын-кызның яшәешебездәге вазыйфасы мәсьәләсе һәрдаим актуаль. Бу турыда төрле фикерләр бар. Хатын-кыз мәсьәләсе бүгенге тормышта милли проблема кебек үк, иң үткеннәрнең берсе булып тора. Кешене физик яктан да, рухи яктан да хатын-кыз тудыра һәм үстерә. Табигать һәм кешелек җәмгыяте тарафыннан хатын-кызга әнә шундый иң бөек миссия йөкләнгән. Фәлсәфи яктан бу проблеманы ачуга дин галиме, публицист, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Бигиев Мусаның хезмәтләре дөнья курә.

Шул елларда ук ул, хатын-кызның тулы хокуклыгын танырга һәм мөселман җәмгыятьчелеге тормышында аларның абруен күтәрергә чакырып, махсус программа тәкьдим итә. Аның шушы өлкәдәге теоретик эзләнүләре «Коръән Кәрим аять кәлимәләре хозурында хатын» (1933ел) китабында чагылыш таба. Төп фикер булып хатын-кызны түбәнсеткән җәмгыять беркайчан да алгарышка ирешә алмаячак дигән караштан гыйбәрәт. Хатын-кызның тоткан ролен бәяләп бетермәве исламның сүлпәнәя баруын китереп чыгара дип язылган Муса Бигиев хезмәтләрендә. Үзе турында: «Хатын-кызга карата хөрмәтем миңа корьәндә язылган тәрбия буенча кергән» – ди. М.Бигиев хатын-кызның Көнбатышта да, Көнчыгышта да түбәнсетелгән хәленең сәбәбен табарга тырышты. Көнчыгышта мөселман халыклары дәүләт эшләреннән азат булып, өй, гаилә өчен генә кирәк булсалар, Көнбатыштагы хатын-кызлар дәүләт эшләренә катнашсалар да, эшче көч булып кына калалар, күп кенә хокуклардан мәхрүм булалар.

М.Бигиев гаилә турында – гаилә ул бу яшәештәге оҗмах һәм оҗмахның башы, ди. Минем фикеремчә, түбәнсетелгән тормышта яшәгән хатын-кызлар беркайчан да бөек була алмаячак. Хатын-кызларның җәмгыятьтәге урынын билгеләү мәсьәләсен өйрәнгәндә, ул социаль һәм кешелек хокукларын күтәреп чыгу проблемасын өйрәнә һәм чишә.

Минем иң яратып укыган китапларымның берсендә Коръән рөхсәт иткән, әмма үтә дә четерекле, шулай да татар дөньсында шактый киң тарала барган күпхатынлылык темасы күтәрелә. Һәм ул күпләрне уйланырга, тормыш-көкүрешебезгә төрле яклап күз салырга ярдәм итәр дип

уйлыйм. Бу китапта Гөлчәчәк Галиеваның «Газзәбану» романы һәм «Тулгак» повесте басылган. «Газзәбану» романы тулысынча чын тормыштан алынган. Төп герой Газзәбану апа.

Бу әсәрдә Газзәбануның ире 1921 еллардагы ачлык вакытында дусты белән акча эшләргә дип Үзбәкстан якларына китәләр. Шундагы бер татар баена эшкә кереп, гаиләсен ачлыктан коткару өчен аның укымышлы кызына өйләнергә мәҗбүр була. Ләкин алар арасында мәхәббәт тә була.

Еллар үткән саен, күпхатынлылык турында бик тиз һәм ансат кына баеп киткән югары чиновниклар арасында шәригать кануннарының дәүләт күләмендә танылуын теләп сөйләшүләр, төрлечә фикер йөртүчеләр матбугат битләрендә дә куренә башлый. «Шәһри Казан» газетасында мөфти хәзрәтенең урынбасары җавап итеп болай дигән:

«Купхатынлылык шактый киң таралган Татарстанда инде популярлаша да бара. Ирләрен башка хатыннар белән бүлешергә туры килгән хатыннарның үз язмышларын авыр кичерүләрен беләм. Тик аларның яраткан ирләренә карыша алырлык хокуклары юк. Берничә хатынлы булу күп ирләребез уйлаганча һич тә җиңел түгел, гаиләләрендә дә тынычлыклары юк», – ди ул. Шул ук вакытта ике, өч, хәтта дүрт хатыны булган мөселманнарыбыз һаман арта бара икән ләбаса. Кайбер яшь кенә ханымнарыбыз һәм кияүгә чыга алмый калган кайбер кызларыбыз да матбугат битләрендә купхатынлылыкны хуплап, ятим балалар да, ялгыз хатын-кызлар да азрак булыр иде дип аңлатырга тырышалар.

Икенче яктан караганда хәзер хатын-кыз хокуклары ирләрнеке белән тигезләште дияргә була. Бәлки, артып та китмәде микән?! Оешма җитәкчеләре, депутатлар һәм башка урыннарда да күрергә була аларны. Элекке сугыш еллары күрсәтелгән кинофильмнарда трактор, машина йөртүче хатын-кызларны күреп исебез китә иде. Ә хәзер барлык төр транспорт чараларында да руль артында хатын-кызны күрәбез. Әле алай гына да түгел, биек йортлар төзегәндә дә кирпеч тотып хатын-кыз эшли, ирләр белән беррәттән станокта тимер дә кыра. Күп йортларда ирләр урынына тормышны шулай ук хатын-кыз алып бара дисәк тә була. Бик артыгы белән түгелме бу тигезлек?! Ә бит шул көнетөне авыр эштә эшләгән хатын-кызны өйдә сагынып нарасыйлары көтеп утыра. Әйе, өйдә эти кеше бала белән декрет ялында, ә әни иртәдән кичкә кадәр трамвай йөртә. Менә нинди тигезлек! Ә нарасыена бирерлек наз, көч, игътибар каламы синең гүзәл зат?! Тәрбияне иң беренче бит син – ана бирергә тиеш. Иртәгесен ашык-пошык балалар бакчасына китереп куйган балалар – чәч таралмаган, күлмәк алыштырылмаган...

Ничек баланың иртән кәефе булсын, әлбәттә ул көйсезләнә инде.

Буш вакыты булдымы телефонга тотына хәзер кеше. Балалар да хәзер ана назын онытып, телефон колына әйләнмәдеме икән? Аларга ана кочагында утыруга караганда телефонны кочаклап утыру рәхәтрәк түгелме? Бик нык уйланырга кирәк бу турыда.

Яшүсмер кызларның малаймы, кызмы икәнлеген чамалап булмый. Яшел чәч, озын тырнак, тагын әллә нинди чылбырлар тагылган киемнәр. Хатын-кыз нәфислеге күренәме боларда? Ямьсез сөйләшү, үзеңне ямьсез тоту да читләми үзләрен.

Мәктәптәге укытучы апаларыбыз искә төшә: зәңгәр төстәге итәкле костюмнан, битенә сизелер-сизелмәс кенә акбур йогып калган математика укытучысы, җилкәсенә җете ак мамык шәлен салган тарих укытучысы, матур күлмәген кигән чын тавыш белән җыр өйрәтүче җыр укытучысы. Барысы да шул киемнәре белән ничек бар шулай истә калганнар бит алар. Алар шикелле булырга теләп укытучы уенын уйнау. Менә алар безгә чын хатын-кыз образын биреп калдырганнар. Ә хәзер хатын-кыз һәр көн саен яңа кием кия, алтын-көмеш бизәкләр тага, күбесенең уйларында ничек тә кием яңарту, баерак күренү. Шул киемнәр, бизәкләр аркылы өләшергә тиешле наз, җылылык чыга алмый интегә. Бу хәзерге заманның актуаль проблемасы.

Әмма тагын бер төр хатын-кызларны әйтми калып булмый. Ирләрен, улларын, сөйгәннәрен илне сакларга озаткан аналар, хатыннар, кызлар... Әйе, менә алар хәзерге заманның күркәм, сабыр, үрнәк алырдай хатын-кызлары. Аларны байлык та, кием дә кызыксындырмый. Аларга бары тик илдәге тынычлык һәм балаларының, ирләренең, сөйгәннәренең исән-сау әйләнеп кайтулары гына кирәк.

М.Бигиев башлаган проблема, мина калса, хәзер дә дәвам итә. Тәрбияче булып эшләү, алда әйтеп үткән бу төр әниләр, балалар белән аралашу, шундый фикергә китерә – безнең бурыч булып шушы нәни кыз балалардан акыллы, тәрбияле, нәфис, кешелекле хатын-кызлар тәрбияләп үстерү.

# СОВРЕМЕННЫЙ ВЗГЛЯД НА ПЕДАГОГИЧЕСКИЕ ИДЕИ ТАТАРСКОГО ПРОСВЕТИТЕЛЯ ШАКИРЗЯНА ХАМИДИ

**Тагирова Эльвира Радиковна**
*МАДОУ «Детский сад №315»*
*Ново-Савиновского района г. Казани*
*Воспитатель*

Педагоги-просветители оставили богатейшее педагогическое и методическое наследие, которое еще не изучено в достаточной мере и не полностью стало достоянием широкой общественности. И чтобы это наследие стало действенным подспорьем в нравственном воспитании подрастающего поколения, необходимо его обстоятельное исследование, дальнейшая разработка, творческое развитие и применение выдвинутых в нем идей на практике.

Именно поэтому изучение деятельности прогрессивных для своего времени татарских просветителей, внесших огромный вклад в дело просвещения народа, является важной и актуальной задачей.

Актуальность данного исследования состоит в том, что особо важную роль в развитии личности человека играют педагогические ценности предшествующих поколений. Изучение наследия педагогов – просветителей раскрывает его огромное воспитательное значение для нас – потомков. Правильное использование этих знаний позволит более эффективно и успешно осуществлять обучение и воспитание подрастающего поколения в современном обществе.

В своем исследовании я рассматриваю педагогические идеи татарского педагога, просветителя Шакирзяна Хамиди.

Несмотря на то, что в татарской энциклопедии при переводе на русском дана информация о родном брате Шайхислам Хамиди, о Шакирзяне ничего не написано. Между тем в его книге о нравственном воспитании освещены общепедагогические проблемы школьного образования, подготовки учителей, представляющий огромную ценность для современной педагогической науки и практики, которые целостно не изучены и не разработаны. В этом и состоит противоречие между необходимостью исследования педагогического наследия татарского просветителя Шакирзяна Хамиди, возможностью использования содержательного и воспитательного материала этого наследия в условиях современных образовательных учреждений и не изученностью факторов формирования педагогических факторов и обобщенностью его трудов в целом.

Это противоречие подтверждает очевидность существования историко-педагогической проблемы: какие социально-политические, историко-педагогические условия и факторы сформировали просветительское мировоззрение и педагогические взгляды Шакирзяна Хамиди; каковы содержание и научно-методическое обеспечение образования в педагогическом наследии учёного?

Цель исследования состоит в том, чтобы проанализировать и обобщить педагогические взгляды Шакирзяна Хамиди, выявить те рекомендации из его наследия, которые связаны с обучением и воспитанием будущих поколений.

В соответствии с этой целью были определены следующие

Задачи исследования:

1. Изучить педагогическую деятельность и наследие прогрессивного татарского педагога и просветителя Шакирзяна Хамиди.
2. Рассмотреть педагогические принципы воспитания и обучения на основе книги Шакирзяна Хамиди о нравственном воспитании.
3. Разработать методы и формы использования позитивных идей татарского деятеля просвещения в современном ДОУ.

Педагогическое наследие Шакирзяна Хамиди мы рассматриваем как имеющее большой научный интерес не только с точки зрения истории развития образования и педагогической мысли, но и решения современных проблем совершенствования содержания и методов воспитания и обучения. Это и объясняет выбор темы работы: «Современный взгляд на педагогические идеи татарского просветителя Шакирзяна Хамидуллина».

Книгу Шакирзян Хамиди можно поделить на несколько частей. Книга начинается с упоминания Бога-Аллаха «С именем Аллаха Милостивого, Милосердного». Это подтверждает, что главной целью татаро-мусульман в получении знаний, воспитания и обучения детей опирается на законы и предписания Всевышнего. Вначале он представил свод правил для детей школьного возраста по нравственному воспитанию, которое состоит из пятидесяти правил. Далее, наставления детям, чтобы они старались. Следующая глава – наставления для бедных-инвалидов. Далее обучение предметам по математике, обучение календарю. Последняя глава – это разъяснение о ученых – богословах.

Особо важное значение Шакирзян Хамиди в воспитании детей отводит в познании Бога. Хамиди говорит, что людей из ничего создал Всевышний и приказал жить в соответствии с Его законами. Каждый человек

должен учиться и быть образованным. Без знаний нельзя постичь Бога, религию ислам.

Эти правила, можно применить в работе с детьми после изучения определенной темы, рассказа, сказки или ситуации. Необходимо разобрать это правило. Родителям можно раздать памятки, чтобы они повторяли детям с утра, как наставление.

Система воспитания, выработанная, татарскими педагогами и просветителями представляла собой феноменальное явление в педагогической жизни татарского общества. Педагогические идеи и взгляды Шакирзяна Хамиди сыграли основополагающую роль в формировании единой системы нравственного воспитания татарской молодежи. Они представляют несомненный интерес и для современных педагогов-практиков и ученых. Научно-образовательная деятельность Шакирзяна Хамиди, как универсальную образовательная технология, с успехом может применяться в работе учителями с учащимися самого разного возраста, склонностей и способностей.

Данное исследование выявило актуальность и значимость идей и высказывания педагога просветителя о формах обучения и воспитания детей для современной дошкольной и школьной практики. Наиболее интересными, на мой взгляд, являются их мысли о самообразовании, о нравственной, умственной и трудовой подготовке в условиях школы и семьи. В них большая роль отводится народному учителю в учебно-воспитательном процессе, перед которым ставятся требования, не потерявшие своей актуальности и значения и в настоящее время.

## БӨЕК ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕНЕҢ ПЕДАГОГИК МИРАСЫ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН КОНТЕКСТЫНДА

**Фадеева Нина Валентин кызы**
*Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе төп гомуми белем бирү мәктәбе*
*Югары квалификация категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар, конференциядә катнашучылар!

«Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», – дибез. Сүз дә юк, башка халыклар кебек үк, без дә үз тарихыбызны өйрәнергә, белергә тиешбез. Безнең төп бурыч – мәдәниятебезне, телебезне һәм дөрес тарихны киләчәк буыннарга җиткерү.

2023 нче ел Республикабызда «Милли мәдәниятләр һәм горефгадәтләр», ә Рәсәйкүләм «Педагог – остазлар» елы буларак игълан ителде.

36 ел эш стажлы югары квалификацияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, мин элеге мәртәбәле конференциядә катнашуны кирәк санадым һәм Казан арты Питрәч ягында туып үскән күренекле шәхесебез турында мәгълүмат тупладым.

Сүзем тел галиме, педагогия фәннәре кандидаты, К. Насыри исемендәге премия иясе, доцент Николай Валентинович Максимов хакында.

Николай Валентинович Максимов 1956 нчы елның 14 нче декабрендә Питрәч районы Керәшен Сәрдәсе авылында туа.

1964 – 1974 нче елларда үз авылында урта мәктәпне тәмамлап, колхозда шофер булып эшли башлый.

1975 – 1977 нче елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

Кайткач, яңадан шофер булып эшләвен дәвам итә. Эш барышында, институтка барып имтиханнар биреп кайта. Егеткә институтка укырга чакыру килгәч, ул, колхоз рәисенә барып, укырга барырга рөхсәт итуләрен сорый. Шулай сентябрьдә укырга китеп бара.1977 – 1982 нче елларда Казан дәүләт педагогия институтында белем ала.

Югары белемле яшь белгеч Казанның 90-нчы мәктәбендә татар теле укытучысы булып эшли башлый. Ул биредә 1982 – 1987 нче елларда эшли. Шуннан башлана инде Николай Максимовның китап - дәфтәрләр, фән белән саташып узган йокысыз төннәре...

Биш ел мәктәптә укытканнан соң, 1987 – 1990 елларда Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыны аспирантурасында укый.

1991 елда академик М.З. Зәкиев җитәкчелегендә «Заманча әдәби татар телен үстерүдә калькалаштыруның роле» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. 1991 – 1992 елларда әлеге институтта фәнни хезмәткәр вазифасын башкара.

1992 нче елдан 1997 нче елгача Николай Валентинович Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләренә белем бирү институтының татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасын җитәкли.

1997 – 2007 нче елларда Н.В.Максимов С.М.Киров исемендәге Казан дәүләт Технология университетында ике телдә укыту методик үзәгенең директоры вазифасын башкара. Бу еллар аралыгында ул элеге институтта 18 фәннең татар телендә укытылуына узеннән күп көч кертә:

дәреслекләрне татар теленә тәрҗемә итә. Максимов Н.В. редакциясендә Казан дәүләт технология университетының татар төркемнәрендә белем алучы студентларны укыту өчен 60 тан артык укыту-методик әсбап нәшер ителә.

2003 – 2007 нче елларда Николай Валентинович бередә кафедра доценты.

2006 – 2008 нче елларда Н.В.Максимов фәнни редакциясе астында Р.З.Хәйдәрованың рус телендә белем бирүче урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 8 һәм 9 сыйныфларына (рус телле укучылар өчен) «Татар теле» дәреслекләре; татар телендә белем бирүче урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 5 нче – 11 нче сыйныфларына «Татар теле» дәреслекләре нәшер ителә.

2007 – 2009 нче елларда Николай Валентиновичны кабаттан Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләренә белем бирү институтының татар теле һәм әдәбиятын укыту кафедрасы җитәкчесе итеп билгелиләр.

2009 нчы елның 1 нче сентябреннән 2017 нчы елга кадәр татар дәүләт гуманитар – педагогия университетының (бүген КФУ составында) татар теле һәм халыкара коммуникацияләр кафедрасы доценты. Шулай ук мәгариф өлкәсендәге хезмәткәрләрне «Татар теле һәм әдәбияты» укытучысы белгечлегенә әзерләү курслары җитәкчесе булып та эшли.

2003 – 2017 нче еллар аралыгында 3 тапкыр татар телен укыту программасын яза.

2017 нче елдан Николай Валентинович Максимов Казан мәктәпләрендә рус балаларын татарча сөйләшергә өйрәту юнәлешендә үз программасы буенча укыту-эксперимент эшчәнлеген башлап җибәрә. «Сөйләм калыпларына нигезләнеп, татар теленә өйрәтү технологиясе» дигән дәреслеге кысаларында мастер-класслар, укытучылар өчен ачык дәресләр уткәрә. Татар теле, әдәбият дәресләре укыта. Николай Валентиновичның әлеге эше шушы көндә дә уңышлы дәвам иттерелә, Бөтенроссиякүләм кулланылышта.

2018 – 2019 нчы елларда Николай Валентинович КФУның дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбендә, Республикабыз җитәкчелеге кушуы буенча, идарә органы хезмәткәрләренә татар телендә сөйләшергә өйрәнү күнекмәләре дәресләре бирә.

**Тел белгече, туган (татар) телендә белем бирү буенча 6 дистәләп хезмәт авторы Николай Валентинович Максимовның нәсел тамыры 156 еллык стажлы педагогик** мираслы укытучы – мәгърифәтчеләргә тоташа.

1867 нче елның 4 нче маенда Николай Иванович Ильминский Сарапулда мәктәп ачу мөмкинлеге турында Россия мәгариф министры граф Толстойга хат яза. Хатта: «Урай-Чаллы, Карабаян, Казиле, Югары Сәрдә, Ташкирмән авылларында мәктәп ачарга була», – дигән юллар була.

Архив язмаларыннан күренгәнчә, Керәшен Сәрдәсендә мәктәп (элек Казан губернасы, Лаеш өязенә керә) 1867 елда ачылган. Бу – керәшен телендә укытучы керәшен-татар классы мәктәп була. Мәктәпнең беренче укытучысы – Дмитрий Максимов, ягъни Николай Валентинович Максимовның өченче буын бабасы була. Укытучы балаларны өендә укыта. Мәктәп дворянин Максимовның үз йортында урнаша.

Югары Сәрдәдә мәктәбенең беренче укытучысы Дмитрий Максимов булуы турында халыкка авылның мактаулы кешесе, сугыш һәм хезмәт ветераны, полковник Георгий Алексеевич Токинов та сөйли. Токиновлар һәм Максимовлар күрше яшиләр.

1884 нче елда мәктәптә укучылар саны: 42 малай; 1886 елда – 45 малай, 7 кыз; 1890 елда – 44 малай, 17 кыз, 1918 елда – 57 малай, 18 кыз…

1872 елдан мәктәп земство ведомствосына кабул ителә.

Максимовлар нәселе раскулачивать ителгәннән соң, бина Совет власте кулына күчә (1930 нчы еллар). 1960 нчы елларда бина яңадан мәктәп биләмәсенә кайтарыла.

1920 елга кадәр керәшен Сәрдәсе авылы «Югары Сәрдә» дип атала. Югары Сәрдә мәктәбе «Изге Гурий туганлыгы» җәмгыяте системасында ачыла һәм аның җитәкчелегендә эшли. Әлеге ширкәткә 1867 елда нигез салынган һәм хәзерге Питрәч районы территориясендә тугыз авылда мәктәп ачылган. Бу мәктәпләр 1867 елдан 1917 елга кадәр әлеге җәмгыять хисабына яши. 5 елдан соң (1872 елда) Югары Сәрдә мәктәбе земство карамагына күчә.

Бу мәктәпләрдә 8 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балалар өчен 3 еллык уку каралган була. 1907 елдан «рус булмаган» мәктәпләр 4 еллык укуга күчерелә. Класста бер үк вакытта ике яки өч төркем белем ала. Даими укыту программасы булмый. Нигездә, балалар укырга, хисапка, җырларга өйрәтеләләр. Кече һәм урта төркемдә – керәшен, зурлар төркемендә рус телендә белем алганнар. Уку елы 160 көн, 25 сентябрьдән 15 апрельгә кадәр дәвам итә.

Телдән сөйләнгән һәм тарихи чыганаклар буенча, Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе авылында, гомумән, мәгарифкә Максимовлар-Сердинскийлар һәм аларның туганнары зур өлеш кертә. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, рус телен белгәнгә, армиягә офицерлар булып хезмәт

итәләр һәм Идел буеның төрле почмакларында укытучылар булып эшлиләр.

Кайберләренең тулы исемлеген язып китәмен:

– Максимов Николай Петрович (1899 – 1942) Лаеш районы авыл мәктәпләрендә укытучы булып эшләгән. Имән Кискә һ. б.).

Бу исемлектә Николай Максимовичны (1843 – 1912) һәм аның балаларын аеруча аерып күрсәтергә кирәк. Барлык җиде баласы да (биш ул һәм ике кыз) Сәрдә земство мәктәбендә укыган һәм зур тормышка юллама алган.

– Ольга Николаевна Афанасьева (1869. Казан һәм Мәскәүдә халык мәгарифе министрлыгы системасында эшләгән.

– Гурий Николаевич (1872-1963) 1881-1885 еллардан 1932 елга кадәр Керәшен Сәрдәсе авылында башлангыч авыл мәктәбе укытучысы булып эшли. 1932 елдан Лаеш шәһәре урта мәктәбендә эшли. Соңгы гомерен Лаеш районы Мирәтәк авылында уздыра.

– Мария Николаевна Князева (1880. Мәскәүдә халык мәгарифе министрлыгы системасында эшләгән.

– Федор Николаевич Сердинский (1886 – 1942).

– Иван Григорьевич Токинов (1891–... ) авыл мәктәбе укытучысы булып эшли.

– Василий Григорьевич Токинов (Текин) (1894 – 1918) хәзерге Кукмара районы Яныл керәшен авылында укытучы булып эшли.

Кызганычка, мәктәп архивы сакланмаган, Максимовлар династиясе турында да тулы мәгълүмат тупланып бетмәгән.

Хәзерге көндә дә Максимовлар династиясендә укытучылык итү онык-оныкчыкларда горур төстә дәвам иттерелә. Алар үзләренең ата-баба тарихын, аларның тормыш юлын, укытучылык эшчәнлеген яхшы белә, килер буыннарга тапшыра. Буген бөтен Татарстан, Рәсәй җирендә, төрле төбәкләрдә шушы тамыр дәвамчылары мәгариф өлкәсендә эшләвен дәвам итә.

**Материалны язганда кулланылган әдәбият исемлеге:**

1. В. М. Беркутовның «Татарстан территориясендә революциягә кадәрге мәктәпләр» тарихи-педагогик белешмәлеге.

В исследование PISA включены задания разного типа. Почти половину из них составляют вопросы, предполагающие свободные ответы. А есть вопросы с определённым, нерасширяемым списком ответов. Это значит, что ученик должен выдать самостоятельный ответ, который будет ограничен конкретными словами или числами. Почти треть всех заданий в тесте составляют вопросы с готовыми вариантами ответов. Главное отличие программы PISA от ЕГЭ, ОГЭ и других российских тестов заклю-

чается в том, что она, в первую очередь, оценивает возможность школьников руководствоваться логикой при выполнении нестандартных задач. В этом отношении можно сказать, что PISA следует современным образовательным трендам, ведь способность учеников применять школьные знания в жизни – это важнейший аспект функциональной грамотности и навыков XXI века.

Наша школа в составе всего лишь 8 школ со всей Республики Татарстан в конце января прошлого года методом случайной выборки попала в план международного исследования PISA. Мы с 6 учениками этого возраста и педагогами, их обучающими, около трех месяцев скрупулезно готовились к этому исследованию. Но в связи с санкциями участие Российской Федераций отменили в данном тестировании. Но 12 октября уже только один на тот момент 15-летний ученик 9 класса нашей школы принял участие уже в общероссийской оценке качества также по модели PISA. Результаты, надеемся, хорошие он показал, но какие, узнаем только в конце этого или начале следующего учебного года.

Когда нам сообщили, что Ульянковская школа попала в международное исследование, в первую очередь мы проинформировали родителей о международном исследовании PISA, где наши 15-летние обучающиеся (их у нас было шестеро: 5 девятиклассников и одна восьмиклассница) должны были принять участие. Мы определили ответственных за подготовку к международному исследованию, была организована работа по формированию функциональной грамотности обучающихся 8, 9 классов с использованием инструментария PISA с введением в уроки, внеурочную деятельность разбора заданий на сайтах: РЭШ, института стратегии развития образования, ФИОКО, ФИПИ.

Еженедельно специалисты МОиН РТ проводили ВКС с руководителями школ и начальниками отделов образования; методическую и информационную помощь по подготовке обучающихся к международному исследованию оказывали преподаватели Приволжского межрегионального центра повышения квалификации и профессиональной переподготовки работников образования, Института развития образования Республики Татарстан, Центра оценки профессионального мастерства и квалификации педагогов, специалисты Москвы проводили еженедельные вебинары по направлениям функциональной грамотности.

Актуализируя материалы стратегических сессий по развитию функциональной грамотности, мы с педагогами обсуждали затруднения в процессе подготовки к PISA; анализировали структуру уроков и методические рекомендации в контексте подготовки к исследованию, а также

интегрируем до сих пор тренировочные упражнения РЭШ, ИСРО, «докрученные» материала учебника в уроки; в рамках внеурочной деятельности проводим квест-игры «Путешествие по функциональной грамотности».

И сейчас в нашей школе продолжается работа по формированию уровня функциональной грамотности обучающихся с использованием инструментария PISA с введением в уроки, внеурочную деятельность разбора заданий на сайтах: РЭШ, ФИОКО, ФИПИ.

## ФОРМИРОВАНИЕ ФУНКЦИОНАЛЬНОЙ ГРАМОТНОСТИ НА УРОКАХ ФИЗИКИ И ВО ВНЕУРОЧНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ

**Четверикова Елена Николаевна**
*МБОУ «Школа №91» г.Казани*
*Учитель физики*

В современных условиях к образовательному процессу предъявляются особые требования, так как дети должны показать результаты в быстро меняющемся мире. Сегодня происходит переориентация: от предметной оценки к оценке функциональной грамотности. И, конечно же, учитель не может оставаться в стороне. Формирование функциональной грамотности школьников сегодня набирает такую значимость, что каждый учитель вовлечен в формирование функциональной грамотности школьников.

Как можно формировать функциональную грамотность на уроках физики и во внеурочной деятельности?

Урок проведения лабораторной работы «Определение КПД наклонной плоскости» 7 класс в форме проектной работы «Пандус в школе».

Для актуализации я использовала задания ФИПИ открытый банк заданий для оценки естественнонаучной грамотности обучающихся вариант 7 (вопросы 14,15,16,17). Здесь формируются естественнонаучная (умение распознавать простые механизмы на рисунках), читательская (умение выделять нужную информацию из текста), математическая (знать формулу выигрыша в силе и сделать соответствующие вычисления) грамотности.

Целью проектной (лабораторной) работы является доказательство важности использования простых механизмов, в частности наклонной плоскости, в повседневной жизни человека и рассмотрение пандусов.

На этапе исследования у учащихся формируется естественнонаучная (умение объяснить физическое понятие – КПД), читательская (умение

понимать прочитанную информацию), математическая (умение работать с формулами, вычислительные навыки) грамотности и глобальная компетентность (изучение местных проблем, успешное и уважительное взаимодействие с другими).

Класс делится на группы, у каждой свой исследовательский вопрос. Учащиеся выдвигают гипотезы, записывают ход исследования, анализируют полученные данные и делают выводы.

- Как зависит КПД при подъеме тела по наклонной плоскости от высоты наклонной плоскости?
- Как зависит КПД при подъеме тела по наклонной плоскости от веса тела?
- Как зависит КПД при подъеме тела по наклонной плоскости от поверхности наклонной плоскости?
- Вычисление КПД лестницы. Где лучше разместить пандус в школе.

В конце урока учащиеся доказывают свою гипотезу и защищают проект «Пандус в школе».

В течении всего урока идет формирование:

1. Естественнонаучной грамотности – развитие способности использовать естественнонаучные знания для объяснения явлений.
2. Читательской грамотности – развитие умений анализировать текст, рисунки, понимать информацию, имеющуюся в тексте.
3. Математической грамотности – развитие способностей использовать математические знания в разнообразных ситуациях, требующих для своего решения различных подходов, размышлений.
4. Глобальной компетентности – развитие умений вступать в открытое, уважительное и эффективное взаимодействие с другими людьми.

Формирование функциональной грамотности происходит не только во время учебной деятельности, но и внеурочной.

Исследовательская работа «Физические явления в произведениях С.Т. Аксакова».

Мы выбрали произведения С.Т. Аксакова «Записки об уженье рыбы» и «Записки ружейного охотника Оренбургской губернии», которые необходимо было не только прочитать, но и найти физические явления. Объяснить и сравнить эти явления. В данной исследовательской работе учащиеся учатся преобразовывать одну форму представления данных в другую, применять соответствующие естественнонаучные знания для объяснения явлений, анализировать и делать соответствующие выводы, таким образом, формируется естественнонаучная, читательская грамотности (функциональная грамотность).

| ЗАПИСКИ... | ФИЗИКА |
|---|---|
| «Для погружения себя в воду и стояния на всех ее глубинах имеет она во внутренности своей пузырь, лежащий вдоль спинного хребта, наполненный воздухом и перетянутый на две неравные половинки: должно предположить, что посредством сжиманья и разжиманья этого пузыря рыба погружается вниз или поднимается вверх» | Для того чтобы всплыть из глубины в поверхностные слои воды, рыба раздувает свой плавательный пузырь; тогда объем ее тела увеличивается, вес вытесняемой воды становится больше ее собственного веса – и, по закону плавания, рыба поднимается вверх. Чтобы прекратить подъем или опуститься вниз, она, напротив, сжимает свой плавательный пузырь. Объем тела, а с ним и вес вытесняемой воды уменьшаются, и рыба опускается на дно согласно закону Архимеда. |
| «Нырки, чернь и свиязь чаще всех машут крыльями и быстрее рассекают воздух: шум от их полета сливается в один дребезжащий, пронзительный свист...Заблеял дикий барашек, кружась в голубой вышине весеннего воздуха, падая из-под небес крутыми дугами книзу и быстро поднимаясь вверх…» | От сопротивления воздуха кончики перьев начинают сильно дрожать и производят звуки – чем больше частота, тем выше звук. |

Использование подобных заданий на уроках физики и во внеурочной деятельности, позволяет учителю предоставить возможность ученикам размышлять над своими знаниями и убеждениями, задавать вопросы, пополнять объём знаний, перестраивать своё понимание, формулировать выводы, то есть активно участвовать в процессе учения, что повышает их функциональную грамотность. Тем самым, позволяет добиться высоких результатов.

**Литература**

1. Богданова В.А. Формирование информационно-функциональной компетентности школьников в процессе реализации личностно ориентированной модели педагогического процесса / В.А. Богданова – Педсовет.org. – 2007

2. 3. Зайцев, В. Формирование ключевых компетенций учащихся /В. Зайцев //Сельская школа. – 2009. – №5.

3. Коваль Т.В., Дюкова С.Е. Как оценивать умения учащихся в сфере глобальных компетенций // Отечественная и зарубежная педагогика. 2019. Т.1.

4. ФИПИ, открытый банк заданий для оценки естественнонаучной грамотности.

# Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә функциональ грамоталылык формалаштыру

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ БЕЛЕМЛЕЛЕГЕН ҮСТЕРҮ (УКУ ГРАМОТАЛЫЛЫГЫ)
## (Мастер-класс)

**Алкина Наилә Мәхмүт кызы**
*Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Осиново бистәсенең «В.В.Карпов исемендәге лицей» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

**Аннотация**

Мәгариф стандарты таләпләре шундый: традицион «грамоталылык» төшенчәсе белән беррәттән «функциональ грамоталылык» төшенчәсе барлыкка килә. Шәхеснең гади кыска текстларны уку, аңлау, төзү, фикер йөртү төзү һәм иң гади арифметик гамәлләр башкару сәләте буларак элементар грамоталылыктан тыш, җәмгыятьтә уңышлы адаптацияләнү, һөнәри үсеш өчен «функциональ грамоталы» шәхес формалаштырырга кирәк. Мастер-класс үткәрү файдалы, чөнки мастер-класста катнашучылар татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә функциональ грамоталылыкны формалаштыру буенча төрле төр биремнәр турында белем алачаклар, үз практикаларында алган белемнәрен куллана алачаклар.

**Мастер-классның темасы:** Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның функциональ белемлелеген үстерү (уку грамоталылыгы)

**Максат**: тыңлаучыларны татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә уку грамоталылыкны формалаштыру алымнары һәм ысуллары белән таныштыру

**Бурыч:**

– эш алымнары белән танышу аша мастер-класс эчтәлеген ачу;

– әлеге эш алымнарын куллануның гамәли әһәмиятен, аларны дәресләрдә куллануның максатка ярашлылыгын күрсәтү.

**Җиһазлар:** кушымталар, тарату материалы.

## Мастер-класс барышы

### I. Төп өлеш

**1. Нигә функциональ грамоталылык кирәк?**

PISAНЫҢ дөньякүләм мониторингыннан соң,күпләргә бу компетенция белем бирү программасында «баналь рәвештә» барлыкка килгән кебек тоелырга мөмкин. Чынлыкта исә процесслар күпкә глобальрәк һәм бөтен дөньяда барган үзгәрешләр белән аңлатыла. Һәм бу катлаулы һәм тиз чынбарлыкта яшәр өчен, бүгенге мәктәп укучыларына яңа күнекмәләр, белемнәр һәм күнекмәләр кирәк булачак.

**2. Функциональ грамоталылык нәрсә ул?**

• Дөньяда барган глобаль үзгәрешләр Глобаль компетенцияләр дә таләп итә.

Функциональ грамоталылык үз эченә ала:

• Математик

• Финанс

• Табигать фәннәре

• Глобаль компетенцияләр

• Укучы

• Тәнкыйди фикерләү

**3. Галимнәр бу турыда нәрсә әйтәләр?**

Россия педагогы, РАО әгъза-корреспонденты Наталья Федоровна Виноградова, «кече мәктәп укучысының функциональ грамоталылыгы: укытучы өчен китап» басмасы

• Бүген функциональ грамоталылык-шәхеснең төп белеме. Балага ия булу мөһим:

• Үзгәрә торган дөнья белән уңышлы аралашырга әзерлек;

• Төрле (шул исәптән стандарт булмаган) уку һәм тормыш мәсьәләләрен хәл итү мөмкинлеге;

• Социаль мөнәсәбәтләр төзү сәләте;

• Үз грамоталылыгын бәяләүне, алга таба белем алуга омтылуны тәэмин итүче рефлексив күнекмәләр җыелмасы белән.

Алексей Алексеевич Леонтьев, РАО Академигы, 2100 нче мәктәп басмасы. Сәламәт акыл педагогикасы»

Функциональ яктан грамоталы кеше-ул кеше эшчәнлегенең, аралашуның һәм социаль мөнәсәбәтләрнең төрле өлкәләрендә тормыш бурычларының максималь киң диапазонын хәл итү өчен гомер дәвамында даими рәвештә үзләштерелгән барлык белемнәрне, күнекмәләрне һәм күнекмәләрне куллана алган кеше.

**4. Функциональ уку нәрсә ул?**

• Конкрет мәсьәләне хәл итү өчен мәгълүмат табу максатыннан уку. Функциональ уку түбәндәге күнекмәләрне үзләштерүне күздә тота:

• Мәгълүмат эзләү

• Укыганны аңлау-монда без мәгънәле уку турында сөйләшәбез

• Алынган мәгълүмат белән эшләү (бәяләү, аңлату) – монда без тәнкыйди фикерләү турында сөйләшәбез.

• Үз бурычларын хәл итү өчен мәгълүмат куллану.

Бу күнекмәләр балачактан ук формалаша, аларның дәрәҗәсе мәктәпкәчә үсешкә, ата-аналар һәм укытучыларның йогынтысына, мәктәп программасына һәм кешенең үзенә бәйле.

**5. Укучыларга без нәрсә тәкъдим итә алабыз?**

**Иҗади эшчәнлеккә җәлеп итү**

**1. Иҗади эшчәнлеккә җәлеп итү**

Беренче эш алымым иҗади эшчәнлеккә җәлеп итү..

Бу алым «Тәрәзәле язу» алымы дип атала. Әлеге алым дәрестә текст белән эшләгәндә, элек үзләштергәнне тикшерү һәм яңа материалны өйрәнгәндә отышлы.

«Тәрәзәле язу» алымы уйланырга мәҗбүр итә, сүзләрне урынлы файдаланырга этәрә, сүз байлыгын арттыра. Укучы әлеге тәрәзәчекләргә сүзләрне тутырып бетергәч, нәрсә килеп чыгуын түземсезләнеп көтә.

«Шаккатыр» алымы, «Хатаны тап» алымнары да бик унышлы

**2. Образлар аша тәрбияләү**

Хәзерге заман баласының психикасы бик нечкә, ул өзелергә торган җеп кебек. Кешенең яхшы һәм яман сыйфатларга ия булуын укучылар шушы образлар аша күрәләр. Ләкин кешенең нинди булуына карамастан, аның бу дөньяда яшәргә хаклы икәнен аңлату кирәк. Әсәрне анализлау нәтиҗәсендә иң тискәре геройларның төптә яшерелгән уңай сыйфатлары барлыгы күренә,һәр килеп туган кыен ситуациядән дә чыгу юлы барлыгы ачыклана һәр образ – укучы өчен тормыш мәктәбе. Әсәрдәге образлар аша укучы үзенә уңай сыйфатларны үзләштерә, әхлакый тәрбия ала.

**3. Символлар белән эш**

Символлар белән эшләү укучыларда әсәр укуга кызыксыну уята.

Әсәрнең эчке, яшерен, серле мәгънәсен ачыклауга омтылыш тудыра.

**4. Төсләр ни сөйли**

Кара төснен һәрвакытта да тискәре төс булмавын, ә ак төснең һәрвакыт чисталыкны гына аңлатмавын шушы анализ вакытында күрәләр. Әдәби әсәрдәге төсләр укучыларга сүз артына яшерелгән тел төбен аңларга ярдәм итә.

Әлеге чыгышымда *ФУНКЦИОНАЛЬ БЕЛЕМЛЕЛЕК* нең нигезендә яткан уку грамоталылыгын үстерү өстендә алып барган эш тәҗрибәм белән уртаклаштым. Әлбәттә, бу алымнар беркемгә дә яңалык түгел, аларны без һәрберебез кулланабыз. Хәзер яңача укыту алымнары, технологияләре килеп керде. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, укытуның һәр этабы өчен уку материалын үзләштерүнең иң уңышлы вариантын кулланып эшләү, укучыларга алган белемнәрен тормышта куллана белергә өйрәтү. Әгәр балага бер генә китапның, бер генә әсәрнең матурлыгын,фикер тирәнлеген күрсәтә алсак, укучыны мәңгегә китап укуны яратырлык, китап дөньясында йөзәрлек итеп тәрбияли алуыбызга ышанам.

## ДИСТАНЦИОН БЕЛЕМ БИРҮ ШАРТЛАРЫНДА GOOGLE ФОРМАЛАРНЫ КУЛЛАНУ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ

**Гарифуллина Миләүшә Фәрит кызы**
*3 нче номерлы Биектау гомуми*
*урта белем бирү мәктәбе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Цифрлы икътисадның алга таба үсеше өчен уңай шартлар тудыру, цифрлы технологияләрне, Татарстан Республикасы халкының тормыш сыйфатын арттыручы сервисларны һәм хезмәтләрне нәтиҗәле үстерү максатларында 2022 ел Татарстан Республикасы Президенты Р. Н.Миңнеханов Указы белән Татарстан Республикасында цифрлаштыру елы дип игълан ителде. Республикабыз һәрвакыт яңалыкларда алда булырга ярата. Шуңа да эшне заманча оештыру өчен халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә дә, белем бирү системасын да цифрлаштыру зарурлыгы килеп басты. Цифрлы педагогика үз эченә төрле цифрлы технологияләрне (компьютерлар, гаджетлар, программмалар белән тәэмин итү һ.б.) ала һәм шуның нәтиҗәсендә белем бирүнең югары сыйфатын тәэмин итә.

Хәзерге вакытта әйләнә-тирәдәге цифрлы мохит кече яшьтән башлап, бала тормышының аерылгысыз өлешенә әверелде. Компьютер чаралары танып-белү, тикшеренү,уен эшчәнлеге процесслары замана балалары өчен көндәлек, кызыклы шөгыль, яңа белемнәр һәм тәэсирләр алу өчен кулай ысул булып тора.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысына хәзерге шартларда балаларда туган телгә карата кызыксыну, мәхәббәт уяту өчен аеруча тырышырга кирәк. Шуңа күрә без дә заманадан артта калмаска, белем бирүдә төрле чаралар кулланырга тырышабыз.

Соңгы елларда онлайн-дәресләр дә уздырырга туры килә. Карантин, имтихан вакытларында дистанцион укытуга күчәргә туры килә. Андый вакытларда мин Google формалар белән эшләргә яратам. Бу кушымта барыбызда да бар инде. Телефоннарыбызда да бар. Анда эшләгән тестлар балаларның белемнәрен тикшерү өчен укытучыга да бик уңайлы, балага да кызыклы.

Тестларның сорауларына балларны билгеләп, автомат рәвештә тикшерелә торган итеп тә эшләп була. Безгә кайвакыт тиз генә мәгълүмат алу өчен Google формаларда сораулар җибәрәләр. Дәрестә узган тема буенча шундый сораулар җибәрсәң, укучыларга кызык булып китә. Шулай ук укытучыга да тиз генә белемнәрне тикшереп билгеләр куярга бик уңайлы. Аннан соң бу формаларда презентацияләр эшләргә дә җиңел. Телефонда гына да эшләп була.

Һәм шунысы мөһим, алар телефонда урын алып тормыйлар. Дистанцион укыту вакытында күбебез ватсаптан биремнәр биреп, аннан алар җибәргән фотолар белән бөтен телефон тулды бит. Ә Google форматта җибәргән биремнәр телефонның хәтерен тутырмыйлар. Һәм телефонда Google диск аркылы теләсә кайсы вакытта кирәкле мәгълүматны табып, балаларга биремнәрне телефоннан гына да җибәреп була.

Менә соңгы вакытта Google класс кушымтасын куллана башладым. Анысы сыйныф белән эшләү өчен тагын да җайлаштырылган. Бу кушымта белән эшләгәндә һәр сыйныфка аерым курс төзеп, укучылар шунда ссылка буенча кереп биремнәрне үти алалар, презентацияләрне карый алалар. Бу кушымта түләүсез, вакыты чикләнмәгән булуы белән дә бик отышлы. Укучылар биремнәргә комментарийлар да яза алалар.

Мондый эш төрләре куллану укучыларда фәнгә карата кызыксыну уята, телне өйрәнү теләген арттыра.

Гомумән, интернетның без белгән мөмкинлекләре күп, без белеп бетермәгәннәре тагын да күптер. Сезнең арада бу мөмкинлекләрдән бик оста файдаланучылар да байтактыр. Мин бары үземә ошаган эш формасы белән таныштырып киттем. Бу формалар нәкъ менә онлайн укыту, белемнәрне тикшерү, өй эше бирү өчен уңай. Ә инде дәрестә, һичшиксез укучы белән җанлы әңгәмә булырга тиеш дип саныйм.

# ДИСТАНЦИОН УКУ ШАРТЛАРЫНДА ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕН ҮТКӘРҮДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ПЛАТФОРМАЛАРЫ ҺӘМ СЕРВИСЛАРЫ

**Гатауллина Алина Абелгасовна**
*МБОУ «Школа №130» г.Казани*
*Учитель родного языка и литературы*

Бүгенге көндә дистанцион уку шартларында туган тел һәм әдәбият дәресләрен үткәрүдә чит ил һәм рус телле белем платформаларын куллану мөмкинлекләре булырга тиеш дип уйлыйм.

Бу проблеманың **актуальлеге** түбәндәгеләргә бәйле: беренчедән, туган телгә һәм әдәбиятка өйрәтүнең сыйфатын арттырса; икенчедән, укучыларның төп компетенцияләрен формалаштыруга ярдәм итә торган нәтиҗәле ысуллар һәм алымнар сайларга мөмкинлек бирә.

Белем бирү платформаларын эзләгәндә мин үз алдыма дистанцион дәреснең барлык этапларын тормышка ашыра алырлык сервислар сайлауны **төп бурыч** итеп куйдым.

Платформалар белән эшләү өчен махсус белемнәр яки күнекмәләр кирәкми, компьютер, планшет яки интернетка керү мөмкинлеге булган смартфон гына да җитә. 2020 елда башланган дистант чорыннан бирле zoom популяр иде, ләкин, кызганычка каршы, аның куллану вакыты чикләнгән. Хәзер **Сферум** кебек сервис популярлаша бара. Бу кушымта даими үсә, яңа функцияләр һәм мөмкинлекләр өстәлә. Бүген платформа күп яктан социаль челтәрне хәтерләтә, анда берләшмәләр булдыру мөмкинлеге дә бар. Аңа укытучылар, мәктәп укучылары һәм аларның әти-әниләре керә ала. Һәр берләшмәдә модераторлар булырга мөмкин, алар контентны контрольдә тота. Мондый берләшмә эчендә конкрет предметлар буенча төркем төзү мөмкинлеге дә бар. Шулай ук программа сайланган кулланучылар белән төркемле чат ачарга, диалогларда аралашуның төрле коралларыннан файдаланырга мөмкинлек бирә.Анда текстлы хәбәрләр җибәрергә, төрле форматтагы кертелгән файлларны салырга, тавыш һәм видеоэлемтә буенча шалтыратырга, экран демонстрациясен кертергә һәм укучыларга презентацияләр күрсәтергә була.

Миңа шулай ук **Яндекс Телекүпере** платформасы ошый. Аның өстенлекләре:

– аралашуга вакыт буенча чикләүләр юк;

– чит конференцияләргә тоташканда теркәлергә кирәкми;

– фоннар галереясында рәсемнәрне сайлау мөмкинлеге зур;

– конференция өчен сылтама автомат рәвештә күчерелә;

– 35 катнашучыны берләштерә ала;

– теләсә нинди уңайлы чарада (компьютерда, планшетта, телефоннан яки браузерда) эшләргә мөмкин.

Балалар арасында геймерларның аралашу урыны (**discord**) һәм стриминг платформалары (**twitch**) популяр. Укучылар монда буш вакытта уйныйлар, аралашалар, үзләренә кулдаш (напарник) эзлиләр. Бу платформаларның үзенчәлекләреннән файллар җибәрү мөмкинлеген, күп санлы ышанычлы серверлары булуын, каналлар арасында тиз арада күчү өчен оверлей функциясе барлыгын әйтеп китәргә мөмкин.

Һәр дәрес укучыларның үз эшчәнлекләренә бәя бирүдән, аларның эмоциональ халәтен тикшерүдән, белемнәрне актуальләштерү бурычлары булган мотивацион-максатчан этаптан башлана. Бу этапта укытучыга нинди сервислар ярдәм итә ала соң? Минемчә, бу интерактив презентацияләр булдыру өчен онлайн-сервис – **Mentimeter.com.** Аның ярдәмендә сораштыру, тавыш бирү үткәрергә, укучыларның эмоциональ халәтен яки аларның реаль вакыт режимында яңа материалны өйрәнергә әзерлеген тикшерергә мөмкин. Бер уңайсыз ягы бар, хәзерге вакытта vpn белән генә эшли.

1. Дәреснең икенче этабы, кагыйдә буларак, яңа тема өстендә эшләүгә, күнегүләргә, төп күнекмәләр эшләүгә, шулай ук элегрәк өйрәнелгәннәрне кабатлауга багышлана. Әлеге этапта мин түбәндәге сервислардан файдаланам:**Padlet.com** – онлайн-такта булдыру өчен платформа. Минем өчен иң җайлы һәм аңлаешлы сервис. Укытучы һәм укучы белән турыдан-туры аралашудан тыш, укытуда язмаларны, таблицаларны, схемаларны, графикларны күрсәтү өчен тактадан файдалану мөмкинлеге булырга тиеш. Мондый такта язмалар алып бара ала торган дивардан гыйбарәт. Укучылар бу язмаларны экранда күрә, шулай ук үз комментарийларын яки постлар калдыра ала. Онлайн-такта төркемләп эшләүне нәтиҗәле оештырырга, уртак проектлар булдырырга, «ми штурмы» оештырырга, рефлексия үткәрергә һ.б.мөмкинлекләр бирә. Шулай ук киң куллану мөмкинлекләре булган Миро тактасы бар, ләкин аның интерфейсы инглиз телендә һәм анда эшләү өчен курслар үтсәң яхшырак булыр дип уйлыйм.

2. Интерактив күнегүләр булдыру өчен бик уңайлы интернет-сервис – **LearningApps.org.** Сервис мөстәкыйль үзләштерү өчен дә шактый гади. Төрле предметлар буенча классификацияләнгән бик зур әзер күнегүләр коллекциясе бар. LearningApps.org электрон интерактив күнегүләрне уңайлы һәм җиңел ясарга мөмкинлек бирә. Мөмкинлекләрнең киңлеге,

навигациянең уңайлылыгы, файдаланудагы гадилеге үзенә җәлеп итә. Монда ИКТ белән эшләүнең иң минималь күнекмәләре булган теләсә кайсы укытучы үз ресурсларын (яңа материалны аңлату, ныгыту, тренинг, контроль өчен зур булмаган күнегүләр) булдыра ала.

3. **joyteka.com** – белем бирү квестлары, дидактик уеннар («Своя игра»), терминологик сүзлекләр (флэш-карточкалар), интерактив видео булдырырга мөмкин булган белем бирү платформасы. Бу платформаны дәрәсне бәяләү этабында яки рефлексия этабында кулланырга була.

4. **umapalata.com** сервисы педагогларның игътибарын күптән җәлеп итте. 2000 елдан башлап иҗади төркем искиткеч дидактик Flash-уеннарны булдырган. Барыннан да элек, бу уеннар күп дәрәҗәле интерактив модульләрне уен формасында яшерүе белән яхшы. Алар ярдәмендә укытучы сыйныфта төрле эш формаларын (индивидуаль, төркемле, фронталь) оештыра ала.

5. Викториналар, тестлар һәм сораштырулар булдыру өчен **Quizizz, wordwall.net** сервислары бик кызыклы. Бу платформалар ярдәмендә ярышлар оештырырга, һәр укучының нәтиҗәләрен күзәтеп торырга мөмкин.Әлеге этапта барлык югарыда санап үтелгән сервисларны кулланырга мөмкин: уртак такталар, теглар болыты, Google-форма, сораштырулар, уртак презентацияләр. **Quizlet, Kahoot, Triventy, Flippity, onlinetestpad** һ.б кебек уңайлы сервисларны да актив кулланам.

Минем тагын дәрес конструкторлары төзи торган платформаларга да игътибар бирәсем килә.Алар, дистанцион уку системалары белән беррәттән, педагогларга үз уку контентын булдыру мөмкинлеген дә бирә. Мондый сервислар Moodle яки Google Classroom кебек танышларына көндәшлек тудыра ала. Кагыйдә буларак, дәрес конструкторлары дистанцион укыту системалары белән чагыштырганда күпкә җиңелрәк үзләштерелә. Шул ук вакытта алар иң мөһим компонентларны үз эченә ала, мәгълүмат контентын һәм тикшерү өчен биремнәрне, шул исәптән тестларны да урнаштыру мөмкинлеге бирә. Конструкторларның күбесе укучылардан теркәлүне таләп итми, махсус сылтама буенча күчү яки код кертү дә җитә. Мондый механизм шулай ук педагог өчен дә, укучы өчен дә эшне гадиләштерә.

**Core –** минем яратып куллана торган дәрес конструкторларымның берсе, бик яхшы функционал һәм бушлай. Бу укытучы өчен дә, укучылар өчен дә интуитив яктан аңлаешлы платформа. Әлеге конструктор укытучыга һәр укучы өчен белем бирүнең шәхси траекториясен төзи алуы, төрле катлаулылыктагы биремнәр әзерли алуы белән аерылып

тора. Укучылар, төрле җайланмалар аша, регистрация узмыйча гына да биремнәрне үти алалар.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә, дистанцион уку шартларында туган тел һәм әдәбият дәресләрен үткәргәндә төрле белем бирү платформаларын һәм сервисларын файдалану бик мөһим.Алар предметны өйрәнүдә кызыксыну уяту, белем алу ихтыяҗы тудыру, дәрестә генә түгел, өй шартларында да мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнергә мөмкинлек бирү, укытучыга да үз белем дәрәҗәсен арттырырга ярдәм итү кебек максатларга җавап бирүләре белән аерылып торалар.

Практик өлеш түбәндәге онлайн-тактада: https://padlet.com/gataualina/w14pybykts3zi8cu

## ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕН ДИСТАНЦИОН УКЫТУ

**Денисова Гөлүсә Рәшид кызы**
**Фәхретдинова Алёна Ришат кызы**
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «37 нче гимназия» автономияле гомуми белем муниципаль учрҗдениесе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Дистанцион белем алу (ерактан торып белем алу) бик борынгы еллардан ук барлыкка килгән. Аның тарихы 1836 елда Лондон университетытында башлана. Университетта мәктәп укучыларын имтиханга әзерләү өчен курслар ачыла. Алар университетка йөрмичә генә кыска гына вакыт эчендә ниндидер фән буенча өстәмә белем алу курслары була. Шуннан бирле ул үзенең актуальлелеген саклаган һәм бүгенге көнгә кадәр үз-үзен аклаган белем алуның бер юнәлеше.

Россиядә дистанцион укытуның рәсми датасы итеп 1997 елның 30 маен санарга мөмкин, Россия Мәгариф министрлыгының 1050 номерлы боерыгы чыкканнан соң, мәгариф өлкәсендә дистанцион укыту буенча эксперимент үткәрергә рөхсәт ителә.

Бүгенге көндә белем бирү оешмаларында дистанцион укытуны оештыру темасы актуаль булып кала, чөнки дистанцион укыту формаларын куллану, сыйныфта бала булмаганда гына түгел, шулай һәр балага индивидуаль якын килүне тормышка ашыру коралы буларак та кулланылырга мөмкин

Соңгы елларда электрон һәм аеруча дистанцион уку безнең чынбарлыгыбызга әйләнде һәм көнүзәгендәге мәсьәлә булып тора. Бу укы-

ту формаларының норматив-хокукый базасы булып «РФ ның Мәгариф турында Федераль законы» тора. (Федеральный закон от 29.12.2012 №273-ФЗ (ред. от 17.02.2023) «Об образовании в Российской Федерации» (с изм. и доп., вступ. в силу с 28.02.2023). Статья 13. Общие требования к реализации образовательных программ)

Әлеге законның 13 нче статьясының (Белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга гомуми таләпләр) икенче пунктында:

– «Белем бирү программаларын тормышка ашырганда төрле белем бирү технологияләре кулланыла, шул исәптән дистанцион белем бирү технологияләре, электрон укыту» дип әйтелә:

– 2022 елның 1 сентябрендә гамәлгә кергән яңа федераль белем бирү стандартларында электрон һәм дистанцион белем бирүне гамәлгә ашыруга үз өлешләрен керттеләр. Әгәр элек электрон һәм дистанцион белем бирүне белем бирү процессында кулланырга мөмкин булса, бүгенге көндә белем бирү процессын гамәлгә ашырганда аларны куллану мәҗбүри.

Укыту процессын оештырганда, башка предметларныкы кебек татар теле һәм әдәбияты фәне буенча әзер укыту платформалары булмау сәбәпле, мина да шактый эзләнергә туры килде. Һәм дистанцион уку өчен тәкъдим ителгән күп кенә вариантларны өйрәнгәннән соң, мин үз эшемдә куллану өчен Google Classroom сервисын уңышлы дип таптым.

Google Classroom – онлайн курслар һәм дистанцион уку өчен эффектив мәйданчык. Ул популяр Google платформасы белән интеграцияләнә һәм югары сыйфатлы укыту процессын оештыру өчен берничә файдалы гугул сервисларын үз эченә ала. Бу сервис 2014 нче елның 6 нчы маенда анонслана. Монда укытучы үзе дәрес төзи, биремнәр, тестлар, видеолар беркетә ала. Укучылар да сайтка кереп укытучы биргән эшне күрә. Эшләп җибәргәч, укытучыга шунда ук тикшергә мөмкинчелек бар.

Google Classroom сервисы дистанцион укуны оештыруны җиңеләйтә, материалларны бирүне һәм дәрескә әзерләнүне гадиләштерә.

Шулай ук Classroom сервисын телефонга да йөкләргә мөмкин. Мобиль кушымта 2015 нче елда чыгарыла. Бу кушымта укучылар өчен дә, укытучылар учен дә бик уңайлы.

Google Classroom сервисында эшне оештыру өчен, безгә Google аккаунты булдырырга кирәк. Аккаунт булдырганнан соң Google птатформасында Google Classroom сервисын табып, эшне башлап җибәрә алабыз.

Google Classroom сервисының уңайлыклары бик күп. Һәр балага аккаунт булдырырга кирәкми, бары тик һәр аерым сыйныфка курс булдырырга һәм укучыларны курска кушарга кирәк.

Укучыларның курска кушылуының ике ысулы бар:

1.Укучыларның электрон почталарына курска чакыру җибәрелә. Бу очракта укучылар чакыруны кабул итәләр һәм курска кушылалар.

2. Код белән керү. Укучылар курслар битендә «Курска кушыл» вкладкасы аша курска кушылалар.

Курс үзе дүрт биткә бүленгән:

1.ЛЕНТА/БЕЛДЕРҮЛӘР

Лентада курса булган бөтен яңалыклар яктыртыла

2.ЗАДАНИЯ/БИРЕМНӘР

Әлеге бүлектә дәрес өчен кирәкле уку материалларын, биремнәрне урнаштырам.

3.ПОЛЬЗОВАТЕЛИ/КУЛЛАНУЧЫЛАР

Сыйныфтагы укучыларымның исемлеге.

4.ОЦЕНКИ/БИЛГЕЛӘР

Укучыларның билгеләре.

Укучы курска кушылганнан соң, почта аша, лентадагы яки биремнәрдәге барлык үзгәрешләр турында хәбәр алып тора. Шулай ук, материалларны үзенә уңайлы вакытта карый, биремнәрне билгеләнгән вакытка кадәр үти һәм тапшыра.

Google Classroom сервисы мөмкинлекләрен кулланучылар укытучылар һәм укучылар күзлегеннән җентекләп карап чыгыйк.

Укытучылар:

– берничә курс белән эшли;

– класслар (курслар)булдыра;

– уртак укыту. Бер курста 20 укытучыны чакырып, берлектә эшли;

– укыту материалларын җибәрә;

– башкарылган эшләрне тикшерә һәм бәяли;

– «Оценка» битендә бәяләр кую системасын сайларга, бәяләү категориясен булдырырга һәм барлык куелган бәяләрне карарга мөмкинлеге бар.

Укучылар:

– укытучыларның биремнәрен үти;

– өй эшләрен тапшыра;

– сыйныфташлары, укучылар белән аралаша алалар.

Дистанцион укунын киләчәге бик зур. Чөнки бер кеше берюлы берничә уку йортында белем алу мөмкинлеге булачак. Һәм аның өчен шәһәрдә яшәү таләп ителми. Ләкин барлык материалны үзләштерү, укучы җилкәсенә төшә. Иң мөһиме – дистанцион укыту һәрвакытта да укучыларның белем алуга ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм үстерү эшенә хезмәт итәргә тиеш.

# ТУГАН ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ФУНКЦИОНАЛЬ БЕЛЕМНӘРНЕ ФОРМАЛАШТЫРУ

**Зарипова Алсу Рәшит кызы**
*Казан шәһәре 89 нчы мәктәп*
*Туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерү мәгариф системасында бүген актуаль проблема. Россия Президентының 2018 нче елгы 5нче маендагы указыннан күренгәнчә, укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштырып, без **максатчан** рәвештә белем бирү сыйфатын күтәрү, уку сыйфатын күтәрү өстендә эшлибез. Функциональ грамоталылыкның статусы югары, чөнки функциональ грамоталылык астында гади биремнәр юк, алар барысы да тормыш ситуациясенә уралып бара.

## Функциональ грамоталылыкны формалаштыру

Гомуми белем бирү системасында функциональ грамоталылыкны формалаштыру өстенлекле максатларның берсе булып тора. Шул исәптән, функциональ грамоталылыкны формалаштыруның төп ысулы буларак, белем бирүдә инновацион карашларны үзләштерүгә игътибар бирелә. *Функциональ грамоталылык* терминына килгәндә, совет һәм Россия лингвисты, психолог А.А.Леонтьев түбәндәге билгеләмәне бирә: «Функциональ грамоталылык – тормыш бурычларын хәл итү өчен, кешенең гомер дәвамында алган белемнәрен эшчәнлекнең төрле даирәләрендә, аралашуда һәм социаль мөнәсәбәтләрдә куллана белү сәләте ул». Белгәнебезчә, функциональ грамоталылык күпкырлы төшенчә. Ул уку грамоталылыгын, математик грамоталылыкны, табигый-фәнни грамоталылыкны, финанс грамоталылыгын, глобаль компетенцияләр, креатив фикерләүне үз эченә ала.

1. Нинди була соң ул функциональ грамоталы шәхес? Функциональ грамоталы шәхес – гомере буе алган белем, күнекмәне тормышта төрле өлкәләрдә килеп чыккан проблемаларны, мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеген киң кулланып, социаль мөнәсәбәтләр урнаштыра һәм аралаша алучы. Гади итеп әйтсәк, укучыны әйләнә-тирә үзе тәрбияли, үзе каршылыгын куя, төрле юллар тәкъдим итә, укытучы булган белемнәрен кулланып, кирәкле юлга чыга. Ә укучыга белем кирәклекне төшендерү иң авыры. Шуңа күрә укытучы иң элек теоретик белемнәрне үзләштерә, аннан аны гамәлдә уңышлы куллану ысулларын өйрәнә, сынап карый.

Теоретик белем уңышның нигезе булып тора. «Фукнционировать» сүзенә эшләү, алга бару, хәрәкәт итү, куллану дигән синонимнар кулланып була. «Грамоталылык» – кешенең туган телендә язу һәм уку кунекмәләренең дәрәҗәсе, кешенең алга таба үсешенең фундаменты, нигезе. Моннан чыгып, функциональ грамоталы шәхес – югары дәрәҗәдә мөстәкыйль, җаваплы фикер йөртүче һәм алга баручы, кирәкле мәгълүматны табып аны тормышта куллана белүче кеше дип әйтергә мөмкин. Ә укытучының төп максатларының берсе – укучыларның алган белемнәрен тормышта кулланырга өйрәтү. Укучыда түбәндәге күнекмәләр формалашкан булырга тиеш. Әйләнә-тирә мохит белән мөнәсәбәтләргә керү.

2. Гомер дәвамында алынган белемнәрен стандарт һәм стандарт булмаган сорауларны хәл итүдә куллана белү сәләте.

3. Социаль мөнәсәбәтләр булдыру сәләте.

4. Үзбәя бирү, алга таба белем алуга омтылыш булдыру.

**Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә файдалана торган алымнар**

Иҗади һәм якын килеп, балаларның кызыксынуларына, яшь үзенчәлекләренә туры китереп, тормышка бәйләп бирелгән биремнәр актуаль һәм заманча булырга тиеш. Бу укучыларны эзләнергә, кирәкле мәгълуматны эзләргә һәм аны куллана белергә өйрәтә. Шуннан чыгып мин төрле биремнәр кулланам. Проектлар, иҗади эшләр өстендә эшләгәндә укучылар сүзлекләргә, төрле интернет ресурсларга, әдәби китапларга, мультимедиа программаларга мөрәҗәгать итәләр. Укучылар үз эшләрен нәтиҗәле, югары сыйфатлы, замана таләпләренә туры китереп башкару өчен барлык чараларны кулланалар. Димәк, укучыларның алган белемнәрен тормышта кулланырга өйрәнәләр.

Уку – коммуникатив танып белү эшчәнлегенең иң мөһим төрләренең берсе, аның нигезендә фикерләү эшчәнлеге ята. Уку күнекмәләре бик мөһим, чөнки көндәлек тормышта без еш кына язу үрнәкләре белән хәл итәбез: китаплар, матбугат басмалары укыйбыз, интернет челтәрләрендә төрле мәгълүмат эзлибез. Уку кешенең культурасын үстерә, аны шәхес буларак тәрбияли. Рус төркемнәрендә эшләгәндә уку аеруча зур урын алып тора, чөнки чит тел өйрәнүдә уку төп компонент булып тора. Ул сүз байлыгын киңәйтергә, контексттан таныш булмаган сүләрне аңларга, грамматик категорияләрне ныгытырга, сөйләм күнекмәләрен камилләштерергә булыша. Текст өстендә эш вакытында укучыларда универсаль уку гамәлләре формалаша: танып белү, коммуникатив, регулятив, шәхси. Текст өстендә эшнең 3 этабы бар: укуга кадәр, уку вакыты, укудан соң.

1. Текст өстендә эшнең укуга кадәр этабы максатлары: балаларда мотивация тудырырга, тел һәм сөйләм авырлыкларын мөмкин кадәр киметергә. Бу этапта түбәндәге күнегүләр эшләргә мөмкин:

а) тактага текстның асылын ачыклый торган әйтем/ цитата/ афоризм язып, текст нәрсә турында булыр икәнен чамалау;

ә) текст исеменнән аның темасын билгеләү, күтәрелә торган проблемалар, туган ассоциацияләр турында әйтү;

б) булган иллюстрацияләргә, видео фрагментларына таянып текстның тематикасын уйлап формалаштырырга;

в) бирелгән сүзәр буенча төп идеяне, бу сүзләр нинди ассоциацияләр тудырганы турында әйтергә.

2. Текст өстендә эшнең уку вакыты этабы максатлары: укучыларның тел күнекмәләрен һәм сөйләм осталыкларын формалаштыру. Бу этапта түбәндәге күнегүләр эшләргә мөмкин:

а) тәкъдим ителгән сорауларга җавап табарга;

ә) раслауның дөреслеген яки ялган икәнен, я раслауның текстта булмаганын ачыкларга;

б) җөмләләрне тәртип буенча төзү;

в) текстка туры килә торган җөмләләрне табарга

г) һәр абзацка яраклы исем табарга;

д) текстта төшерелеп калган урынга мәгънәсе буенча туры килгән сүз яки җөмлә куярга;

е) таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен контексттан аңларга тырышырга;

ж) контекстка карап, таныш булмаган сүзнең берничә тәкъдим ителгән тәрҗемәсе арасыннан сүзне аеруча төгәл чагылдыра торган тәрҗемәсен әйтергә;

җ) өзекне укырга һәм аны сөйләргә;

з) текстны балалар санына бүлеп, аларга таратып, тиешле тәртиптә яңадан җыярга;

и) җитмәгән мәгълүматны тутырырга.

3. Текст өстендә эшнең укудан соң этабы максатлары: текст ситуациясен кулланып, укучыларның тел һәм язу күнекмәләрен, таныш белү активлыгын үстерү. Бу этапта түбәндәге күнегүләр эшләргә мөмкин:

а) укылган тексттан яңа мәгълүматны ачыклау, үз фикереңне әйтү;

ә) тәкъдим ителгән сүзтезмәләрнең кайсысы текстның төп фикерен төгәл җиткерә? Үз җавабыңны нигезләргә;

б) текстның төп фикерләрен ачыклап, планын төзергә;

в) телдән /язмача текстның кыскача эчтәлеген җиткерергә;

г) текстны төп герой исеменнән телдән /язмача сөйләргә;

д) текстка яңа исем уйлап табу.

**Йомгаклау.**

Креатив фикер йөртергә, уйларга өйрәнгән бала күбрәк иҗатка тартыла, андый баланың башына күбрәк матур фикер килә башлый. Әгәр балага бер генә китапның, бер генә әсәрнең матурлыгын, фикер тирәнлеген күрсәтә алсаң, аны мәңгегә китап укуны яратырлык, китап дөньясында йөзәрлек итеп тәрбияләргә мөмкин. Китап укыган баланың язу һәм сөйләм теле дә камил, эзлекле, тирән була.

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫГЫН ҮСТЕРҮНЕҢ МАКСАТ-БУРЫЧЛАРЫ

**Зарипова Гөлшат Искак кызы**
*Казан шәһәре Мәскәү районы 102 нче гимназия*
*Туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Бүгенге көндә күпчелек педагоглар, методистлар укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыру турында күп сөйләшәләр, мөмкин булганча укытучыларны бу проблемага гамәлдә игътибар итәргә өндиләр. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен бу проблема бик актуаль.

Функциональ грамоталылык – кешенең уку һәм язу күнекмәләрен һәм осталыкларын текстан мәгълүмат алу, ягъни текстны аңлау, кыскарту, үзгәртү һәм реаль аралашуда куллануга юнәлтелгән сәләте. Функциональ грамоталылыкны формалаштыру – катлаулы процесс, ул укытучыдан заманча формалар һәм укыту ысулларын куллануны таләп итә. Бу формаларны һәм ысулларны кулланып, без инициатива, мөстәкыйль, иҗади фикер йөртүче шәхес тәрбияли алачакбыз.

2010 нчы елдан алып, Рәсәй мәктәпләре функциональ грамоталылыкның элементлары булган метапредмет уку нәтиҗәләренә таләпләр куя торган Федераль мәгариф стандартлары нигезендә эшлиләр. Дәресләр һәм сыйныфтан тыш чаралар кысаларында функциональ грамоталылыкка ирешү өчен бик күптөрле методик техника бар. Мәсәлән, бу мәктәп дәреслекләренең эчтәлегендә кулланылган сораулар белән генә чикләнмичә, ә «Конвергент белем бирү көне», «Музейда, паркта дәрес»,

«Һөнәри сынаулар» һ.б. форматлардагы дәресләр уздыруга да кайтып кала.

5-11-нче сыйныфларда татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыру өчен кулланган кайбер техника һәм ысулларны тәкъдим итәм. Гамәлдә мин еш уку һәм язу аша тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясенә мөрәҗәгать итәм. Бу технология безнең максатлар өчен иң яхшысы дип исәплим.

Тәнкыйди фикерләү технологиясе түбәндәге бурычларны чишәргә мөмкинлек бирә: укыту мотивациясе: уку процессына кызыксыну һәм уку материалын актив кабул итү; язу культурасы: төрле жанрдагы текстларны язу күнекмәләрен формалаштыру; информацион грамоталылык: теләсә нинди катлаулы мәгълүмат белән бәйсез аналитик һәм бәяләү эше сәләтен үстерү; иҗтимагый компетенция: аралашу күнекмәләрен формалаштыру һәм белем өчен җаваплылык.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерүгә юнәлтелгән метод һәм эш төрләре бихисап, чөнки бу төр дәресләрдә без текст белән эшлибез, ә текст, безнең фикеребезчә, фукнциональ грамоталылыкны формалаштырудагы төп чара.

## ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЕННАРЫНЫҢ ЦИФРЛЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕН КУЛЛАНУ

**Хайруллина Айсылу Расим кызы**
*Казани Казан шәһәре Яңа Савин районының*
*«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган*
*71нче татар-рус урта гомуми белем мәктәбе»*
*гомуми белем бюджет муниципаль учреждениесе*
*Югары категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Хәзерге вакытта мәгариф системасында яңа белем бирү стандартлары кертелгәч, укучыларның мәгълүматны кабул итүләренә тиз адаптацияләнүенә ярдәм итүче практик-ориентлы алым зур әһәмияткә ия була. Җәмгыятьтә мәгълүматлаштыру нәтиҗәсендә мәктәпне тәмамлаучыларга карата таләпләр үзгәрә. Шуңа күрә, яңа шартларны исәпкә алып, уку процессы өзлексез белем бирү концепциясен тормышка ашыруга ярдәм итүче компетентлыкларны үстерүгә юнәлдерелгән булырга тиеш. Әмма кирәкле компетентлыкларны үстерү өчен, билгеле бер дәрәҗәдә функциональ

грамоталылык кирәк, бу заманча белем бирүнең билгеле бер шарты булып тора һәм сайланган теманың актуальлеген аңлата.

Бүгенге конференциядә мин сезгә «Туган (татар) тел һәм әдәбияты дәресләрендә белем бирү уеннарының цифрлы технологияләрен куллану» дигән темага чыгышымны тәкъдим итәм. Чыгышымның максаты: дәресләрдә укуны оештыру өчен цифрлы белем бирү ресурсларын (ЦОР) куллануның нәтиҗәлелеген күрсәтү һәм укучыларда шәхес эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә тормыш мәсьәләләрен хәл итүдә функциональ грамоталылыкның әһәмиятен ачыклау. Максаттан чыгып түбәндәге бурычларны куйдым:

- бүгенге көндә кулланышта булган цифрлы белем бирү ресурсларын барлау.
- төрле платформаларда эшләү мисалында укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыру өчен ЦОР куллану тәҗрибәсе белән уртаклашу.

Татар теле дәресләрендә укытуның яңа төр формаларын, ягъни интерактив такта һәм мультимедия проектор куллану укытуның нәтиҗәлелеген тагын да арттыра. Бүгенгесе көндә татар баласы ана телендә белем һәм тәрбия ала, үз милләттәшләре белән аралаша; алдагы буыннарның бай тәҗрибәсе, тарихы, гореф – гадәт, йолалары белән таныша; фикерләү сәләтен үстерә; сөйләм һәм язма тел культурасын баета; уку предметларының башкаларын да ана телендә үзләштерә ала. Боларның барысы да татар укучысын җәмгыятьнең төрле өлкәләрендә актив катнашучы шәхес буларак формалаштырырга ярдәм итә, аның акыл, эмоциональ һәм әхлакый үсешенә уңай йогынты ясый.

Татар теле укытучысы да замана белән атлап барырга, яңалыклар ташкыны алдында югалып калмаска тиеш. Шул нисбәттән, мин сезгә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен мөмкин кадәр заманча, кызыклы һәм сыйфатлы үткәрер өчен онлайн инструментлар җыелмасын тәкъдим итәм. Интернетта табып була күп санлы төрле веб-сервислар, аларның күбесе белем бирү процессында кулланырга мөмкин.

**LearningApps.org** сервисын кулланып төзегән дидактик биремнәр (уеннар) тәкъдим итәм. Шундыйлардан кроссворд чишү, пазллар җыю, парын табу, сүзләрне (рәсемнәрне) төркемнәргә урнаштыру, төшеп калган сүзләрне урнаштыру, викторина һәм башка уеннарны санап китәргә була. Биремнәрне әзер килеш алып кулланырга да мөмкин, ләкин сайтта укытучы үзе теркәлеп эшләсә, укытучы өчен уңайлырак булачак. Укытучы өчен шунысы уңайлы: биремнәрне тиз арада үзгәртеп, төрле темага, төрле сыйныф өчен яраклаштырырга мөмкин.

**Joyteka** – интерактив биремнәр булдыру өчен иң популяр белем бирү платформаларының берсе. Платформа безнең илнеке, Екатеринбург укытучы Максим Юрьевич Новиков тарафыннан эшләнгән. Бушлай тариф 20 интерактив бирем булдырырга мөмкинлек бирә. Ләкин кайбер квест бүлмәләренә керү чикләүләре генә бар. Интерактив биремне төзегәндә уң якта видеоинструкция барлыкка килә. Шуңа күрә аңлау бик җиңел. Күп кенә педагоглар әлеге платформаны квестлар булдыру өчен актив кулланалар. Ләкин аның башка мөмкинлекләре дә бар. Платформа төрле темаларга викториналар булдырырга мөмкинлек бирә, биремнәрнең күләме һәм эчтәлеге төрле, барысы да сезнең фантазиягезгә һәм белем бирү максатларыгызга бәйле.

**Online Test Pad** – бушлай универсаль конструктор, аның ярдәмендә төрле тестлар, кроссвордлар, сканвордлар, сораштырулар, логик уеннар, диалоглар булдырырга мөмкин, алар ярдәмендә үз укучыларыңны сынап кына калмыйча, аларга имтиханнарга, контроль зачетларга яхшырак әзерләнергә мөмкинлек бирергә мөмкин.

**Padlet.com** – тактасын куллану зур мөмкинлекләр бирә. Анда чиксез күләмдә мәгълүмат урнаштырырга, комментарийлар калдырырга мөмкин. Анда барлык кирәкле мәгълүматны туплап кулланырга мөмкин. Шулай ук проектлар төзү дә, виртуаль экскурсияләр оештыру да, онлайн газеталар чыгару да. бик уңышлы ресурс.

Укучыларның мотивациясен арттыру чарасы буларак **Quizziz** платформасы да бик кызыклы. Quizizz веб-сервисын аның функционалы Kahootны хәтерләтә, әмма аннан аермалары бар.

**Genially** сервисын традицион укытуда да, дистанцион укытуда да кулланырга мөмкин. Шулай ук сервис укучыларга ФГОС тарафыннан каралган уку проектларын булдырырга мөмкинлек бирә.

**Jigsaw Planet** кулланучылар тарафыннан төзелгән берничә миллион пазлны үз эченә ала, аларны онлайн җыярга яки теләсә нинди катлаулылыктагы үз пазлларын булдырырга мөмкин.

Мәктәптә рус телле укучыларга туган телне укытуның төп максаты – коммуникатив компетенцияне үстерү, чит телдә мәдәниятара аралашуда катнашырга теләгән һәм алга таба да мөстәкыйль камилләшүгә сәләтле бала шәхесен үстерү. Әмма максатка ирешү сыйфаты, барыннан да элек, шәхеснең ихтыяҗына, аның мотивациясенә бәйле. Шулай итеп, цифрлы белем бирү ресурсларына нигезләнеп төзелгән уеннарны куллану уңай нәтиҗә бирә, чөнки ул укучыларның эшчәнлеген активлаштырырга һәм функциональ грамоталылыкны формалаштырырга гына түгел, ә белем бирү сыйфатын күтәрергә, педагогның һөнәри

дәрәҗәсен күтәрергә, белем бирү процессында укучыларның аралашу формаларын төрләндерергә мөмкинлек бирә.

Цифрлаштыру – тормышның аерылгысыз өлеше, шуңа күрә аннан өйгә кереп качып, күрмәмешкә салышудан мәгънә бар дип уйламыйм. Әлбәттә, һәр нәрсәнең чиге булырга тиеш. Әгәр теләсә кайсы даруны күбрәк куллансаң, ул агуга әйләнергә мөмкин. Санлаштыру белән дә шул ук хәл. Безгә гаҗәеп мөмкинлекләр биргән цифрлаштыруны файдалы итеп куллана белергә кирәк

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТЕКСТ ӨСТЕНДӘ ЭШ АЛЫМНАРЫ КУЛЛАНУ АША РУС ТӨРКЕМЕНДӘ УКУЧЫ БАЛАЛАРНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫГЫН ҮСТЕРҮ

**Хисамова Рамилә Рамис кызы**
*МБГУББУ ТР*
*«Буа шәһәре лицей-интернаты»*
*I квалификацион категорияле туган*
*тел һәм әдәбияты укытучысы*

ФГОС таләпләре буенча, без бүген укучыларыбызны төрле яклап үстерергә тиеш. Шуны истә тотып, һәр дәрестә укуга карата мотивация булдыру өчен төрле метод һәм алымнар кулланырга мөмкин. *Бу максатка ирешү өчен без балаларда функциональ грамоталылык формалаштырырга тиеш.*

***Функциональ грамоталылык*** – кешенең әйләнә-тирә мохит белән мөнәсәбәтләргә керүе, гомер дәвамында алынган белемнәрен куллана белү сәләте.

***Уку грамоталылыгы*** – функциональ грамоталылыкның иң мөһим өлеше. Ул – укучыда текстларны аңлау, куллану, бәяләү, алар турында уйлану сәләте үстерә.

Уку – коммуникатив танып белү эшчәнлегенең иң мөһим төрләренең берсе, аның нигезендә фикерләү эшчәнлеге ята. Уку күнекмәләре бик мөһим, чөнки көндәлек тормышта без еш кына язу үрнәкләре белән эш итәбез. Уку кешенең культурасын үстерә, аны шәхес буларак тәрбияли.

Рус төркемнәрендә эшләгәндә уку аеруча зур урын алып тора, чөнки чит тел өйрәнүдә уку төп компонент булып тора.

**Уку –** сүз байлыгын киңәйтергә, контексттан таныш булмаган сүзләрне аңларга, грамматик категорияләрне ныгытырга, сөйләм күнекмәләрен камилләштерергә булыша.

«Балтач районы Сосна авылы ономастикасы», «Әхмәт Мазһаров – районыбызның беренче академигы», «Рәшит Мостафин – күңелләргә моң өләшүче асыл зат», «Гөлзадә Сафиуллина – М.Җәлил исемендәге дәүләт бүләге иясе» дигән темаларга фәнни-эзләнү эшләре алып бардылар һәм республика күләмендә үткәрелгән конференцияләрдә чыгыш ясап, призлы урыннар яуладылар.

Дәрестән тыш чараларны дөрес оештырганда, укучы шәхес буларак формалаша, укыту процессына, объектына, шартларына, нәтиҗәләренә

мөнәсәбәтен күрсәтә. Ул үз эшчәнлеген оештыруга сәләтле була. Дәрестә дә, дәрестән тыш эшчәнлектә дә укучы шәхесен күз алдында тотып эшләгәндә, уңышка ирешергә мөмкин.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: дәрестән тыш эшчәнлектә һәм өстәмә белем түгәрәкләрендә актив катнашкан укучының аңлы рәвештә укуга теләге арта, ул фән белән ныграк кызыксына башлый, үз эшенә җаваплы карый, аның танып белү эшчәнлеге камилләшә, ул үзендә ышаныч тоя, эшкә омтылышы көчәя.

## КЛАССТАН ТЫШ ЧАРАЛАР УЗДЫРУ – АНА ТЕЛЕБЕЗГӘ ӨЙРӘТҮНЕҢ УҢЫШЛЫ АЛЫМНАРЫННАН БЕРСЕ («ХЫЯЛ» ТЕАТР ТҮГӘРӘГЕ ТӘҖРИБӘСЕННӘН)

**Галиева Зөлфия Мансуровна**
*Казан шәһәре, Киров районы*
*57 нче рус-татар урта мәктәбе*
*Туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Татар халкы элек – электән белемле, мәдәниятле булган. Без дә, татар теле укытучылары, халкыбыз мирасын, телебезне, тарихыбызны, мәдәниятебезне саклаучылык, үстерерлек шәхесләр тәрбияләү өчен тырышабыз.

Казан шәһәренең 57 нче рус-татар урта мәктәбендә дә рус мохитендә тәрбияләнүче татар һәм башка милләт балаларына туган телгә мәхәббәтне, дәресләрдә генә ирешеп булмый, әлбәттә. Класстан тыш чараларның мөмкин булган барлык төрләрен дә кулланып эшлибез.

Класстан тыш чаралар уздыру – ана телебезгә өйрәтүнең уңышлы алымнарыннан берсе дип саныйм. Шул нисбәттән мәктәбебездә «Хыял» балалар театр түгәрәге оештырып җибәрдем. (Мәдәният институтының театр бүлеген тәмамладым). Түгәрәктә мин укучыларга туган телнең байлыгын, матурлыгын, сүзләрнең төрле яңгырашын аңлатам, бигрәк тә сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру, сөйләм осталыгын үстерүгә әһәмият бирәм. Балаларга театр сәнгатен өйрәтеп, милли мәдәнияткә мәхәббәт тәрбияләргә телим.

Татар халык иҗаты әсәрләрен тирәнтен өйрәтү, язучыларыбызның әсәрләре белән таныштыру, сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру, сөйләм осталыгын үстерү белән бергә туган телебезне ярату, аның гүзәллегенә төшенү, милли горурлык хисләре тәрбияләү минем төп максатым булып тора.

**Максатка ирешү өчен бурычлар билгеләнде:**

1. Укучыларны чыгыш ясау һәм аралашу осталыгына өйрәтү.
2. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү (дикция, сулыш белән идарә итү, сөйләм тавышы кую, орфоэпия өстендә эшләү).
3. Укучыга үзенең сөйләм осталыгын, талантын сынап карарга шартлар тудыру.
4. Татар милли театр сәнгате белән кызыксынуны үстерү.
5. Театр әсәрләренә таянып күркәм әхлакый сыйфатлар тәрбияләү

Бу максатларны тормышка ашыруда сүз сәнгатенең, әдәбиятның матур үрнәкләренә мөрәҗәгать итәбез. Сәнгать әсәрләренең мәгънәсенә төшенү укучылыр өчен аерым сүздән башлана. Авазларны ишетмичә көйне аңлап булмаган кебек, сүзне тоемлау сәнгатеннән мәхрүм бала әсәрнең кыйммәтен танып белмәячәк. Шуны истә тотып, иң беренче балаларда сүзләрнең дөрес әйтелешенә ирешүләренә игьтибар бирәм. Театр түгәрәгендә дәресләр төрле формада үткәрелә. Күбрәк теоретик һәм практик күнегүләр белән ныгытып алып барабыз.

Түгәрәктә татар балалары белән бергә рус телле укучылар да бик теләп йөри. Сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру, сәнгатьлелек дәрәҗәсен камилләштерү өчен, беренчедән, сулыш, тавыш, дикция өстендә эш алып барырга кирәк.

Дикция ул – авазларны, иҗекләрне, сүзләрне дөрес, ачык, аңлаешлы әйтү. Ләкин эш барышында төрле кимчелекләр белән очрашасың.

1. Сөйләү аппаратындагы табигый кимчелекләр.
2. Диалекталь кимчелекләр.

Сөйләм теле техникасы артикуляцион күнегүләрдән, сузык һәм тартык авазны берәм-берәм эшкәртүдән, авазларның дөрес яңгырашын өйрәнүдән башлана. Мәсәлән, ГА-ГО-ГУ-ГЫ. ГӘ-ГӨ-ГҮ-ГЕ-ГИ. (Укучылар кайсы авазны авыр үзләштерә, шул авазларны алырга тырышасың)

Шундый әйтем һәм табышмаклар белән сузык һәм тартык авазларның дөрес яңгырашына ирешкәннән соң авызны ачык, анык итеп әйтү күнекмәләре үткәрелә. Аның өчен тизәйткечләрдән файдаланабыз. Тизәйткечләрнең эчтәлеген югалтмыйча, мәгънәле итеп, акрын гына, ашыкмыйча гына сөйләтә башлап, сүзләрнең дөрес яңгырашына ирешкәч, кызулата барабыз.

Узара сөйләшкәндә, тексларны укыганда «логик» һәм «психологик» паузалар була. Бу паузаларның төп функциясе – текстагы мәгънәне дөрес җиткерү. Укучылар бу терминнарны белә, аңлый, тоя, чөнки аерым дәресләрдә сүзнең мәгънәсен, тәмен аңлап, фикерне табып укырга өйрәнәбез. Моның нәтиҗәләре дә бар. Районыбызда үтә торган смотр-

конкурсларда призлы урыннарны алып мине шатландыралар. Ел саен «Сәйяр» театр фестивалендә, «Яшәсен театр» исемендәге шәһәр театр бәйгесендә, Туфан Миңнуллин исемендәге республика конференциясендә катнашабыз.

Репертуар сайлаганда укучыларның мөмкинлекләрен искә алып, халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын, җырлы-биюле уеннарын, тапкырлыгын, җор теллелеген чагылдыра торган өзекләрне сайларга тырышам. Әнә шулай сайлый торгач репертуарыбыз да баеды. «Өч кыз», «Башак», «Шалкан» әкиятләре, А.Алишның «Коерыклар», «Куян кызы», «Чукмар белән Тукмар», «Сертотмас үрдәк» әкиятләре, «Сак-сок», «Өч кыз», «Башак», «Шалкан» әкиятләре, Эльмира Шәрифуллинаның «Дустың булмаса – эзлә», Т.Миңнуллинның «Иптәш командир», Нүрия Сәйяр «Хикмәтле кыңгырау», Ф.Хөснинең «Солдат улы» әсәрләрен сәхнәләштереп күрсәттек.

Түгәрәккә йөрүче балалар үзләре башкарган образлар аша иптәшләренә туган телнең хозурлыгын, асылын төшенергә ярдәм итә. Еш чыгыш ясаган саен балаларның осталыклары да арта, талантлары да ачыла бара. Шуңа дәртләнеп, канатланып эшлибез.

Балалар өчен язылган әсәрләрне сәхнәләштерү, образларны ижат итү серләренә төшендерү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен формалаштыру, укучыларнын ижади сәләтләрен үстерә, театр сәнгатенә мәхәббәт уята.

Театр сәнгате әсәрләрендә халыкның рухи тәҗрибәсе, гореф-гадәтләре, әхлак нормалары. Менә шундый гадәтләрне өйрәнү, белү, күңел белән кабул итү укучы балаларда гуманлы мөнәсәбәтләр тәҗрибәсен тудыра, яңа гадәтләрнең, яңа әхлак нормаларының асылын аңларга, аларны чагыштырып, үлчәп карарга мөмкинлек бирә дип уйлыйм. Үзара бергәләп кичерелгән шатлыклар, бергәләп кичерелгән борчулар, бергәләп табылган уңышлар коллективны рухи яктан берләштерә, үзара ярдәм итешү, бер-берең өчен борчылу, бер-берең турында кайгырту кебек хисләр тәрбияли.

Татар халкының бай иҗатын өйрәнгән, әби-бабаларыбызның йола һәм бәйрәмнәрен белгән, татар театр сәнгатен аңлаган балаларның күңеле начарлыкта булмас, минем башкарган эшләрем нәтиҗәсез калмас.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: театр түгәрәге, класстан тыш чаралар татар сөйләменә өйрәнү өчен укучыларга коммуникатив мотивация, уңайлы шартлар булдыра.

# СОЗДАНИЕ И РАЗВИТИЕ ИНТЕРАКТИВНЫХ МУЗЕЕВ В РЕГИОНАХ РОССИИ (МУЗЕЙ СОВЕТСКОЙ ПИОНЕРИИ)

**Закиров Айдар Минлекашипович**
*МАОУ «Лицей-интернат №7» г.Казани*
*Учитель родного языка и литературы*

Проектно-исследовательская работа является анализом актуальности и востребованности развития пионерских ценностей в современном обществе.

**Цель работы:** Представление варианта популяризации пионерии в современном обществе.

**Задачи:**

- Изучить литературу по данной теме.
- Изучить историю пионеров.
- Способствовать воспитанию патриотизма в заинтересованных личностях.
- Пополнение знаний учащихся по истории СССР.
- Создать макет музея на базе школьной библиотеки и провести пилотный запуск среди добровольцев из учеников нашей школы.

**Актуальность темы.**

Актуальность данной работы обусловлена тем, что в современном обществе культурный отдых становится все менее популярен. Мы хотим это исправить, создав интерактивный музей, где при помощи цифровых технологий, а также стандартных средств передачи информации (речь, текст на бумаге) можно будет погрузиться в атмосферу тех самых пионерских будней.

Что после нас останется потомкам? Нашим близким, детям, внукам? Что они почувствуют, вспоминая нас? Мы, вспоминая наших прадедушек и прабабушек, гордимся ими. Гордимся их победой в Великой Отечественной войне. Они сражались не ради своей выгоды, а ради свободы государства, ради будущих поколений.

Мы живем в процветающей стране! Большинство градообразующих предприятий были открыты еще в СССР.

Люди того времени оставили потомкам сильное государство, так что же можем оставить мы? Мы можем оставить память об этих людях, об их заслугах.

Немаловажной частью общества того времени была пионерия. Пионеры всегда помогали всем вокруг. Самое интересное, что нам самим

нравится помогать друг другу. Нравится, когда мы можем чувствовать гордость, помогая старшим поколениям.

Но в наше время реальность постепенно отходит на второй план, люди перестают видеть то, что у них прямо перед носом. Все зависли в цифровом мире и забывают и о настоящем, и о прошлом своих государств.

Но мы можем это исправить, популяризируя ценности старого общества; общества, что росло без мыслей о недосягаемом выдуманном мире; общества, что заботилось друг о друге; общества, которому не было плевать на прошлое и на будущее. Одна из ценностей людей того времени – патриотизм, любовь к родине, знание родной истории. А где же можно получше узнать историю родного государства? В музее!

В нашем музее будет представлено множество интерактивных стендов. Всего музей будет разделен на 4 блока. В первом блоке посетители смогут узнать об истории появления пионеров, о понятии слова пионер, о целях пионерской организации, об их уставах и принципах приема. Во втором разделе посетители поближе познакомятся с атрибутикой пионеров, их формой, и гимном организации. В третьем блоке будет представлен фрагмент из Великой Отечественной войны. В нем говорится о подвигах и отважных поступках детей-пионеров. В заключительном блоке посетители узнают о героях пионерах.

## МИЛЛИ МӘКТӘПТӘ ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЧАРАЛАРНЫҢ УКУЧЫЛАРГА ҺӘМ АТА-АНАЛАРГА БУЛГАН ӘҺӘМИЯТЕ

**Субханова Гүзәл Илдар кызы,**
*Бөгелмә муниципаль районының*
*Һади Атласи исемендәге*
*14нче татар гимназиясе*
*Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары*

Дәрестән тыш эшчәнлек – федераль дәүләт белем бирү стандартының мөһим бер өлеше. Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру ул – тәрбия һәм социальләшүгә юнәлдерелгән барлык эшчәнлек (укыту эшчәнлегеннән кала) төрләре. Дәрестән тыш эшләр гомумдидактик принципларга нигезләнеп оештырыла: максатчанлык, фәннилек, системалылык, эзлеклелек, укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләре, балаларның мөстәкыйльлелеге һәм иҗади активлыгы, тормыш белән

бәйләлек саклана. Дәрестән тыш эшләрнең тематикасы, юнәлешләре, төрләре бик күп. Юнәлешләре:

рухи-әхлакый юнәлеш;

спорт-сәламәтләндерү юнәлеше;

эстетик-сәнгать юнәлеше;

социаль юнәлеш;

гомуминтеллектуаль.

Төрләре: экскурсияләр, түгәрәкләр, секцияләр, түгәрәк өстәлләр, конференцияләр, диспутлар, мәктәпнең фәнни оешмалары, олимпиадалар, бәйгеләр, фәнни-эзләнү эшләре һ.б.

Мәктәптә дәрестән тыш эшчәнлекнең төп **максатлары** булып:

1) укучыларның мөстәкыйльлеген һәм инициативасын күрсәтү өчен шартлар тудыру;

2) продуктив вакыт үткәрү омтылышын тәрбияләү;

3) аралашу культурасын формалаштыру;

4) тәҗрибә, белем, күнекмәләр һәм күнекмәләр тапшыру.

Дәрестән тыш эшчәнлек **бурычлары:**

- укучыларның төрле эшчәнлек төрләренә омтылышларын һәм сәләтләрен ачыклау;
- максатларга ирешү өчен ихтыяр көче һәм сабырлык тәрбияләү;
- укучыларның дәрестән тыш вакытын кызыклы, файдалы итеп үткәрүгә ирешү;
- тәрбия үсешен системалы итеп алып бару;
- белем, күнекмәләр һәм күнекмәләр системасын формалаштыру;
- үзләштерелгән күнекмәләрне һәм күнекмәләрне күрсәтүгә ярдәм итүче уңай шартлар тудыру.

Буш вакытны бүлү **проблемасы** безнең җәмгыять өчен һәрвакыт актуаль булып тора, чөнки шәхеснең иң нәтиҗәле тәрбиясе укудан буш вакытта була. Шуңа күрә мәктәптә дәрестән тыш эшчәнлек мәктәп укучыларында эчке дисциплина, үз-үзеңне аңлау һәм дөрес әхлакый сайлау сәләтен үстерүгә юнәлдерелгән. Укучыларның уку-тәрбия эшчәнлегенең әлеге һәм башка шәхси нәтиҗәләрен бәяләү шәхессез мониторинг тикшеренүләре барышында башкарыла, аларның нәтиҗәләре буенча идарә карарлары гамәлгә ашырыла, алар белем бирү учреждениесен үстерү программаларын һәм белем бирү процессына ярдәм итү программаларын проектлау вакытында идарә карарларын кабул иткәндә исәпкә алына.

Мәктәптә дәрестән тыш эшчәнлек алып бару нәтиҗәсендә балалар санын арттыру, укучыларның социаль мәдәниятен, ватанпәрвәрлек һәм

гражданлык хисләрен формалаштыру, сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш, толерантлык, әйләнә-тирә дөньяга ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү күздә тотыла.

Мәктәптә дәрестән тыш эшчәнлек төзүдә куелган максатларга уңышлы ирешү өчен түбәндәге **принципларны** үтәү кирәк:

1) Иҗат принцибы. Педагог укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүгә ярдәм итәргә, коллектив һәм шәхси иҗат белән шөгыльләнү теләгеп сакларга тиеш.

2) Социаль әһәмиятлелек һәм уңыш принцибы. Укытучының тырышлыгы балаларда уңышларга ирешү ихтыяҗларын формалаштыруга юнәлдерелгән. Баланың казанышлары аерым әһәмияткә генә ия түгел, ә тирә-юньдәгеләр өчен дә кыйммәтле булуы мөһим.

3) Гуманистик юнәлеш принцибы. Балаларның кызыксынуларына һәм ихтыяҗларына максималь буйсыну һәм туры килү. Баланың шәхесен күрсәтү, үз-үзен тормышка ашыру һәм үз-үзен раслау өчен шартлар формалаштыру.

4) Вариативлык принцибы. Сыйныфтан тыш эшчәнлекнең киң спектры һәм төрләре, ирекле сайлау һәм анда ирекле катнашу мөмкинлеге.

5) Системалылык принцибы. Укучының дәрестән тыш эшчәнлек системасының эшләве.

Дәрестән тыш эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген өйрәнү өчен, тәкъдим ителгән күрсәткечләргә туры китереп, әңгәмә, тест үткәрү, ярыш характерындагы чараларда катнашу нәтиҗәләрен анализлау (ярыш, конкурс, олимпиада һ.б.), белгечләр-экспертларның бәяләве, баланың «Казанышлар портфеле»нең эчтәлеген анализлау, тәмамланмаган тәкъдим итү ысулы (тәмамланмаган тезис) һ. б. ысулларны кулланырга мөмкин.

Бөгелмә шәһәрендә булган бердәнбер милли мәктәп – Һади Атласи исемендәге 14 нче татар гимназиясендә дәрестән тыш чараларга аеруча зур әһәмият бирелә. Гимназиядә дәрестән өстәмә белем бирү һәм дәрестән тыш чараларның барлык төрләре буенча да тирән эш алып барыла. Өстәмә белем бирүгә килгәндә, түбәндәге түгәрәкләр күп еллар эшләп килә һәм нәтиҗәләр бирә: – «Балачак иле» – бию түгәрәге;

– «Күңелле шашкалар» – социаль юнәлеш;

– «Эшлекле инглиз теле» – метапредмет һәм шәхси үсеш;

– «Ватанпәрвәр» – ватанпәрвәрлек тәрбияләү түгәрәге;

– «Гөрләвек»– җыр студиясе;

– «Музей эшчәнлеге» – гимназия музейлары эшчәнлеге;

– «Театр» – инглиз телендә театр түгәрәге;

– «Циркуль» – проект төзү һәм конструктор эшчәнлеге һ.б.
Өстәмә белем бирү түгәрәкләре – 12, дәрестән тыш эшчәнлек төрләре – 22. Гимназиядә уку-укыту, тәрбия бирү эшчәнлеге югары дәрәҗәдә алып барыла. Нәтиҗәләре булып имтиханнарда укучылар җыйган югары баллар, төрле конференция, бәйгеләрдә алган югары урыннар тора.

## БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ АЕРЫЛГЫСЫЗ ӨЛЕШЕ БУЛАРАК, ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ҺӘМ ӨСТӘМӘ БЕЛЕМ

**Фадеева Нина Валентин кызы**
*ТР Питрәч муниципаль районы*
*Керәшен Сәрдәсе төп гомуми*
*белем бирү мәктәбе*
*Югары квалификация категорияле*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Хәерле көн! Мин 37 ел хезмәт стажлы авыл укытучысы. 37 ел мөгаллимлек итү вакытында нәрсәләр генә күрмәдек... 1990 нчы еллар... Үз Республикабыз, Конституциябез, телләр турында Закон кабул ителгән чорлар. 2000 нче елларда урта мәктәп программасына туры китереп, томлап матур әдәбият әсәрләре басылды. 2017 нче елга кадәр җиң сызганып, рәхәтләнеп татар теле, әдәбият дәресләре укыттык, түгәрәкләр оештырдык, бәйгеләрдә катнаштык. Театр төркемнәре эшләде, язучы-әдипләрнең юбилейларын, очрашулар үткәрдек. Укучыларыбыз бик теләп роман, повесть, драма әсәрләре укыды, иҗат итте, ятлады. Сөйләм, язма тел камилләште. Шушы ара – иң бәхетле, теләп, уңышшлар белән эшләгән алтын чорыбыз дияр идем мин бүген.

2017 нче елда без, татар теле, әдәбият фәнен укытучылар, кинәт билгесезлектә калгандай булдык... Башка суктылармыни?! Укытуда сәгать саны кимеде «татар теле» – «туган тел» «әдәбият» – «туган телдә уку» фәненә әйләнде. «Татар теле нигә кирәк соң ул?» дигән сүзләрне җитәкчеләр, мәктәптәге башка фән укытучылары, ата-аналар күтәреп алды. Бер карасаң, шулай уйларга җирлек тә бар иде.

2007 нче елда укучым Республикакүләм «Каурый-каләм» бәйгесендә проза номинациясендә 1 нче урын алды. Аннары 4 ел рәттән районда татар теле, әдәбият фәннәреннән олимпиадаларда җиңеп, республикага чыктык. 2011 нче елда республикада әдәбияттан 4 нче урын яулады бала. Күп яздык, конкурсларда җиңде бала. 4 ел татар журналистикасына укырга барам дип яшәде. 2011 нче елда мәктәпне тәмамлаганда татар

теленнән, әдәбияттан имтиханга (ГИА) яңа елга кадәр әзерләндек. Аннары, вузга керер өчен, рус теленнән, рус әдәбиятыннан имтихан бирү кирәклеге әйтелде. Укучыма да, миңа да шок булды. Өстәмә күп эшләнде, имтиханнар уңышлы бирелде. Ләкин хокуксызлыктан үкенеч калды.

Менә инде берничә ел эчендә шундый аяныч хәлдә калдык. Балалар авыл мәктәбендә дә хәтта телләрен ватып русча сөйләшә. Йортта да шулай сөйләшәләр. Татарча дөрес сөйләшү, дөресс җөмлә төзу юк дәрәҗәсендә. Бәхәсләшмим, зыялы гаиләләрдә матур итеп, саф ана телендә тәрбия алып баручылар да бар. Бүгенге мәктәп укучысы татарча күп сүзнең мәгънәсен белми. Кайберләре, чит телне өйрәнгән кебек, татар телен укый.

Әмма без телчеләрнең бурычы – ана телен, сөйләмебезне саклап калу. Минем үземә бу юнәлештә җырлый белүем, 37 ел авыл җирлегебездә эшләп килгән «Чулпы» керәшен халык ансамбле солисты булуым, үземнең шигырь язу сәләтем, сәхнәләрдән нәфис сүз сөйләвем ярдәмгә килде. Түләүсез дип тормадым, укучыларымны кызыксындыра алдым, дәрестән тыш күп эшләдем. Кичәләр үткәрдек, әсәрләрне сәхнәләштердек, иҗат белән шөгыльләндек.

2016 нчы елда мәктәп укучылары, укытучылары өчен «Без бергә» бәйгесен оештырып җибәрде Татарстан. Төрле номинация бар иде. Мин фольклор, халык җыры дигәнендә тукталдым. Мәктәптә 8 малай һәм кызны сайлап алып, «Яңгыравык тамчы» төркемен төзедем. Акопелло керәшен җырларын җырларга, бию хәрәкәтләренә өйрәтә башладым балаларны. Шушы елга кадәр җиңү яулыйбыз районда. Республикада да матур уңышлар шактый.

Әгәр укытучы үзе әйдәп бара белмәсә, үзе үрнәк булмаса, сәләте өстендә эшләп, балалар арасында дәрәҗәсен үстермәсә, үз үрнәгендә эш күрсәтмәсә, балалар бервакытта да укытучыга тартылмый. Без әбибабайларыбызның киемнәрен сандыклардан алып кидек. Шулар белән, горурланып, чыгыш ясыйбыз.

Шул ук 2016 нчы елда, күңелем үсеп китеп, үз көчемә ышанган хәлдә, «Көмеш тәңкә» гаиләм ансамблен дә оештырып җибәрдем. Ансамбль шунысы белән игътибарны җәлеп итә: анда өч буын вәкиле эшли – әни, кыз, оныклар.

Төркемнәребез белән авыл, мәктәп, район, республика, халыкара, рәсәйкүләм шактый чара-бәйгеләрдә нәтиҗәле генә катнашып киләбез.

Керәшен халкының йолалары безнең авыл җирлегендә нык сакланган.

Хәзер инде акрын-акрын үз көчебез белән киемнәребезне дә аруландырырга тырышабыз.

Минем тыңлаучыларга җиткерәсе килгән яңалыгым: без телне төрле юллар белән сакларга, баетырга, килер буынга тапшырырга бурычлы. Әти-әни эштә, балалары белән күбесе эшләми. Милли йолаларга тарту – балаларның матур тәрбиясен саклый. Класстан тыш эшләрдә укучылар хөрмәткә, әдәпкә, бердәмлеккә, ярдәмләшергә, ватанны яратырга өйрәнә. Үткәне белән бүгенгесен тоташтыручы чылбырга әйләнә. Алай гына да түгел, бала үз-үзенә ышанырга, сәхнәдә чыгыш ясарга, аралашырга өйрәнә. Дуслар таба. Тере аралаша.

Бүгенге компьютор заманында, балаларны телефоннардан, ялгызлыктан бары дөрес оештырылган дәрестән тыш чаралар йолып кала ала.

Минем дәрестән тыш яратып оештыра торган бер чарамның темасы; «Әдәбият һәм музыка сәнгате». Әдәбиятта төрле яшьтәге кешегә никадәр көйгә салынган шигырь! Балалар аны белми дә!

«Балаларда укуга ничек кызыкыну уятырга?» – дигән сорау алдында калган коллегага киңәшем: эшне, балаларны яратып эшләргә. Әйтергә кирәк, мәктәпне бетереп киткәндә, кайбер балалар арасында; «Безнең татар әдәбияты нинди бай, татур, телебез нинди камил!» – диючеләр дә бар.

Ә җыр борынгы. Бүген без халкыбызның матур гореф-гадәтләренә, фольклор әсәрләренә тукталып үттек. Без үзебенең милләтебезне онытмыйча, милли йолаларны дәвам итәргә, фольклор әсәрләрен сөйләмебездә ешрак кулланырга тиешбез. Халык иҗатын өйрәнү – безнең зиһенебезне баета, дөньяга карашыбызны киңәйтә, тел байлыгыбызны, белемебезне үстерә, тарихыбызны аңларга ярдәм итә.

Керәшен җырының тамырлары тирән, җырлаганда ул күкләргә менгәндәй тоела. Халык җыруының җаны зур, аның эче тулы байлык, гайрәт.

Без балаларыбызга белем биреп ккнә калмаска, бәлки, тарихын, үткәнен һәм бүгенгесен аек белгән, милләтен саклаган, ана телен югалтмаган, йолаларын белгән кеше тәрбияләргә тиешбез. Әлбәттә, дәрестән тыш һәм өстәмә эшчәнлек аша.

# ТАТАР ГИМНАЗИЯСЕ ШАРТЛАРЫНДА БАЛАНЫҢ СӘЛӘТЕН ҮСТЕРҮДӘ ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛҺӘМ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕ ҺӘМ ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ БЕРДӘМЛЕГЕ

**Хәсәнҗанова Мәдинә Хәйдәр кызы**
*Казан шәһәренең*
*«Татар телендә белем бирүче*
*155нче гимназия» ГБМБУ*
*Туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Балаларны укыту һәм тәрбияләүнең бердәм системасын булдыру, һәр укучының сәләтен үстерергә мөмкинлекләр бирә торган гамәли чаралар әзерләү, профильле укыту һәм сүз сәнгате ярдәмендә укучыларда әхлакый инану, рухи культура, эстетик зәвык тәрбияләү, аларның хис дөньяларын уяту һәм тәрбияләү, телдән һәм язмача сөйләмнәрен үстерү туган(татар)тел һәм әдәбият дәресләренең һәм шулай ук дәрестән тыш эшчәнлекнең зур максаты булып тора.

Дәрестән тыш эшләр гомумдидактик принципларга нигезләнеп оештырыла: максатчанлык, фәннилек, системалылык, укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләре, балаларның мөстәкыйльлелеге һәм иҗади активлыгы, тормыш белән бәйлелек саклана. Дәрестән тыш эшләрнең тематикасы, юнәлешләре, төрләре бик күп.

Юнәлешләре: рухи-әхлакый юнәлеш; спорт – сәламәтләндерү юнәлеше; эстетик – сәнгать юнәлеше; социаль юнәлеш; гомуминтеллектуаль.

Төрләре: экскурсияләр, түгәрәкләр, секцияләр, түгәрәк өстәлләр, конференцияләр, диспутлар, мәктәпнең фәнни оешмалары, олимпиадалар, бәйгеләр, фәнни-эзләнү эшләре һ.б.

Гимназиядә туган (татар)телдән дәрестән тыш эшчәнлек рухи – әхлакый юнәлеш буенча оештырыла. Туган (татар)тел укытучысының эше башка укытучылардан шактый аерыла. Ул хәтта дәрестән тыш эшне дә бик мавыктыргыч итәргә мәҗбүр. Милли рух тәрбияләү айлар, еллар дәвамында дәрестә генә түгел, ә дәрестән тыш чаралар да да, өйдә дә дәвам итә торган өзлексез процесс булганда гына моңа ирешеп була.

Берничә ел дәвамында без туплаган тәҗрибә шуны күрсәтә: урта һәм югары классларда әдәбияттан һәм туган (татар) телдән иҗади һәм эзләнү – тикшеренү төрендәге эшләр берничә дәрестә яки 2 – 3 айга исәпләнгән проектлар көтелгән нәтиҗәне бирә. Без укучылар белән әдәбияттан ае-

рым язучылар, шагыйрьләрнең әсәрләрен анализлап, әдәби әсәрләрне тикшерү юнәлешендә эзләнү –тикшеренү эшләре башкарабыз.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: дәрестә башланып, дәрестән соң дәвам иттерелгән фәнни эш белән шөгыльләнү укучыны күп нәрсәгә өйрәтә: уйлау мөмкинлекләре киң ачыла, логик фикерләү дәрәҗәсе үсә, теманы киңрәк планда өйрәнә,төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эшләргә, төрле чыгышлар ясарга өйрәтә.

## КАМИЛ ШӘХЕС ТӘРБИЯЛӘҮДӘ СЫЙНЫФТАН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК

**Шакирова Раушания Галәутдин кызы**
*Казан шәһәренең*
*«Татар телендә белем бирүче*
*155нче гимназия» ГБМБУ*
*Туган тел һәм әдәбият укытучысы*

Тәрбия процессының асылы-укучы белән берлектә кешелеклелек кыйммәтләрен, тормыш законнарын һәм нормаларын өйрәнү, аларны аралашуда тикшерү, баланың кызыксынуын, максатларын, мөмкинлекләрен аның белән берлектә билгеләү.

Шәхесне шәхес булганнар гына тәрбияли ала, шуна да яшь буын сыйныф житәкчеләрендә иң күркәм сыйфатларны куреп үсәргә, югары әхлакый һәм рухи принциплар тарафдары булуына ышанырга тиеш. Мин бу ышанычны акларга тырышам. Тәрбия эшемнең төп өлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. «Сәламәтлек» (әңгәмәләр, викториналар, спартакиадалар, походлар, спортсменнар белән очрашулар).
2. «Интеллект» (предмет олимпиадалары, предмет атналыклары, интеллектуаль викториналар, үз кызыксынуларынны яклау).
3. «Хәтер» (ветераннар белән очрашулар, тарихи урыннарга экскурсия, иншалар конкурсы).
4. «Мин һәм минем Ватаным» (туган як тарихын өйрәнү, атаклы кешеләре белән очрашулар)
5. «Сәнгать дөньясында» (концерт, спектакльләргә бару, сәнгать осталары турында сыйныф сәгатьләре )

Тәрбия эшендә беренче ярдәмчем булып татар халкынын җәүһәрләре тора. Ярдәмчеләрем дип мәгърифәтчеләребез К.Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдинне саныйм. Милли йолаларыбыз, гореф-гадәтләребез балалар-

ны инсафлы, тәрбияле, мәрхәмәтле итеп тәрбияләргә ярдәм итә. Үземнең укучыларымны әхлаклы, тәрбияле, миһербанлы дип атый алам мин. Һәм олы тормыш юлында алар уз максатларына ирешәчәкләренә ышанасым килә. Хәзерге көндә аларның ярдәмчел, кешелекле, хезмәт сөючән булуында мин үземнең зур хезмәтемне күрәм.

Укучы шәхесе үзенчәлекле, күпкырлы. Яшь буынны укыту һәм тәрбияләү алымнары һәм юллары күп төрле. Ләкин укытучынын да, тәрбияченен дә, әти-әниләрнең дә максаты бер: бала белемле, тәрбияле, сәламәт булырга тиеш.

Җәмгыятькә талантлы, ижади фикерли, аралаша белуче, инициативалы гражданнар сорала. Укып алган диплом гына тормышта үз урынынны табуга гарантия була алмый. Мәктәп бусагасын атлап чыгучы жаваплылык хисе, дисциплина, белем күтәрүгә омтылыш, эзләнүчәнлек кебек сыйфатларга ия булырга тиешлеген бөтенебез беләь. Мәктәпләрдә шундый шәхесләр тәрбияләүгә укучы шәхесенә юнәлдерелгән яна педагогик технологияләр куллану ярдәм итәр иде.

Әдәбият – кеше, анын рухи дөньясы турындагы фән. Әдәби әсәр ул – характерлар, язмышлар, мөнәсәбәтләр кыйссасы. Ижади фикерли белу – теләсә нинди җәмгыятьтә иң кыйммәт бәяләнүче сыйфат, иң универсаль эшчәнлек алымы. Ижадилык – үз шәхесеңне, фикерләвеңне, аң һәм интеллектыңны даими камилләштерү. Иҗади эшчәнлектә кеше үсә, махсус тәжрибә туплый, үзенең табигый сәләтен һәм мөмкинчелеген ача. Дәресләрдә һәм класстан тыш чараларда укучыларның сөйләмен һәм иҗади сәләтен үстерүгә зур әһәмият бирергә кирәклеген аңлап эш итәм.

# Ценности современной начальной школы

## ОТ СКАЗКИ – К БЕСЕДЕ ОБ ЭКОЛОГИИ

**Волкова Радмила Шлёмовна**
*МБОУ «Школа №43»*
*Ново-Савиновского района г. Казани*
*Заведующая библиотекой*

Живой мир нашей планеты весьма необычен и разнообразен. Природа создала столько видов растений и животных, что не хватит всей жизни, чтобы изучить хотя бы малую часть этих удивительных созданий даже взрослому человеку.

Как же помочь школьникам познакомиться хотя бы с некоторыми из этих удивительных творений матушки-природы? Как научить их относиться ко всему, что нас окружает, с любовью и уважением? Давайте попробуем сделать это через сказку.

К счастью, советские писатели оставили нам в наследство огромное количество произведений: рассказов, сказок, стихотворений. Можно без труда найти среди этих литературных сокровищ те, которые могут лечь в основу не одного десятка библиотечных и внеклассных занятий и классных часов. Это и Михаил Пришвин, и Софья Радзиевская, и Константин Паустовский, и Эрнест Сетон-Томпсон, и многие другие.

Но среди всего этого многообразия особняком стоят сказки Виталия Бианки. Его герои отличаются от других сказочных персонажей тем, что живут не в сказочных домах-теремках, как героиня С.Я.Маршака из сказки «Кошкин дом», а в естественных условиях: дуплах, гнёздах, норках. Но при этом каждый из них рассказывает свою историю-сказку, простую и фантастическую в одно и то же время. И мышонок Пик со своим не-обыкновенным путешествием, и маленькая заблудившаяся Береговушка («Лесные домишки»), и торопящийся попасть домой Муравьишка («Как Муравьишка домой спешил») – это готовое открыться всем желающим окно в удивительный мир дикой природы.

Одно из таких произведений и легло в основу этой разработки. Сказка «Росянка – комариная смерть» познакомит школьников с одним из интереснейших созданий природы – насекомоядными растениями и позво-

лит совершить экскурсию в один из самых необычных уголков природы – на болота.

В ходе занятия мы попробуем ответить на следующие вопросы: «Что такое болота?», «Болото и его жители.», «Болото и человек: вред или польза?» Таким образом, мы будем постепенно открывать детям мир экологии, чтобы они научились понимать и беречь природу.

ТЕМА: «Удивительный мир болот»

ВРЕМЯ ПРОВЕДЕНИЯ: 45 минут

ФОРМА МЕРОПРИЯТИЯ: Библиотечный урок

ЦЕЛЕВАЯ АУДИТОРИЯ: 2-3 класс

ЦЕЛЬ МЕРОПРИЯТИЯ: Познакомить участников с насекомоядными растениями, с растительным и животным миром болот, помочь найти ответы на вопрос: «Болото и человек: вред или польза?». Дать понятие об экологическом сообществе. Познакомить с новыми словами и выражениями.

ЗАДАЧА: Прочитать сказку В.Бианки «Росянка – комариная смерть», объяснить ученикам новые слова и выражения, встречающиеся в тексте (например, «Сохатый», «Копалуха», «Батожок» и др.).

ОЖИДАЕМЫЕ РЕЗУЛЬТАТЫ: Расширение кругозора учеников, пополнение их словарного запаса, новые знания об окружающем мире.

ОБОРУДОВАНИЕ: Книги со сказкой, проектор.

ОПИСАНИЕ ХОДА БИБЛИОТЕЧНОГО УРОКА: Сначала школьники по цепочке читают сказку, библиотекарь по ходу чтения поясняет новые слова и выражения. Затем включается презентация и дети узнают более подробно об обитателях болота.

РЕФЛЕКСИЯ: Подводим итоги урока. Ученикам дается минута на осмысление /рассуждение, чтобы дети вспомнили и продумали всё, что узнали. Потом каждый озвучивает свои впечатления с использованием таких предложений, как «Я сегодня узнал(а)…»; «Было интересно узнать…»; «Меня удивило…»; «Я понял(а), что…»

**Список использованной литературы:**

1. В. В. Бианки. Рассказы и сказки. – Казань: Татарское книжное издательство, 1981. – с. 25-27.
2. С.Б. Радзиевская. Повести и рассказы. – Казань: Татарское книжное издательство, 1981. – 349 с.
3. Осипов Н.Ф. В воде и у воды: Рассказы. – М.: Детская литература, 1965. – 54 с., илл.

## Сценарий урока

БИБЛИОТЕКАРЬ: Здравствуйте, дорогие мои читатели! Сегодня нас с вами ждёт очень интересное и полезное занятие. Мы прочитаем с вами сказку Виталия Бианки «Росянка – комариная смерть», которая познакомит вас с очень интересными и неожиданными представителями живого мира нашей планеты.

Давайте будем читать по очереди. Если вам попадётся новое и неизвестное для вас слово или выражение, после прочтения я вам их объясню, и вы сможете пополнить свой словарный запас.

*Школьники по очереди читают сказку.*

*Библиотекарь поясняет новые слова.*

БИБЛИОТЕКАРЬ: Ну вот, ребята, вы и познакомились с интереснейшими представителями растительного мира – хищными растениями. Мы с вами прочитали описание этого маленького хищника, а теперь давайте посмотрим, как она выглядит в природе. Росянка и её разновидности водятся во многих странах мира, и не всегда они опасны только комарам. Они могут поймать в свои сети, мух, шмелей, кузнечиков, тараканов, и даже мелких животных (см. приложение).

Росянка, конечно же, не единственный житель болота. Там живут многие удивительные создания. Скажите, кого из болотных обитателей вы знаете?

*Ученики называют разных животных и птиц.*

БИБЛИОТЕКАРЬ: Да, вы все правы. Но кроме тех живых существ, которых вы назвали, есть ещё цапли, тритоны и черепахи, выдры и бобры и многие другие. Среди болотных растений нужно отметить прекрасные кувшинки, разные виды осоки и рогоза. Все они по-своему уникальны и могут жить только в болотистой местности. Давайте же познакомимся с некоторыми из них (см. приложение).

БИБЛИОТЕКАРЬ: Как вы видите, болото – это уникальный уголок живой природы. Конечно, они опасны для тех, кто не знает их. На протяжении сотен и тысяч лет в болотах тонули люди и звери. Однако болото может быть, как врагом, так и другом людей. Ведь именно из маленьких ручейков, текущих по болотам, берут своё начало такие реки, как могучий Днепр-Славутич, наша красавица Волга, Москва-река и другие. Без болот не было бы и этих великих рек. Кроме того, болота не дают лесным пожарам уничтожить все леса.

Во время Великой отечественной Войны болота играли роль защитников для многих людей. Ведь не зная дороги, нельзя ни пройти вражеским солдатам, ни тем более провести тяжёлую технику. Например, в

повести, написанной писательницей Софьей Борисовной Радзиевской, болото послужило укрытием и домом для небольшой горсточки людей, оставшихся в живых после того, как гитлеровские солдаты сожгли их родную деревню. Повесть так и называется «Болотные Робинзоны». Когда вы станете чуть постарше, я вам обязательно буду рекомендовать эту книгу к прочтению.

Теперь вы немного больше знаете о болотах. Теперь я хочу спросить у вас: как вы думаете: хорошо, что болота существуют или плохо? Польза от них или вреда всё-таки больше?

*Ученики дают ответы на вопрос.*

А теперь, ребята, давайте подведём итоги нашего урока. Сейчас я дам вам минуту, чтобы вы вспомнили и продумали всё, что узнали. Потом каждый из вас озвучит свои впечатления. Попробуйте использовать такие предложения:

Я сегодня узнал(а)…; Было интересно узнать…; Меня удивило…; Я понял(а), что…

Большое спасибо, что пришли на урок. До свидания!

Приложение

Доклад к презентации.

СЛАЙД 1: Название «Удивительный мир болот»

СЛАЙД 2: Книга В.Бианки «Росянка – комариная смерть». Иллюстрации к книге.

СЛАЙД 3: Загадка

«Все обходят это место,
Здесь земля, как будто тесто;
Здесь осока, кочки, мхи.
Нет опоры для ноги.»

СЛАЙД 4: Росянки

Росянки – одни из наиболее распространенных среди насекомоядных растений. Растут они по всему миру и насчитывают около 100 видов, большая часть которых обитает в Австралии и Новой Зеландии.

СЛАЙД 5: Торф

Торф – полезное ископаемое, которое образуется из остатков мхов, кустарников и невысоких деревьев на болотах. Части этих растений попадают во влажную болотистую землю, разлагаются без присутствия воздуха.

Он хорошо впитывают в себя жидкость (сто граммов торфа могут удерживать в себе до одного литра воды). Благодаря этому свойству, торф используют для очистки воды от загрязнения нефтью. Кроме того, торф

используют как удобрение. Ещё торф входит в состав многих хорошо знакомых лекарственных средств, например, активированного угля. Также благотворно влияют на здоровье человека торфяные грязи. Поэтому, очень часто недалеко от залежей торфа можно увидеть санатории, курортные зоны и базы отдыха.

Торф очень хорошо горит и выделяет много тепла, а ещё это отличный шумоизолятор, поэтому торфяные блоки часто используют при строительстве домов.

СЛАЙД 6: Клюква

Клюква – единственная кислая ягода в мире. Тем не менее, она высоко ценится как врачами, так и обычными людьми. Она долго хранится, в ней целая кладовая витаминов и полезных человеку кислот. Клюквенный морс пьют при простудных заболеваниях. Он утоляет жажду и снижает температуру. Очень полезна клюква с мёдом. Из этой ягоды делают пастилу, начинку для конфет, варенье.

СЛАЙД 7: Жабы и лягушки

Лягушки очень полезные. Они съедают ежедневно большое количество мух, комаров, мошек и других насекомых. Без лягушек бы насекомых было бы в тысячи раз больше. Кроме того, лягушки являются пищей для многих видов животных, птиц, земноводных, а лягушачья икра, а позже и головастики являются кормом для многих видов рыб и прочих водных жителей. Многие виды лягушек съедобны. Их употребляют в пищу во многих странах. Их мясо по вкусу чем-то напоминает куриное.

К тому же они служат показателями чистоты водоёмов. Если вы слышите по ночам лягушачьи концерты, значит вода в озере или пруду чи-стая. А если они живут у вас в саду – можете быть спокойны за урожай. Ведь эти милые создания уничтожают многих вредных для растений жуков и слизняков, даже таких вредителей, как колорадский жук.

СЛАЙД 8: Аир – это травянистое растение с сильным запахом. На Востоке аир был известен уже в глубокой древности. Настойка из его корневищ лечит самые разные заболевания, повышают аппетит, успокаивают лихорадку. Из корней так же получают эфирные масла, которые используются в парфюмерии. Корневища аира в высушенном и засахаренном виде ещё в XIX веке считались лакомством.

СЛАЙД 9: Кувшинка – не только красивый цветок, она используется в народной медицине, из-за чего длительное время ее необдуманно уничтожали. Вообще кувшинки желтые, как и большинство других водяных растений, принадлежат к самым старым

растениям планеты, которые появились на Земле миллионы лет тому назад.

В фольклоре желтые кувшинки издавна связывали с русалками, даже называли русальным цветком. Верили также, что русалки в летние лунные ночи собираются именно в тех местах, где растет больше всего желтых лилий-кувшинок. Согласно поверью, цветы нельзя срывать, особенно утром и вечером, потому что русалка может рассердиться, схватить человека за руку и даже утопить. Вспомните, в «Майской ночи» Николая Гоголя появлялись такие русалки с венками из кувшинок на голове. Из-за этого, рассказывают литературные источники, людям советовали собирать цветы кувшинки, разговаривая с ним ласковыми словами и даже закрыв уши, чтобы не слышать русалок. В любом случае, не позволялось срезать их, ведь при этом якобы стебель кувшинки истекает кровью, а тот, кто это сделает, будет видеть тяжелые сны. С корневищем кувшинки в руках в давние времена пастухи обходили поле, чтобы сохранить скот.

СЛАЙД 10: Журавль

Еще в Древнем Египте журавля называли птицей солнца. У римлян журавли ассоциировались с лучшими человеческими качествами: верностью, рассудительностью, добротой, отзывчивостью, дружелюбием. Если верить старинным восточным представлениям, души людей после смерти превращаются в птиц. По кавказской легенде, души поверженных храбрых воинов перевоплощаются в журавлей. Отсюда – бережное и уважительное отношение к ним.

По славянским поверьям, журавли тоже являлись посланниками божьими. Верили, что по осени журавли уносят в нездешний мир души усопших. А весной сопровождают души младенцев, которым вскоре суждено родиться.

На Руси всегда считалось хорошей приметой неожиданно увидеть в небе летящего журавля. Славяне верили, что если журавли присядут отдохнуть на поле, то смело можно ожидать от него богатого урожая.

# ФУНКЦИОНАЛЬНАЯ ГРАМОТНОСТЬ В СОВРЕМЕННОМ ОБРАЗОВАНИИ

**Гирфанова Гульфия Салимзяновна**
*МБОУ «Черемшанский лицей»*
*Учитель начальных классов*

Формирование функциональной грамотности учащихся – одна из основных задач современного образования. Уровень сформированности функциональной грамотности – показатель качества образования в масштабах от школьного до государственного.

Современный мир стал гораздо сложнее, чем был двадцать лет назад, а тем более тридцать лет назад. Эти сложности требуют особого подхода в педагогике. Это связано с появлением новых технологий, новых профессий, сфер экономики и с социально-психологическими изменениями самого человека. Окружающий мир больше не аналого-текстологический, ему на смену пришел визуально-цифровой – и это требует расширения и переосмысления понятия «функциональная грамотность».

Основные признаки функционально грамотной личности: это человек самостоятельный, познающий и умеющий жить среди людей, обладающий определёнными качествами, которые авторы именуют общеучебными умениями или ключевыми компетенциями.

Ключевые компетенции – это свойства и качества, необходимые любому человеку вне зависимости от выбранной им профессиональной сферы деятельности, наиболее общие способности и умения, позволяющие человеку понимать ситуацию и достигать результата в личной и профессиональной жизни в условиях конкретного общества [1,с.432].

Обще учебные умения (ключевые компетенции) развиваются в ходе обучения всем предметам на уровне доступном учащимся соответствующей возрастной группы. Эти ключевые компетенции формируются в ходе образовательного процесса, при условии владения педагогом методиками организации в классе учебного сотрудничества («учитель – ученик», «ученик – ученик») и внедрения соответствующих психолого-педагогических технологий [2,с.816].

Цель образования в условиях компетентностного подхода – формирование компетентной личности, т.е. личности, способной самостоятельно решать разнообразные проблемы, используя имеющиеся у нее знания и умения.

Таким образом, только функционально грамотная личность сможет оценить сложившуюся в обществе ситуацию, выбрать востребованную

на сегодняшний день профессию, принять правильное решение, адаптироваться в любом социуме, овладеть современными информационными технологиями.

**Литература**

1. Современные образовательные технологии: учебное пособие / под ред. Н.В.Бордовской и др. – М.: КНОРУС, 2010. – 432с.;

2. Селевко, Г.К. Энциклопедия образовательных технологий: в 2-х т. / Г.К.Селевко. –М.: НИИ школьных технологии. –2006. –Т. 1. –816с.

## ОДНА ИЗ ЦЕННОСТЕЙ СОВРЕМЕННОГО ОБРАЗОВАНИЯ, ЯВЛЯЕТСЯ ФГОС, КОТОРЫЙ ФОРМИРУЕТ УЧЕБНУЮ ПРОГРАММУ

**Корнилова Светлана Владимировна**
*МБОУ «Школа №71» г.Казани*
*Учитель начальных классов*

«Наша школа должна быть открыта для всего нового, должна идти в ногу со временем и при этом сохранять свое уникальное лицо, свои корни, те ценности, которые веками закладывались в обществе, должна не только учить, но и воспитывать человека и гражданина». В.В. Путин

Основной задачей ФГОС является создание единого образовательного пространства по всей России. Считается, что оно обеспечит комфортные условия обучения для детей при переезде в другой город или, к примеру, при переходе на семейное обучение.

ФГОС также обеспечивает преемственность образовательных программ. Предполагается, что каждый ученик на предыдущей ступени обучения получает все знания, необходимые для перехода на следующую. Иначе говоря, нельзя перейти в пятый класс, не владея знаниями и умениями начальной школы.

ФГОС должны соблюдать образовательные учреждения любого уровня, начиная с детского сада и заканчивая курсами повышения квалификации. Под эту необходимость попадают не только государственные, но и частные учебные заведения. Ведь все они подчиняются закону «Об образовании в Российской Федерации».

ФГОС важны как для педагогов, так и для школьников. На государственных стандартах строится весь учебный процесс. В обновлённых ФГОС сформулированы максимально конкретные требования к предме-

там всей школьной программы соответствующего уровня, позволяющие ответить на вопросы: что конкретно школьник будет знать, чем овладеет, что освоит и какие ожидаемые результаты.

**Что нового принёс обновлённый ФГОС для учеников начальной школы?**

- он содержит постулат о необходимости формирования у детей представлений о России как «о стране, устремлённой в будущее», её месте в мире и исторической роли;
- программа обучения детей разделена на две части: 80% состоит из обязательной части начального общего образования, а 20% отведено на учебные курсы и внеурочную деятельность, которую может предоставить конкретная школа. Выбор этих факультативов остаётся за родителями.

Кроме того:

- в школе должны быть созданы условия для работы с одарёнными учениками, проходить интеллектуальные и творческие соревнования, созданы условия для научно-технического творчества и проектно-исследовательской деятельности;
- система оценки полученных знаний должна иметь комплексный подход, учитывать динамику освоения предметов и ориентировать образовательную деятельность на личностное развитие и воспитание обучающихся, включая гражданское, духовно-нравственное, эстетическое, физическое, трудовое, экологическое воспитание.

Отметим, что данные ФГОС не будут использоваться для детей с ограниченными возможностями здоровья и интеллектуальными нарушениями. Для учеников с особыми потребностями создаются адаптивные образовательные программы.

В новый ФГОС для 1-4 классов также добавили задачи на развитие патриотизма у детей. Их реализация должна отражаться в предметных и личностных результатах освоения программ по ряду учебных дисциплин.

В числе обязательных предметов в начальной школе:

1. Русский язык и литературное чтение.
2. Родной язык и литературное чтение на родном языке.
3. Иностранный язык.
4. Математика.
5. Окружающий мир.
6. Основы религиозных культур и светской этики (на выбор – изучение православной, буддийской, иудейской, исламской культуры, либо

основы религиозных культур народов России или основы светской этики).

7. Изобразительное искусство.
8. Музыка.
9. Технология.
10. Физическая культура.

В стандартах прописано право детей проходить обучение в начальной школе на родном языке из числа языков народов России, либо изучать его «в пределах возможностей, предоставляемых системой образования».

В школах, где языком преподавания является русский, изучение родного языка осуществляется по заявлению родителей ученика и при наличии возможности преподавания предмета у образовательной организации.

**Подход к изучению иностранных языков в начальной школе**

Ученики начальной школы к её окончанию должны научиться строить диалог из 4-5 фраз со стороны каждого собеседника, составлять монолог (4-5 реплик),воспринимать и понимать на слух до минуты адаптированного текста и писать тексты объёмом до 80 слов в рамках тематического блока «Мир моего «Я». Мир моих увлечений. Мир вокруг меня. Родная страна и страна изучаемого языка».

Окружающий мир – не только о природе

ФГОС 2 поколения ставил в задачи учебного модуля формирование у детей уважительного отношения к семье и семейным традициям, школе, родному краю, России, её истории, культуре, природе, но теперь также появилась цель развить у детей «чувство гордости за национальные свершения, открытия, победы». У ребёнка должны сложиться первоначальные представления о «важнейших для страны и личности событиях и фактах прошлого и настоящего России».

Родители, с учётом мнений которых складываются многие аспекты процесса школьного образования, должны быть в курсе норм, которые вводят новые ФГОС, чтобы сделать процесс обучения детей максимально комфортным и продуктивным.

ФГОС важны как для педагогов, так и для школьников. Стандарты нового поколения унифицируют темы и подходы преподавания. Благодаря этому школьник сможет получить все необходимые знания и навыки в любом образовательном учреждении каждого региона страны. А педагог может быть уверен, что его учебная программа подойдёт даже для ученика, который только перешёл из другой школы. Работать по ФГОС сложно, но интересно.

Моей задачей теперь, в отличие от предшествующей работы, когда надо было просто как можно нагляднее и доступнее на уроке всё объяснить, показать, рассказать, является включение самого ученика, даже наислабейшего, в учебную деятельность.

Мы все знаем, что каждый наш ученик индивидуален, то же касается и учителей.

К внедрению ФГОС каждый учитель был готов по-разному. Легче всего, я думаю, пришлось тем, кто работал по развивающим системам. Ну а мне, как и любому другому учителю традиционной программы, пришлось многое пересматривать в своей деятельности.

